АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

## *Арск*

КАЗАНЬ · 2017

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

## *Арча*

КАЗАН • 2017

УДК 398:811.512.145:745/749
ББК 82.3(2Рос=Тат):81.2Тат:85.12
М 48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре
һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү
һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

**Редколлегия:**
К.М. Миңнуллин (рәис), И.Г. Нуриев, М.И. Әхмәтҗанов

**Фәнни мөхәррир**
филология фәннәре кандидаты И.Г. Гомәров

**Төзүче**
филология фәннәре кандидаты Р.Г. Галиуллин

**М48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Арча.** – Казан, 2017. – 360 б. – (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән; унбишенче китап).
ISBN 978-5-93091-240-1

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән чираттагы китап Татарстан Республикасы Арча районында яшәүче милләттәшләребез, аларның гореф-гадәтләре, тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Бу җыентыкта борынгы кульязмалар, шәҗәрәләр, тарихи шәхесләргә багышланган мәкаләләр урын алды. Шулай ук анда җирле халыкның авыз иҗаты, җыр-моңнары, осталарның кул эшләре, авыллар тарихы белән дә танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренү-эзләнүләрен туплаган әлеге басма үз укучыларын табар һәм андагы язмалар һәркемдә зур кызыксыну уятыр, дип ышанабыз.

**ISBN 978-5-93091-240-1**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2017

## СҮЗ БАШЫ

И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин...

Халкыбызның бөек улы Габдулла Тукай «Туган җиремә» шигырендә үзен дөньяга китергән Арча ягына мәхәббәтен әнә шундый җылы хисләргә төреп бирә. Ул хис даһи шагыйребезгә генә түгел, дөньяга сибелеп яшәгән һәр татар кешесе өчен дә хас: Арча районы милләтебезнең рухи, мәдәни үзәкләренең берсе, әдипләр еш кына аны «әдәбиятыбызның Мәккәсе» дип тә атыйлар. Казан артының үзәге булган Арчага карата бу чагыштыруларны куллану, әлбәттә, юктан килеп чыкмаган. Арча ягындагы Кышкар, Курса, Ташкичү кебек мөселман дөньясына мәшһүр мәктәп-мәдрәсәләрнең эшләве һәм аларның даны еракларга таралу, шул уку йортларында мәгърифәтче һәм философ Г. Курсави, галим, тарихчы, философ, мәгърифәтче Ш. Мәрҗани, галим-математик, астроном, мулла Фәйзулла әл-Мөндеши кебек шушы җирлектә туган шәхесләребезнең эшчәнлек алып барулары һәм аларның шагыйрь Г. Кандалый, мәгърифәтче Ф. Халиди, шагыйрь Г. Рахманколый, татар халкының милли азатлык хәрәкәте идеологы Батырша кебек шәкертләр тәрбияләве Арча төбәгенең, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, татар халкының төп рухи мәркәзләренең берсенә әверелүенә дәлил булып тора. Габдулла Тукайдан башлап, татар әдәбиятының йөзек кашларын тәшкил иткән Галиәсгар Камал, Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев һ.б. каләм әһелләрен, сәнгать кешеләрен үстергән як икәнен дә искә алсаң, Арча районының милли тормышыбызда нинди зур урын тотуын бәяләргә мөмкин.

Әлбәттә, һәр төбәкнең дә иң зур байлыгы − ул халык. Арча төбәгеннән инде ничәмә-ничә гасырлар дәвамында күренекле шәхесләрнең чыгып торуы да нәкъ менә бу як халкының мәдәниятле булуына турыдан-туры бәйле. Тукай юкка гына: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – димәгән. Гасырлар дәвамында тупланган тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл, тапкыр фикерләр, тәрбия алымнары, әхлак нормалары, күңел дөньясының, матурлыкның үзенчәлекле чагылышы, хәерле гамәлләрне аңлау-тоемлау рәвеше, дин, фәлсәфә, хәтер – болар барысы да тере формада халыкта яши, аның яшәү-көнкүреш шартларында реальләшә торган тиңсез хәзинә. Әлеге бәһасез олы байлык һәр дәвердә үсеш-үзгәрештә. Галимнең бурычы – әнә шул хәрәкәтнең кабатланмас чаткыларын, әһәмиятле мизгелләрен билгеләп калу, бөртекләп җыйнау, теркәү, өйрәнү аша мөһим ачышлар ясау, халыкныкын халыкка кире кайтару.

Соңгы елларда татар халкын, аның борынгы заманнарга барып тоташкан бай тарихын, күп гасырлар дәвамында чарланып килгән туган телен, үзенчәлекле сәнгатен һәм мәдәниятен күп белгечләр катнашлыгында бергәләп өйрәнү буенча Татарстан Фәннәр академиясе институтлары тарафыннан әһәмиятле чаралар уздырыла. Шуларның зур кызыксыну уята торганнарыннан берсе – халкыбыз яши торган төрле төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештыру. Экспедицияләр Институт оешкан вакыттан бирле уздырылып килсә дә, 2009 елдан башлап яңа баскычка күтәрелде. Шул елдан комплекслы экспедицияләр Татарстанның Актаныш, Апас, Кукмара, Чүпрәле, Мамадыш, Әтнә, Мөслим, Минзәлә һ.б. районнарында, Мари Эл, Удмуртия Республикаларына, Түбән Новгород, Омск, Томск, Новосибирск, Оренбург, Әстерхан, Чиләбе, Курган, Самара һ.б. татарлар яши торган күп кенә өлкәләрдә уздырылды. Бу экспедицияләрдә тел галимнәре, фольклорчылар, археографлар, тарихчылар, музыка һәм сәнгать белгечләре катнашты. Нәтиҗәдә теге яки бу төбәктә яшәүче татарларның тарихы берьюлы, берничә аспектта өйрәнелде. Бу исә һаман да үсештә-хәрәкәттә булган мәдәни-тарихи мирасыбызның ерак тамырларына тирәнрәк үтеп керүдә гаять әһәмиятле адым булып тора.

Шунысы әһәмиятле, әлеге төбәкләрдә тупланган материаллар нигезендә фәнни китаплар язылды, ике дистәгә якыны «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» исемле сериядә инде аерым басма булып басылып та чыкты. Әйтергә кирәк, бу хезмәтләр халыкта да, фән дөньясында да зур кызыксыну уятты һәм алар инде сирәк очрый торган библиографик китаплар рәтендә урын алды.

2016 елның җәендә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан Арча районына әйтеп үтелгән комплекслы экспедицияләрнең нәүбәттәгесе уздырылды. Анда дистәгә якын галим гаҗәеп бай материал туплады һәм алар анализланып шушы китапта тәкъдим ителә.

Арча районы әдәби телне саклый торган, халык авыз иҗатына, кулъязма китапларга бай, татарларга гына хас бизәү һәм текстлар белән кабер ташлары эшләү үзенчәлегенә ия төбәк буларак галимнәрне күптәннән кызыксындыра. Безнең Институт тарафыннан исә беренче фольклор экспедициясе атаклы фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми җитәкчелегендә 1951 елда оештырыла. Фольклорчылар бер айдан артык вакыт эчендә Арча районының Пөшәңгәр, Чүриле, Сеҗе, Сикертән, Казаклар, Масра, Казанбаш, Арча, Наласа, Урта Аты, Субаш Аты, Орнашбаш, Кушлавыч, Югары Сәрдә авылларын өйрәнә. Алга таба Институт галимнәре үз юнәлешләре буенча тикшеренүләрне дәвам итә. Әйтик, филология фәннәре докторы, профессор Марсель Әхмәтҗанов Арча төбәгендәге кулъязмаларны барлый, кабер ташларын өйрәнә, филология фәннәре докторы, диалектолог Флера Баязитова авыллардагы халык традицияләренә, гореф-гадәт, йолаларга, җирле сөйләш үзенчәлекләренә, йорт-җир төзелешенә, гомумән, рухи һәм матди мәдәнияткә караган фәнни мәгълүматлар туплый. Арча төбәгенә моңа кадәр фольклорчы, диалектолог, археограф, текстолог галимнәр тарафыннан ясалган игътибар үз нәтиҗәсен биргән: җыелган материаллар эшкәртелеп, фәнни әйләнешкә кертелгән, төрле җыентыкларда, шул исәптән академик басмаларда урын алган, гыйльми күзлектән өйрәнелеп, алар нигезендә фәнни хезмәтләр язылган, гомумән әйткәндә,

Казан арты татарларыннан җыелган рухи энҗеләр милли мирасыбыз буларак үз бәясен алган. Галимнәр дә Арча төбәгенә кагылышлы тикшерү-өйрәнү эшләрен даими алып барганнар. Шиһабетдин Мәрҗанидән үк башланган кабер ташларын ачыклау эшен Гали Рәхим, Һарун Йосыпов, Татарстан Милли китапханәсе галимнәре Ирек Һадиев, Раиф Мәрдәнов, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Айдар Гайнетдинов һ.б. дәвам итә. Халык авыз иҗатын барлауда Хуҗа Бәдигый күп көч куя. Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының этнологик тикшеренүләр бүлеге баш фәнни хезмәткәре Дамир Исхаковның Арча кенәзләренә кагылышлы эзләнүләре тарихыбызны барлауда мөһим урын алып тора. Татарстанның традицион мәдәниятне үстерү үзәге хезмәткәре Эльмира Каюмова Арча гөсләчеләрен ныклап өйрәнде.

Арча районы – Татарстан Республикасында иң эре районнарның берсе. Рус елъязмаларында Арча XIII гасырдан башлап телгә алына. Арчаның 1174 елда һәм аннан да элегрәк үк булганлыгы турында хәбәрләр бар. Арча атамасы Казанның түреннән үк башлана. «Арча капкасы», «Арча кыры», «Арча ягы», «Арча юлы» атамалары Казан тирәсендә Арча ягы кешеләре яшәгәне хакында сөйли.

Казан руслар тарафыннан яулап алынгач, Казан артына, нигездә, шәһәрдән качып котыла алган халык җыйнала. Алар үзләре белән шәһәр мәдәниятен, шәһәрнең традицион һөнәрчелеген (зәркәнчелек, металл эшкәртү, күнгә чигү, ташка язу һәм каллиграфия), монументаль һәм архитектура сәнгатен алып килә. Боларның барысында да Болгар дәүләтендә булган традицияләр саклана. Казан артының югары сәнгате һәм мәдәнияте һөнәрчеләренең күп булуы белән аңлатыла.

Әлеге экспедициядә галимнәребез бүгенге көнгә кадәр халык күңелендә сакланып калган мирасны барлады, соңгы еллардагы үзгәрешләргә игътибар итеп, яңа үзенчәлекләрне теркәде. Тел белгече, филология фәннәре докторы Ф. Баязитова традицион культурага, гореф-гадәт, йолаларга караган текстлар нигезендә этнолингвистик материаллар туплады,

җирле сөйләш үзенчәлекләрен ачыклау белән шөгыльләнде. Эпиграфик һәм археографик мирасны филология фәннәре докторы, профессор Ф. Яхин өйрәнде. Халыктан борынгы кульязмалар, ташъязма истәлек үрнәкләре җыелып, материаллар Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә тапшырылды. Алар арасында басма һәм кулъязма китаплар, дәфтәргә, аерым битләргә теркәүле иске язулар, кулъязма һәм басма шәмаилләр, документ кәгазьләр, фотографияләр һ.б. бар. Моннан тыш, А. Гайнетдинов тарафыннан берничә экспедиция дәвамында райондагы 93 авылда 1288 борынгы кабер ташы өйрәнелде. Фольклорчылардан филология фәннәре кандидаты И. Ямалтдинов һәм халык авыз иҗаты бүлегенең фәнни хезмәткәре Г. Яхшисарова төп игътибарларын халык авыз иҗаты үрнәкләрен барлауга юнәлтте. Фольклорчы галимнәрнең халык вәкилләре белән әңгәмә корулары нәтиҗәсендә шушы төбәккә генә хас булган топонимик, тарихи һәм мифологик риваятьләр, хикәятләр, авыл тарихлары, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, йола фольклорына караган үрнәкләр, халык уеннары, төрле ышануларга бәйле барлыкка килгән текстлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, мәзәкләр, мәзәк хәлләр һ. б. язып алынды. Тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлегенең фәнни хезмәткәре М. Газизова йортларның тышкы һәм эчке бизәлешенә игътибар юнәлтеп, сандык төпләрендә ята торган чигүле сөлгеләр, тастымаллар, караватж җәймәләре, шәмаил үрнәкләре белән танышты, агач эше, милли киемнәр тегү һ.б. буенча эзләнүләр алып барып, этник мәдәният өлкәсен баета торган шактый кызыклы материаллар тапты. Әлеге китап Институт галимнәренең Арча якларына кагылышлы соңгы еллардагы кайбер башка эзләнү-тикшеренү материалларын да үз эченә ала. Шулай ук Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә төрле елларда фәнни экспедицияләр вакытында тупланган күп кенә фольклор материаллары тәкъдим ителә. Мөхәммәт Мәһдиев (1961), Эдуард Касыймов (1951), Наил Гыйззәтуллин (1951), Мәрвә Богданова (1951), Арча педагогия училищесы студентлары тарафыннан язып алынган материаллар «Ерак еллар кайтавазы» сәхифәсендә урын алды.

Йомгаклап әйткәндә, укучыларга тәкъдим ителә торган әлеге басмага шушы төбәктәге татарларның тарихилыкны саклап яшәүләре, җирле осталарның, халык талантларының иҗат җимешләре белән тормыш-көнкүрешләрен бизәргә омтылулары хакындагы язмалар кертелде. Арчада көн күрүче татарларның үткәне һәм бүгенгесе хакында шактый тулы фәнни мәгълүмат бирә торган бу китап барлык милләттәшләребезгә дә кызыклы булыр, милләтебез өчен күп ул-кызларны тудырган һәм үстергән төбәк, Гариф Ахуновның «Без бит Арча яклары!» повесте исемендә яңгыраганча, үзенең бай күңелле халкына карата тагын бер кат горурлык хисләре кичерер дип ышанасы килә.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры*

# РУХИ МИРАСЫБЫЗ ХӘЗИНӘСЕ

Һәр төбәктәге татарларның үз хасиятләре, серләре, тарихы бар. Арча халкының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен яктырткан китап әзерләү турында без күптәннән хыяллана идек. Һәм менә, ниһаять, Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре безнең әлеге хыялыбызны тормышка ашырды.

Арча районы – гүзәл табигатьле, табыннарыбызны сыйнигъмәтләр белән баетучы алтын куллы эшчеләрне, татар халкының әдәбиятын, мәдәниятен, күркәм гореф-гадәтләрен үстерүгә зур өлеш керткән бөек Тукайны, Мәрҗанине һәм башка искиткеч олы шәхесләрне үстергән тарихи төбәк. Әдәби әсәрләре белән илебез тарихына кергән язучылары, татар моңы белән халык күңеленә кергән танылган җырчылары, мәгърифәттә зур уңышларга ирешкән укытучылары, чигүле түбәтәйләре һәм читекләре, нәтиҗәле хезмәт иткән авыл хуҗалыгы эшчәннәре белән дан тота Арча районы!

Казан артын гомер бишеге итеп сайлаган әби-бабаларыбыз үзләренә лаеклы, уңган буын, матур гореф-гадәтләр һәм йолалар калдыра алганнар. Шуңа да районыбыз нык, тотрыклы үткәне белән шатлана белә, хәзергесе көндә тырышып эшли, киләчәккә дә зур өметләр баглый, алар да тарих битләрендә үз урынын алыр дигән ышанычта калам.

Үткәнне белмичә киләчәкне корып булмый, бу инде сыналган хакыйкать. Без халкыбыз озак еллар барлыкка китергән мирасны һәм тормыш итү тәҗрибәсен тирәнтен өйрәнгәндә генә, аны балаларыбызга һәм оныкларыбызга җиткерә алабыз.

Киләчәк буын белеп үссен дисәк, без Арча төбәгенең тарихын, мәдәниятен, халык авыз иҗатын, гореф-гадәтләрен, аның күренекле шәхесләренең хезмәтләрен тирәнтен өйрәнүне дәвам итәргә тиеш.

Тәкъдим ителә торган китап та бу юнәлештәге хезмәтләрнең нәтиҗәсе. Арча төбәгенең рухи байлыгын чагылдырган әлеге язмалар татар дөньясы өчен кызыклы булыр, райондашларыбызга һәрдаим ярдәм итәр дип ышанып калам. Елар үтәр, буыннар алмашыныр, китап мәңге яшәр, китапханәләребездә, өйләребездәге китап киштәләрендә сакланыр, безнең тарихи тамырларыбыз – милли мәдәниятебез, телебез, гореф-гадәтләребез һәм традицияләребезне сакларга, үстерергә кирәклекне искәртеп торыр.

***Илшат Габделфәрт улы Нуриев,***
*Арча муниципаль районы башлыгы*

## ДҮРТ ЯГЫМ КЫЙБЛА:
## Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт

*Фәрит Яхин*

Арча халкы кемне дә сокландырырлык. Алар күргән тәрбияне бездә беркемнең дә татыганы юктыр ахрысы. Монда бар да бер башка югарырак. Тораклары төзек тә, чиста да, ә кешеләре – иманлы. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Ничәмә буын шагыйрьләр, язучылар, галимнәр, ил батырлары, аларның да ниндиләре әле – атаклылары, барысы да шушы яктан. Юкка әйтмиләр аларда: «Кешене күтәрсәң – ил күтәрелә, илне үстерсәң – кешеләре үсә!» – дип.

Арча ягындагы иң борынгы авылларның берсе – Түбән Орыда XVII гасырда, үз заманында акылы, зиһене, галимлеге белән танылып, тарихыбызда эз калдырган шәхесләребездән Бисари улы Янсари хафиз яшәп, 1687 елда вафат булган. Аның бабасы – Килдеш бәк, ә ул – Килеваз бәкнең улы икән.

Оры авылы зиратында булып, аның кабер ташын укыганлыгы хакында Риза Фәхретдинов «Асар» китабында язып уза. Янсари хафизның Ючәнәһам исемле кызы Иванай улы Юныска никахлы икәнлеген дә ачыклый[1]. Янсариның «хафиз» аталуы мәсьәләсенә тукталып, бу сүзнең мәгънәләрен төрле яклап тикшерә, керәшеннәрдә поп-атакайны да «хафиз» дип атауларына игътибарын юнәлтә, «абыз, абыстай» сүзләренең дә менә шушы «хафиз»га бәйле ясалуын ача.

---

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Беренче кисәк. Оренбург, 1900. Б. 29.

Иванай улы Юныс исә үз заманында шөһрәтле имам һәм мөдәррис булып җитлегә. Оры авылында зур мәдрәсә тота, балалар укыту белән шөгыльләнә. Аны «Юныс әфәнде», «Юныс ахун» дип атап йөрткәннәр. Бабасы Усай исемле булган.

Юныс хәзрәтнең этисе Иванай Кәче авылында имамлык һәм мөдәррислек иткән. Кодасы Янсари хафиздан соң, бер ел кичеп, 1688 елда вафат була. Казан төбәгендә зур нәсел калдыра.

Иванай мулланың язу эшенә маһирлыгын Р.Фәхретдинов аерым күрсәтә. Ш. Мәрҗани бу нәселдә зур галимнәр булганлыгын үз хезмәтләрендә искә ала.

Юныс хәзрәт 1636 елда туган. Р.Фәхретдиновның язганынча, Казан ханлыгы басып алынганнан соң, Урта Азия якларына китеп, Бохарада белем алып кайткан беренче кеше ул булган[1]. Зур гыйлем туплап, аң-белемдә маһирлыгы белән танылырга өлгергән. Юлда кәрван белән кайтышында, күчмәләр кулына төшеп, аны казакларның данлыклы ханы мәшһүр Әбул-Хәйрнең улы Чыңгызхан каршысына китерәләр. Егетнең төскыяфәте, күркәм тәрбиясе, тирән белемнәре һәм саф зиһене хан хәзрәтләренең күңелендә мәрхәмәт хисләрен уята. Ул аны үз янында калдыра. Әмма берникадәр вакыттан соң, егетнең сагыш утында көюен күреп, кәефен аулау нияте белән кызы Мәһәлбикә солтанга өйләндерә. Кыз, әлбәттә, бик тә чибәр икән. Хан баласы, шуңа да «солтан» титулы белән йөртелә.

Әмма Юныснең күңеле барыбер дә туган якларына ашкына. Ватанпәрварлык хисләренә бирелгән киявен, Мәһәлбикә солтан белән бергә, казаклар ханы Чыңгызхан асыл ватанына кайтып килергә җибәрә. Әмма алар анда төпләнеп калалар.

Юныс хәзрәт Оры авылында мәдрәсәдә укыта башлый. Тирән гыйлем иясе булуын истә тотып, аңарга четерекле мәсьәләләрнең берсе – бу мәмләкәттә гошер садакасын җыю тиешлеме-юкмы, шуны раслап чишү эше йөкләнелә. Ул аның важиб, ягъни саваплы икәнлеген дәлилләп фәтва яза. Голамә тарафыннан кабул ителеп, шул фәтвасы соңгы гасыргача үз көчендә кала килә, дини басма китаплар арасында ул хактагы хәбәрләрне очратырга була.

---

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Икенче кисәк. Оренбург, 1901. Б. 38.

Озакламый Юныс хәзрәтне Оры авылына имам итеп сайлыйлар. Ул мөдәррис, ягъни мәдрәсә профессоры сыйфатында да танылa. Әмма хатыны Мәһәлбикә солтан вафат була. Аны Оры зиратына җирлиләр.

Юныс ахун икенче хатын алырга ниятли. Аңа Янсари хафизның кызы Ючәнәһамне димлиләр.

Юныс хәзрәт өч угыл үстергән, исемнәре Нәзер, Сәфәр, Мәкъсүт икән. Болардан шулай ук укымышлы нәселләр таралган.

Фарсы теленә бик оста булып, Юныс хәзрәт күп әсәрләрен шул телдә язган, Иран ягы әдипләренең һәм галимнәренең хезмәтләренә шәрехләр төзегән, үзеннән бай һәм кызыклы гыйльми мирас калдырган. Китапларында үзен «Юныс ахун», «Мулла Юныс», «Юныс бине Иванай Казани» имзалары белән күрсәткән. Танылган әсәрләреннән берсе – «Шәрхе Габдулла» атала. Соңыннан ул Казанда берничә кат басылган, дини йолаларны үтәү, иман, намаз һәм башка фарызларны башкару хакындагы дәлилле, ышанычлы китаплардан санала.

Татар халкы XIX йөз шагыйре Әбелманих Каргалыйның тормышы һәм иҗаты хакында яхшы хәбәрдар. Алар хакында мәктәп дәреслекләреннән үк яхшы билгеле. Әмма аның бабалары Арча ягыннан икәнлеген искә дә алмыйбыз. Ул данлыклы шагыйрьләр һәм имамнар нәселеннән чыккан.

Әбелманихның бабасы Габдессәлам – Урай (Уразмөхәммәт) улы. Аның әтисе – Колмөхәммәт, бабасы – Колчура, нәсел башлары Кылап бәктән. Асыллары белән алар Алат юлындагы Мәңгәр авылы кешеләре.

Габдессәлам башта Ташкичү авылына күченә, анда имам-мөдәррис була, зур мәдрәсә тота. Дистә еллар буе Кариле имамы Хәсән улы Габдессәлам ахун мәдрәсәсендә камил белем алуга ирешкәнлеге яхшы мәгълүм. Мәдрәсәдә укыган чагында гарәп теле грамматикасына бәйле хезмәт яза һәм сүзлек төзи. Бу кешенең чыннан да Әбелманих Каргылыйның бабасы булуын Р. Фәхретдинов «Асар» хезмәтендә ачык дәлилләп яза, фикерен раслауда шагыйрьнең үз сүзләреннән дә файдалана, әсәреннән өзек китерә[1].

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Икенче кисәк. Б. 42.

Тагын да шунысы әһәмиятле, Габдессәламнең бер кызы Стәрлетамак ягындагы Кырмыскалы авылы имамы Вәлид бине Мәкъсүт бине Афак бине Дусмөхәммәттә кияүдә була. 1744 елда Патшабикә Елизавета (аны татарлар «Әби патша» дип атап йөрткәннәр) татар һөнәрчеләренә һәм сәүдәгәрләренә Сакмар елгасы буенда шәһәр төзергә фәрман бирә. Эш башына Казан ягы Саба авылынан курку белмәс Габделхаяли улы Сәгыйть баса, үз тирәсенә гайрәтле, хөр җанлы татарларны туплый. 1750 елда, башкалар белән бергә, Габдессәлам дә шул якларга күченә, Оренбургта имам һәм мөдәррис була. Аның Ташкичү мәдрәсәсендә укыткан чагында ук шәкертләрен китап язарлык, иркен фикерләрлек дәрәҗәдә тәрбияли алганлыгын Ш. Мәрҗани тарихи хезмәтләрендә дәлилләп, мисаллар белән искә алган.

Габдессәламнең үз мөгаллиме Хәсән улы Габдессәлам исә асылы белән Уфа ягы кешесе була. Ул Кариле авылына килеп, монда исеме тирә-якка танылган остаз-мөдәррис буларак танылa. Күп кенә шәкертләр тәрбияли. Әмма ир балалары булмау сәбәпле, тәрбиясез калгач, Минзәлә елгасы буендагы Шыгай авылына китә. Монда кызы кияүдә була. Шулай итеп, Шыгай авылында кияүләре Сөләйман улы Мөхәммәтшәрифтә яши, атаклы Шыгай мәдрәсәсендә укыта. Аннары Мәлем авылындагы кияүләре Зәйнетдин йортына күченә. Кабере дә шул Мәлем авылында.

Гали Чокрыйның әнисе Гөлбаһар нәкъ менә шушы нәселдән.

Хәсән улы Габессәлам исә данлыклы Котлыгыш Әс-Семети улы Мортаза әфәндедә белем алган. Ә ул, үз чиратында, Дагстан якларында укып кайткан, хаҗи да икән. Р. Фәхретдин хәбәренә күрә, 1723 елда Мортаза хафиз намаз укуга бәйләнешле әһәмиятле гарәпчә китап язган[1].

Хәсән улы Габдессәлам Курса авылында да белем алган. Ул монда Таип улы Рафыйк мөдәррис мәдрәсәсендә укыган. Шунысы игътибарга лаеклы, имам Рафыйк үзе дә заманында Мортаза хафизның шәкерте булган.

Габдессәламнең Рафыйк хәзрәткә күчүе мөдәррисенең вафаты сәбәбенә бәйле аңлатыла ала. Ул заманнарда гыйлем иялә-

---

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Беренче кисәк. Б. 31.

ре күп булмаган. Рафыйк Курсави бик күп бәхәсләр уяткан мәсьәләләрдән берсе – кыска төннәрдә ястү намазын уку тиешлеге хакында рисалә язган шәхес тә әле.

Бу кешеләр фикер иясе Габденнасыйр Курсави кебек алдынгы карашлы галимнең җитлегеп мәйданга чыгуында зур роль уйнаганнар билгеле. Габденнасыйр кебек даһиларга бөек халыклар һәйкәлләр куялар, бездә дә андый гамәлләр булырга тиеш югыйсә.

Габденнасыйр Курсавиның әтисе Ибраһим исемле, бабасы – Ярмөхәммәт. Ул Курса авылыннан Иштирәк нәселенең дәвамчысы. Габденнасыйрның улы – Насыйр. Шунлыктан ләкабе, шәригать кысаларында, Әбуннасыйр була, ягъни «Насыйрның әтисе» дигән сүз. Шунлыктан берәүләр аны «Әбуннасыйр Курсави» диләр, икенчеләр «Габденнасыйр Курсави» исеме белән белдерәләр. Бу исә «ике төрле кеше хакында сүз бара булса кирәк» дип уйларга җирлек тудыра. Алар икесе дә бер үк зат, ягъни Насыйрның атасы Габденнасыйр Курсави.

Габденнасыйр Курсавиның әтисе Ибраһим 1790 елда вафат булган. Әнисе – Әмин кызы Миһербан, Максабаш авылы Мансур бай нәселеннән.

Габденнасыйрның апасы Мәрхүбә исемле булган. Мәчкәрә авылыннан Габдессәлам улы Габдуллага кияүгә чыккан, Габденнасыйрны гына түгел, Гобәйдулла, Муса, Мөхәмматҗан, Хәсәнбану исемле балаларын да үстергән. Р. Фәхретдинов аны «Мәшһүр хатыннар» исемлегенә керткән. Мәрхүбә абыстай 1827 елда вафат булган.

Габденнасыйр Курсави 1776 елда дөньяга килгән. 37 яшендә, 1812 елда, Рамазан аеның соңгы унынчы көнендә вафат булган. «Буның вафат улмасы илә Казан вә Болгар исламнары, бәлки гомумән ислам галәме олуг бер галимнәрене заигъ итмешләрдер», – дип яза шушы хакта белдереп Риза Фәхретдинов[1]. Һәм ул бу очракта да мең өлеш хаклы.

Бала чагында Габденнасыйр, белем алу максатын күздә тотып, туган авылы Курсадан Малмыж ягы Мәчкәрә авылы

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Өченче кисәк. Оренбург, 1903. Б. 95.

мәдрәсәсенә китә. Аннары аны гарәп-фарсы телләрен яхшылап үзләштерү теләге Бохарага кадәр китерә. Ул монда батыйни вә заһири гыйлемнәрне, ягъни интуиция һәм тәҗрибә юллары белән хакыйкатьне табу ысулларын, замананың бөек галимнәреннән һәм шәехләреннән өйрәнә, гарәп-фарсы телләрендә камил дәрәҗәдә укырлык, язарлык, иркен аралашырлык дәрәҗәләргә ирешүе белән бергә, мәгънәләргә, ягъни белемнәрнең эчтәлегенә, чын асылына төшенүгә дә ирешә. Бохарада уздырыла торган галим-голамәнең бәхәс мәҗлесләренә йөри. Монда үзенең яхшы зиһен һәм гыйлемнәр иясе булуын, кыен мәсьәләләрне чишә алырлык көчле акылы һәм аңы барлыгын күрсәтә. Даны тарала. Хәтта ул килмичә бәхәс мәҗлесләре башланмау очраклары ешая.

Әмма уйланмаган хәлләр килеп чыга. Габденнасыйр Курсави, фикер өлгерлеге һәм хакыйкатьне ачык күрә белүе аркасында җитәкче даирәләрнең «күңелен болгатуы» сәбәпле, алга таба Бохарада кала алмый, үз ватанына кайта. Аңа бай җизнәсе Габделсәлам улы Габдулла олы мәдрәсә салдырып бирә. Габденнасыйр Курсави аны алдынгы карашлы һәм югары белемнәр учагына әверелдерә.

1807 елда ул Бохарага икенче тапкыр китә, анда бераз торгач, кирәкле китапларын кабат укып, күчереп язып, тикшерепөйрәнеп чыккач, Хива шәһәренә юл ала, монда да китапханәләрдә була. Аннары Әстерханга килә, шуннан соң, Идел буйлап сәяхәт итә-итә, асыл ватанына кайта.

Ә 1812 елда Габденнасыйр Курсави хаж сәфәренә кузгала. Алар Казанда җыелышып, аннан Истанбулга киләләр. Әмма Габденнасыйр юлда авырый башлый. Истанбулга барып ирешкәндә авыруы тагын да көчәя һәм ул шунда вафат була. Искедәр бистәсе Солтаннар зиратында җирләнә.

Габденнасыйр Курсави күп төрле остазлардан белем ала. Әмма алар арасындагы ике галим аның фикерләре оешуда, күзләре ачылуда төп урынны алып торалар. Аларның беренчесе – Мәчкәрәдән имам-мөдәррис Мөхәммәтрәхим булган. Ә Мөхәммәтрәхим үзе Ашыт авылы Йосыф мулланың улы икән. Икенчесе – Бохара шәехе Ниязколый Төрекмәни (Шаһнияз улы). Бу

остазы да гаҗәеп зур акыл иясе, фикер чыганагы һәм итагатьле кеше булган.

Габденнасыйр Курсавиның язган китап һәм рисаләләре арасында тугызы бүгенге көндә дә әһәмиятле саналалар. «Әл-Иршад», «Китабул-ләваих», «Шәрхүл-гакаидүл нисфиятүл кадим», «Шәрхүл-гакаидүл нисфиятүл җәдит», «Рисаләтүл-исбатул-саффат», «Китабул-нәсаих», «Шәрхул-мохтасарул-Манар», «Хашиятүл-гакаидүл-җәдит», «Төрки телендә Һәфтияк шәриф тәфсире» кебек хезмәтләре белән ул ислам дөньясын яңа фикерләр белән баету гына түгел, бәлки яшәеш барышын һәм илаһият кануннарын суфичылыктан аралап алып аңлата башлаган бөек галим дә санала.

Габденнасыйр Курсави озын буйлы, киң маңгайлы, туры карашлы, куәтле кеше булган. Башкаларның сорауларына ачык итеп, аңлатып җавап биргән, төгәл, матур итеп сөйләшкән. Үткенлеге белән сокландырган да, куркуга да салган. Табигатеннән үк укымышлы кеше икәнлеге күренеп торган. Гәүдәгә – арык, холыкта – сабыр, акылы – камил, фикерләре – дөрес, нәсыйхәтләре – яңача, кабатланмас сурәттә үтемле һәм дәлилле, зиһене – ачык һәм төгәл, әйткәннәрендә матур гыйбрәтләр һәм чагыштыру-ишарәләр күп булып, сүзләре үзе белән сөйләшүчеләрнең күңеленә рәхәтлек белән йогучан булганнар. Бу сыйфатлары аңа карата башкаларда хөрмәт, олылау хисе уяткан, әмма көнчелекле кешеләрдә дошманлык хисе дә тудырган. Әмма Габденнасыйр Курсави боларына бик игътибар итеп тормаган. Олы адәмнәргә күрсәтелгән ихтирамны аңа кече яшеннән татырга туры килгән.

Габденнасыйр Мәчкәрә мәдрәсәсендә укыган чагында аның этисе үлә. Мөгаллиме Мөхәммәдрәхим хәзрәт аның акыллы, зиһенле һәм аңлы шәкерт булуына соклануын яшерми, укуын дәвам иттерүен сорый. Габденнасыйр Курсавиның киләчәктә зур галим буласын башкаларга да яшермичә әйтә килә. Аның үсеп, зур галим мәртәбәсен алуын халыкта өмет итә башлыйлар. Бу хакта Ш. Мәрҗани үз хезмәтләрендә сокланып искә ала, хәтта халкыбыз эчендә чын галимнәрне аера һәм күрә белүчеләрнең барлыгына куана.

Габденнасыйрга иптәшләре дә, тормышы бермә-бер авырлашса да, укуын ташламаска киңәш итәләр. Һәм ул Бохарага китеп бара, анда да ачлы-туклы гомер кичерә. Әмма гыйлемгә омтылышын һич кенә дә туктатмый. Мәчкәрә мәдрәсәсе шәкерте чагында ук аның фикерле булуы, укыган китапларын тәмам истә калдырулары, дәресләрдә һәм аерым оештырылган гыйльми бәхәсләрдә аларны дәлил итеп сөйләп бирүләре мәртәбәсе үсүгә хезмәт итә, инде яңа сыйфатлары да ачыла. Бохара галимнәрен ул гаҗизлектә калдыра башлый. Иман һәм шәригать мәсьәләләрендә аның ачык һәм аңлы сөйләүләре, замана үзгәрешләре һәм тормыш таләпләре белән бергә һәркайсын янәшә куеп аңлатулары үзләрен белем иясе хисабында йөртүче адәмнәрнең ачуларын китерә һәм алар аның өстеннән Бохара әмиренә хат язалар. Бу вакытта Габденнасыйр Курсави Ниязколый Төрекмәнидә дүрт ел белем алган, аның алдынгы шәкерте хисабында санала башлаган икән. Тагын шунысы да бар, Казан ягыннан килгән шәкертләр андый бәхәс мәҗлесләренә йөрмәү ягын караганнар. Ул утырышлардагы шау-шулар, берберсен асылсыз инкарь итүләр, кәфергә чыгарулар бик еш булганлыктан, аның ише урыннардан читтәрәк йөрүне хәерлегә исәпләгәннәр. Әмма Габденнасыйр Курсави бу ише бәхәс мәйданнарына тәҗрибә урыны буларак та караган, аларны хакыйкатьне эзләү өчен уңай урын итеп тә белгән. Әфләтунча фикер йөртүе, акылы, зиһене аны игътикад мәсьәләсендә яңа мәгънәләр табуга китергән.

Бохара әмире махсус мәҗлес җыйдырып, илендәге галимнәрне чакырып, Габденнасыйр Курсавины кяферлектә гаепләгәндә дә бары тик тиран рәвешендә эш иткән, хәтта шәригать таләпләрен дә исәпкә алмаган. Аның ясаган хөкемен һәм дини, һәм тарихи нигездә тикшереп, XX гасыр башында Р. Фәхретдинов бу эшнең ни әмирлек, ни казыйлык ягыннан гадел һәм дөрес башкарылмаганлыгын ачыклап, аңлатып язарга мәҗбүр була[1].

Ш. Мәрҗани дә үз чорында, Бохарада укыган вакытларында, «Габденнасыйр эше» белән махсус кызыксына һәм ул вакыйгада

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Өченче кисәк. Б. 119–121.

катнашкан имам-мөдәррисләрнең соңыннан үкенүләрен, Курсави замандашлары арасында аны аңларлык галимнәрнең булмавын искәртүләрен, бу хакта яшерми әйтүләрен хезмәтләрендә хәбәр итә.

Бохарадан Әстерханга килгәч, Габденнасыйр хәтта Шигый мәзһәбе галимнәре мәҗлесенә чакырыла. Ул аларны шаккатыра. Һәммә яктан бу мәзһәпнең үзенчәлекләрен ачык аңлатып бирә. Аның белән ярышырлык, фикерләрен инкарь итәрлек галимнәрнең араларында табылмавы аларны борчуга сала.

Габденнасыйр Курсави диндә сәләфләр (сәләфият) юлын өстен куя, әмма аңа да тәмам мөкиббән түгел, тәнкыйди карашы булган шәхес. Моңа Ш. Мәрҗани дә игътибар иткән, ул аны хәтта «биш йөз елга бер туа торган галим» дип атаган. Курсавиның китапларын укыган кешеләр, аның фикерләрен һичбер бәхәссез кабул итеп, тормыш тәртипләрен үзгәрткәннәр, хаталарын төзәткәннәр. Шундыйлардан мисал итеп «Асар»да Р. Фәхретдинов Табул ягыннан Хуҗамбирде исемле галимнең вакыйгасын искә ала[1]. Ул, Г. Курсавиның «Әл-Иршад»ын укыгач, мәсләген үзгәртә, игътикадын яңарта.

Г. Курсави Хивага килгәч, шәһәр башлыгы аңа атап аерым мәҗлес оештырган. Гыйлеменә һәм данына соклануын яшермичә, ике йөз алтын акча биреп, аның иңенә халат салган һәм үзләрендә имам-мөдәррис булып калуын үтенгән. Бу кадәрле олы хөрмәтләр күңелләрне яуларлык дәрәҗәдә күрсәтелсә дә, Габденнасыйр ата йортына кайтырга тиешлеген дөрес мәгънәдә белдерә алган.

Аның Хивага килүен мөгаллиме Ниязколый Төрекмәнигә хөрмәте буларак та аңларга кирәк. Кайда гына бармасын, Г. Курсавиның аның шәхесенә карата көчле соклану хисләрен уятыр дәрәҗәдә бөеклеген танымый мөмкин түгел.

Китапларындагы аңлатмалар, фикер сөреше гаҗәеп дәрәҗәдә җитди рәвештә булып, икеләнерлек урын калдырмыйлар, фәнни мәгънәләр кысасында язылганнар. Шул сәбәпле кешеләргә тәэсирләре дә көчле. Дини-рухани эчтәлектә, Аллаһыга тугрылык,

[1] Шунда ук. Б.123.

Мөхәммәд пәйгамбәргә олы хөрмәт, ислам динен саф, бернинди катнашсыз һәм, иң әһәмиятлесе, һәртөрле суфичыл, шагыйранә фикерләрне, әүлияви күрсәтмәләрне читкә кую, аларның асылсыз икәнлекләрен аңлау-аңлату нигезендә язу, яшәү – болар үзләре генә дә ул заман өчен күрелмәгән хәл иделәр. Габденнасыйр Курсави ислам динен хорафи карашлардан арындыру юлын ачты, рухани дөньяның таләпләрен һәм чикләрен дөрес билгеләде. Бу исә халыкны урта гасырчылыктан котылдыру, яңа заманга алып керү иде. Аның алдынгы карашларын татар дөньясының үз вакытында ук кабул итүе халкыбызга карата хөрмәт хисен тагын да ныгыта.

XVIII гасырда рухани фәлсәфә өлкәсендә Габденнасыйр Курсави мәртәбәсендә башка бер генә галим дә җитешмәде. Әмма аның шәхесе һәм өстенлеге бүтәннәрне күләгәдә калдырырга тиеш түгел.

Хәер, халкыбызда булган ул галимнәр, булган! Хәтерләп кенә бетермибез. Шундыйлардан тагын берсе – «Таузыйхи» кушаматын йөрткәне бар.

Аның даны «Тәүзыйх китабы»на мөкиббән булуыннан, аңа аңлатмалар төзүеннән килә. Ул әле башка төрле шәрех китаплары язу белән дә шөгельләнгән. Исеме – Нигъмәтулла имам, Наласа авылында яшәгән. Әтисе – Рәхмәтулла, бабасы – Иманкол исемле икәннәр. Аларның нәселе Рәхманколдан килә. Бу Нигъмәтулла ахун 1815 елда хаҗ сәфәренә китеп, Искәндәрия шәһәрендә вафат иткән, Бусыйри төрбәсе янында җирләнгән...

Түбән Оры данлыклы авыл булган. Монда иске байлар заводфабрикалар тотканнар. Суны буатып, аның көченә машиналар эшен корганнар. Кайсыларының субайлары әлегә кадәр сакланган. Түбән Оры авылы иңкүлеккә, тирән казан булып сузылган чокыр урынга урнашкан.

Әмма хәзер кайбер урамнары түбәннән югарыга таба менеп киткәннәр. Аңлашыла! Моның хикмәте генә түгел, сәбәбе дә бар.

Оры авылында ул хакта искә алуны хәерсез бер гамәл кебегрәк белсәләр дә, тирә-күрше авылларында аны вакыйга итеп сөйлиләр. Чөнки даны китапларга кергән. Тарихларда да «Оры

туфаны» буларак искәртелә[1]. Ул инде, телдән-телләргә йөри-йөри, гасырдан-гасырга күчеп килә-килә, безнең дәвердә дә сөйләнелә. Миңа аны Кызылъярда кат-кат сөйләделәр.

Бик эссе җәйге вакыт икән. Оры авылына бер ак бабай килеп, йорттан-йортка йөреп, эчәргә су сораган. Әмма аңа су бирмәгәннәр. Бары бер яшь кызның гына мәрхәмәте килеп, аңа су чыгарган.

Бәлки вакыйгалар шуның белән бетәр дә иде, әмма бу кызның әнкәсеме (әллә әткәсеме?) бик усал кеше икән. «Аңа нигә су бирдең?» – дип, кызын тәмам орышкан, тәмам орышкан... Бу хәлгә түзә алмыйча ак бабай, ишетеп торган җиреннән: «Авылыгызны су йотсын», – дип, каргап дога укыган.

Ул китүгә, озак үтми, күктә кара болыт чыга, бик көчле җил күтәрелә һәм коеп яңгыр ява башлый. Һәммә тарафтан сулар күтәрелеп, Түбән Оры авылын баскан, халкын, малы-туары белән бергә, агызып алып китеп, еракка илтеп ташлаган. Шул туфан суы алып барып тукталган урында бүгенге көндә дә шомлы агачлык һәм зират икән. Аны «Орылар яткан җир» дип аңлаталар.

Оры туфанында бердәнбер кеше – ак бабайга су биргән кыз исән калган. Үзен ачулануларга әрнеп, өйләренең кыек чормасына менеп качып, шунда елап утырганында яңгыр ява башлаган.

Берәүләр әйтәләр: «Туфанның килгәнен ул белми калган», – диләр. Икенчеләр: «Күреп торган, авыл халкын кызганып елаган», – диләр.

Бу туфан вакыйгасы чыннан да булып узган. Төгәл датасы да билгеле – ул 1817 елга карый.

Ә менә бу вакыйга тагын да гыйбрәтлерәк! Түбән Орыда ул вакытта имам-мөдәрисләрдән шөһрәтле Хәбибулла ахун яшәгән. Аның «Хәбибулла ишан» дигән даны еракларга таралган. Нурлы йөзен күрергә, аяк тузанын үбәргә әллә кайсы мишәр якларыннан да киләләр икән.

Хәбибулла ишанның нәселе зур булып, аның бабалары инде язылып узылган Янсари хафиздан килә икән. Килдеш бәк торыннарыннан болар. Кайчандыр мари яклары алар кулында булган.

---

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Өченче кисәк. Б. 144.

Җәйләрен тарантасларына атларның бары тик яхшыларын гына җиктереп, кышларын затлы бизәкле чаналарда җилдереп, туннарның да асылларын гына киенеп йөргән Хәбибулла ишан. Әтисе – Хәсән, бабасы – Габделкәрим. Хатыны да ни җитте генә түгел, Хуҗа Сәет нәселеннән килгән, Ханмирза, Котлык кебек бабалары белән дан тоткан, Оры авылының мәшһүр байларыннан Туктамыш улы Рәхмәтулланың кызы Зөбәйдә абыстай икән. Хәбибулла ахун Оры авылында таш мәчетнең имамы булган.

Әмма көннәрнең берендә авыл байларының Хәбибулла ишанга карата күңелләре суынган. Аралары бозылып, йөри торгач, ахырда, аның туганы Фәтхулла хәзрәтне ахун итеп куйганнар.

Әмма Хәбибулла ишанның мәртәбәсен санлаучылар да табылган. Тиз арада агач мәчет җиткергәннәр һәм бер мәхәллә булып аерылып чыкканнар.

Боларның икесе дә, Хәбибулла да, Фәтхулла да, ни җитте генә түгел, вәкарьле икәннәр. Мәчетләреннән азан һәм Коръән уку авазлары үзара ярышып ишетелә башлаган, берсе уразага кергәндә, икенчесе бер көнгә соңарта, гаетләрне дә берсе икенчесеннән арттырып уздыра торган булганнар. Ул ярышулары йорт-җиһаз, арба-чана, ат-дирбия, кием-салым, юл йөреш, кыяфәт күрсәтеш, беләмлек мәртәбәләренә кадәр үстерелеп, заманына күрә башы-ахыры күренмәс шайтаный бер хәрәкәткә һәм бәлагә әверелә барган. Ә моның сәбәбе, эшнең башы – мөфти хәзрәтләренең кул уйнатуыннан һәм көнчелегеннән килгән. Аңа башкалар да кушылган.

Тагын шунысы бар, Оры авылының төп халкы мишәр татарларыннан булып, алар бу якларга шактый таза хәлләрендә килеп урнашканнар һәм, гадәтләре буенча сәүдә эшләрен киң җәелдереп, татар галәмен үз мәнфәгатьләренә бик оста хезмәт иттерә башлаганнар. Икенчедән, Оры авылы халкы үз данын һәм мәртәбәсен даими күз уңында тоткан. Яхшы зиһенле, атаклы имамнар нәселеннән булган Хәбибулланы шәкерт вакытыннан дин башлыгы итеп әзерләүгә зур көчләр куйганнар.

Татар мәдрәсәләрендә аң-белем алгач, аны Бохарага җибәрәләр, анда да иң шанлы мөдәррисләрдән белем ала Хәбибулла.

Хәер, ул үзе дә акыллы шәкертләрдән була. Бохарадан Кабулга китеп, гарәп һәм фарсы телләрен камил үзләштереп, белемнәрен тирәнәйтеп һәм киңәйтеп өлгерә. Хәтта ишанлык серләренә дә төшенә. Һәм менә ул Орыга кайткач, имамлыкта аның белән ярышырлык кеше табылмый.

Тиздән Хәбибулла ишан хакында олы хәбәрләр тарала. Мәдрәсәсе даннарга күмелә. Аңа халык ихлас күңел белән бирелә. Бигрәк тә мишәрләр, мәртәбә, дан, кемлек яратучылар булаpак, аның атта узып киткәнендә: «Ишан хәзрәтләребез, бәракәт ит!» – дип, тәгәрмәч эзен ятып үбәләр, укыган догасыннан могҗизалар табалар, чана юлларын кочалар икән.

Хәбибулла хәзрәтнең даны зурлыгын сөйләүче фактлардан тагын да берсе шул, бусы – муллаларга бәйлесе... Имамлыкка дәгъвә иткән шәкертне сынау халыкта булган бит инде...

Шәкерткә, әлбәттә, төрле сораулар бирелә: «Оры шәрифкә бардыңмы? Ханәкәгә кердеңме? Тәнбиһ укыдыңмы?» – диләр. Әгәр дә Оры ишаны Хәбибулланың алдында булган, аның фатихасын алган шәкерт икән, булды гына, килешү-намә җыела, моны имам итеп сайлыйлар, Уфага, мөфтидән шәһадәтнамә алырга җибәрәләр. Әгәр: «Юк!» – дисә, нинди генә укымышлы, олы белемнәр иясе саналмасын, аңардан, ике дә уйламый баш тарталар.

Әмма бервакыт Хәбибулла хәзрәтнең дан-шөһрәтләре бәхетенә каршылык итә башлый. Вакыйга шулай килеп чыга: мөфти Мөхәммәтҗан хәзрәтләренең хаталы эшләреннән берсе хакында тикшерү мәхкәмәгә тапшырыла. Менә шунда «аның урынына Оры имамы Хәбибулланы куялар икән» дигән сүз тарала. Бу хәбәр Мөхәммәтҗан мөфтигә дә килеп ирешә. Әлбәттә, бу яңалык аның ачуын кузгаткан.

Ул Оры авылының мәчетенә ут төртеп яндырырга әмер бирә. Ярый әле бу эшкә һичкем алынмый, халык тәмам курка кала, күңелләрен аптырау баса.

Вәкарьле Хәбибулла хәзрәткә килгәндә, ул боларны белми дә кала. Үз тәртибендә яшәвен дәвам итә. Әмма Мөхәммәтҗан мөфти, мәхкәмә эшеннән имин узып өлгерми, Хәбибулла ишаннан үч алу уена төшә. Имамлыгыннан очырыр иде – белеме

олы, халык арасында хөрмәте галәмнәргәчә ашкан. Хәер, мөфти хәзрәтләре моңарга игътибар итеп тә тормас иде, юк итү эшен башкарыр иде дә... Хәбибулланың мөфтилеккә дәгъва кылмаган булуы, бары тик каршылыклы халыктан чыккан сүз аркасында гына бу хәбәрнең таралганлыгы Казан байлары аша хат белән Уфага, аның үзенә килеп ирешә. Менә шунда мөфти хәзрәтләре, мәчеткә ут төрттерү түгел, мәхәллә халкының күңеленә Хәбибулла ахунга каршы «ут ягу» эшен башлап җибәрергә кирәк таба. Даны сүнсен имеш.

Байлар арасында махсус рәвештә имамга каршы коткылар таратыла. Алар баштарак бирешмиләр. Әмма нинди иманлы кешеләрнең дә күңеленә, әүвәле, аптырау, аннары, коткы төшеп, Хәбибулладан көнләшү, аны начарга чыгару уе урнаша башлый.

Хәбибулла хәзрәткә каршы алып барылган коткыга бирелеп, байлар үзара тарткалаша башлыйлар. Тәмам үпкәләшеп, ахырда ике мәхәлләгә аерылып, Хәбибулла ишан үзенә агач мәчет төзетергә, шунда имамлык итүгә күчәргә мәҗбүр була, туганы Фәтхулла таш мәчеткә мөфти фәрманы илә ахун итеп куела. Ике туган, икесе дә имам, тәмам дошманлыкта яшәүгә күчәләр. Авылларының даны да сүнә бара. Мөхәммәтҗан мөфти дә үз дигәненә ирешә.

Бу вакыйгадан шул аңлашыла: Хәбибулла ахун белән горурланып, аңа чын күңелдән сокланып, аның дәрәҗәсе белән мактанып йөргән халык, ахырда, үзе бәлагә тарый. Үз имамнарын мөфти итеп күрәселәре килү – табигый хәл, ул Орының, аның белән бергә халкының да данын арттырыр иде. Әмма авылда, бу теләкләрнең киресен насыйп иткән вакыйга була. Бу – аларның мәгънәви туфан астында калулары түгел идеме?

Хәбибулла хәзрәт Оры авылында 1762 елда туган, 1817 елда Орыда вафат булган. Шул елны, ишанның вафатыннан соң озак та үтми, Оры авылын туфан суы агызып алып киткән. Мөфти Мөхәммәтҗан (Габдрахманов Мөхәммәтҗан Хөсәен улы, Беренче мөфти, ниндидер сәбәп белән бабасы исеменә бәйле рәвештә, ягъни фамилиясенә карап, «Габдрахман мөфти» дип йөртелгән) исә, Хәбибулла вафатыннан соң җиде ел узгач, 1824 елның 17 июнендә 68 яшендә мәңгелек йортка күченгән. Мөфтилеген

һичкемгә бирми һәм тапшырмый калдырган. Аның Әхмәт исемле улы, башка балалары кебек үк, морза титулында, зур белемле җирләр хуҗасы була. 19 яшендә Сакт-Петербургта дин эшләре министрлыгында дәрәҗәле урынга күтәрелә.

Мөхәммәтҗан мөфтинең бәхет кояшы бик тә югарыдан яктыртып, аны һәрьяктан нурландырып торган. Ул патшалар кебек яшәгән, яхшы арбаларда дүртәр ат җиктереп узып китә торган булган. Аның мәрхәмәтенә ирешү бөек саналган, каһәренә юлыкканнар, һичшиксез, һәлакәт тапкан, бәла авырлыгын татыган. Нинди данлыклы Хәбибулла ишанны да аның сәясәт тегермәне йоткан, ваклап ташлаган.

Фәтхулла хәзрәт тә төшеп калганнардан булмый, ул, ни гаҗәп, матур телле, фикерләрен ачык белдерүче кешеләрдән санала. Аның хәтта берничә әсәр һәм китап язуы билгеле. Шулардан берсе – «Рисаләте фи иттисафул-вәҗиб бил-вәхдәтүлгаддийәт», ике сәхифәдән гыйбарәт, гарәп телендә, ачык аңлаешлы һәм төзек итеп язылган. Икенче хезмәте – «Рисаләте мөһиммәт», 1872 елдан бирле Казанда еш басылган 15 битле китап. Анда ураза мәсьәләләре тикшерелгән. Өченче китабы – «Мәҗмуг». Бу китап 25 бүлектән һәм 798 сәхифәдән гыйбарәт, күләмле хезмәтләрнең берсе. Ул төрле китапларның асыл нөсхәләреннән алынган җыелма хәбәрләрдән, хашияаңлатмаларны киңәйтеп язудан гыйбарәт булып, анда хәтта Себер һәм Урта Азия ханнары Шәйбаниләр нәселеннән имам Хәсән улы Мөхәммәтнең «Җәмигуль-гараиб» китабыннан алынган материаллар да бар, алар барысы да күрсәтелеп барылганнар һәм урыны-урыны белән бәхәс тә ителгәннәр. Бу хезмәтендә ислам дине кануннары, Коръән һәм тәфсирләр, әхлак, медицина һәм башка мәсьәләр белән бәйле хәбәрләр җитәрлек. Әмма алар берсе дә аерым бер ачык максатлы фикер нигезендә бәян ителмичә, җыелма хәбәрләр бирү юлы белән төзелгәннәр.

Фәтхула хәзрәтнең болардан тыш та шактый китаплар язуы билгеле. Алар һәммәсе дә шушы «Мәҗмуг» рәвешендә төзелеп, ислам динендә булган татар халкының гореф-гадәтләре яхшылыгын аңлатып бирүләрдән, ничек гамәл кылганда дөрес һәм күркәм икәнлеген ачыклап сөйләүләрдән гыйбарәт. Бер генә

фикере дә мөселман кешенең иманына, әхлагына, табигатенә зыян итәрлек түгел.

1819 елда Диния нәзарәтенә Фәтхулла хәзрәтнең язган хатыннан аңлашылганча, Оры авылының таш мәчете халык акчасына салынган, кырык ел буена монда җомга һәм гает намазлары укылып киленгән. Хатта Хәбибулла ишанның агач мәчет төзетеп, шунда җәмәгать белән азансыз гына намазлар укуын, инде аның вафат булуын да хәбәр итә.

Һәм менә ул үз янәшәсендә һичкемне танырга теләмәвен авылда таш мәчетне генә калдырырга кирәклеген дәгъвалавын да сиздерә. Агач мәчеттә намазларның азансыз укылуын шәригатьне бозу буларак аңлата. Бу хакта ил халкына хәбәр итүне үтенә. Монысы – Хәбибулла ишанның рухын юк итү теләгеннән әлбәттә.

Картайган көнендә Фәтхулла хәзрәт үз мәдрәсәсенә мөгаллим итеп Казан шәһәренең алтынчы мәчете каршындагы мәдрәсәдә хәлфә хезмәтендә торган Габделкадыйр имам улы Сибгатулланы чакырта. Ул Оры авылына күченеп килә. Үзен намуслы, гадел, тәртипле һәм галим зат буларак таныта. Фәтхулла хәзрәтнең вафатыннан соң, рәсми рәвештә имам һәм мөдәррис дәрәҗәләрен ала. 1873 елда 75 яшендә Орыда вафат була. Сәламәт вакытында ук үз урынына улы Вәлиулланы имам итә. Тирә-күрше авылларда болар нәселеннән муллалар тарала. Мәдрәсәсе яхшы, укымышлы, тәрбияле муллалар әзерләгән.

Арча ягы укымышлыларының берсе – XVIII–XIX гасырларда Казанбаш авылында яшәгән Җәгъфәр улы Бикчәнтәй хәзрәт, аның бабасы Мөслим исемле булган. Бу Бикчәнтәй хәзрәт, Уфа шәһәренә имамлыкка имтихан тотарга килгәч, бер «Әхтәри кәбир» (гарәп сүзләренең төрки телдә аңлатмалы сүзлеге) китабы сатып алган. Аның тышлыгына бу хакта хәбәрен язып калдырган. Вафат булуы 1817 елда, Казанбашта икән.

Икенчесе – Сәйфулла улы Мөхәммәтәмин, Сарман ягы Шыгай авылы муллалары нәселеннән. Бабасы Динмөхәммәт улы Габделхәмит булган. Наласа авылында имам-мөдәррис булып, 1842 елда хаҗ сәфәренә чыгып китә. Каһирә шәһәренә җитеп, монда ил башлыгы Ибраһим патша хозурында кабул ителә. Фарсы теле мөгаллиме Габдеррәшит улы Шәмсетдиннең вафат бу-

луы сәбәпле, Ибраһим патша тарафынан Мөхәммәтәмин аның урынына Әл-Әзһар университетына мөдәррис-профессор итеп билгеләнә. Ул гомеренең соңынача үз эшен зур җаваплылык белән башкара.

Мөхәммәтәмин хәзрәт Бохарада, шәкерт булган чагында ук, Габденнасыйр Курсави белән таныша, аннан дәресләр ала һәм ул өйрәткән игътикад-иман юлын дөрес аңлап кабул итә. Дөрес фикерләве, хәтере яхшылык белән аерылып тора. Китаплар да язган. Аның әсәрләрен заманында Ш. Мәрҗани дә укыган. Ул аларны мактап телгә ала. Мөхәммәтәмин хәзрәт Аллаһы Тәгалә хакында Коръәндәге һәм хәдисләрдәге хәбәрләрдән артыгын сөйләүне мөселман кеше өчен бозыклыкка һәм ислам дине каршында җинаятькә санаган. Бу хакта Оры, Кенәр, Мәңгәр имамнары белән йөзгә-йөз килеп бәхәсләшә, Габденнасыйр Курсави фикерләрен өстенгә чыгара, хатлар алышып фикерләшә торган булган. Гадәтләре, сыйфатлары, әйткән сүзләре матурлык белән булып, язган китаплары да шул юнәлештә һәм рәвештә булганнар. Алар заманында күп галимнәрне тәрбияләүдә лаеклы урын тотканнар. Аның язган китапларыннан берсе – «Мәгадәнелмакасид», эчтәлеге һәм фикер сөреше белән төгәл аңлаешлы әсәр, авторы – «Кавәметдин Әл-Болгари» дип куелган. Бу аның галим буларак үзенә алган тәхәллүсе.

«Мәгадәнел-мәкасид» китабы Габденнасыйр Курсави хезмәтләре тәэсирендә язылган. Риза Фәхретдинов «Кавәметдин Әл-Болгари» имзасы кемнеке булуын төгәл, фәнни нигездә ачыклауга ирешкән[1]. Ул кичке намаз хакында да бер китап язып, анда үзен, автор буларак, «мөалифе –Мөхәммәтәмин бине Сәйфулла Әл-Болгари Әс-Сабави» дип күрсәткән.

Мөхәммәтәмин 1849 елда мәңгелек йортка күчenә. Гарәп мәмләкәтләрендә аны олы галим дәрәҗәсендә таный торган булганнар. Гүре Каһирә шәһәрендә. Ул – Габденнасыйр Курсави идеяләрен гарәп дөньясына таратучы һәм танытучы, ул ачыклаган сәләфият мәзһәбенә тулысынча бирелүче, мөселманнар

[1] *Фәхретдинов Р.* Асар. Алтынчы кисәк. Оренбург: Ф. Кәрими типографиясе, 1904. Б. 293.

арасында җәелдерүче, Идел–Урал ислам әһеленә карата дөнья халыкларында хөрмәт хисләрен тәрбияләүдә зур эшләр башкарган кешеләрнең берсе.

Арча ягының борынгы галимнәреннән тагын да берсе – Ашыт авылында имам-мөдәррис Сәйфелмөлек улы Габденнасыйр (Ашыти), Мортаза улы Мозаффар мулла нәселеннән булып, аның бабасы хәзерге Чүпрәле районы Чокал авылы имамнарыннан икән. Габденнасыйр имам җитмеш биш ел гомер кичереп, 1833 елда вафат була.

Ул Шырдан мәдрәсендә укый, аннары тагын берничә мәдрәсәдә белем алып, данлыклы Оры авылында Хәбибулла ишан мәдрәсәсенә килә, анда мөритлек дәрәҗәсе ала, берара Ашытта мәдрәсәдә укый. Зур белемнәр иясе булып җитешә. Ашытта аны имам-мөдәррис итәләр. Мәдрәсәсе даны тиз арада тирә-якларга тарала. Аңа Казан, Буа, Сембер якларыннан шәкертләр килә, Баһаветдин Мәрҗани дә (Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы) аңарда укый.

Сәйфелмөлек улы Габденнасыйр имам хак сөйләүче, иманы дөрес, гамәлендә шәригать кушканча эш итүче, гадәти тормыш белән яшәүче булган. Заманында Хәбибулла ишанга мөритлек итеп, аңардан иҗазәтнамә яздырып алса да, аны (ишан белән мөфти арасындагы дошманлык сәбәбендә булса кирәк) яшереп саклаган.

Хатыны Мәхбүбә исемле булып, Туктамыш байның кызы икән. Күп балалар үстергәннәр. Мәхбүбә, иреннән соң калып, 1842 елда вафат булган. Кабере Ашыт зиратында.

Габденнасыйр Ашыти бик тә диндар кеше икән. Аның әүлиялек сыйфатлары да күренгән, изгелек һәм сафлык-гыйффәте һәммә чалымнарыннан сизелеп торган.

Аның җеназасында олы имамнар катнаша. Арадан Сөбханкол Мәрҗани улы Баһаветдин, аның укучысы һәм Шиһабетдин Мәрҗанинең атасы: «Ашыт зиратында вәли кабере бар. Халык, ышанып, аның каберен зиярәт итеп йөресәләр дә, бу көн бу вәли дәфен кылынды», – дип әйткән, ягъни, тагын бер изге кешенең кабере өстәлде, дигән.

Хәзер «изгеләр зираты», «әүлия күмелгән җир» дип йөртелгән каберлекне ул заманнарда «вәли зираты» дигәннәр. Мәсәлән,

Биектау районы Камай (Иске Казан) авылы каршында, Чагыл тау башында, Төньяк тарафта Изгеләр зираты бар, анда мәчет салганнар, чардуганнар корганнар, чишмәсе дә матур итеп эшләнгән. «Анда Мулла хаҗи күмелгән», – диләр. Иске заман Сәрдә имамнарының бу зират белән бәйле гаугалы гамәлләре хакында документлар аша безгә килеп ирешкән хәбәрләрдән күренгәнчә, анда Әремле хуҗа һәм аның кызы Гайшәнең гүрләре икән. Ерак түгел урнашкан Айшә авылы да шул Гайшәбикәгә нисбәтле булса кирәк? Әмма Казан артында Гайшә каберләре берничә урында. Аларда чыннан да Гайшә исемле изге кеше күмелгәнме, әллә гомумән дә изге хатын-кызны Гайшә исеме белән атау тәртибе булганмы – бу мәсьәлә ачыкланыр. Күз тиюләрдән «Фатыйма кулы саклый», диләр. «Гайшәбикә кабере» дигәннәре дә, халык уйлавынча, шундый бер ырым-күзаллауларга бәйле, хикмәткә ия түгелме икән?

Әремле хуҗа бу яклар кешесе түгел. Аның «хуҗа» дип аталуы бер-бер әүлия-ишан кебек бөек кеше булганлыгы хакында сөйли.

Арча ягының борынгы галимнәреннән тагын да берсе – Олы Мәңгәрнең имамы Кытый улы Сафакол хәзрәт. Төп чыгышы белән ул Кырым татары булган. XVI гасырда аның бабасы сугышта әсир төшеп, монда китерелгән, аны Килмәк исеме белән атаганнар. Оныгы Сафакол, гыйлемдә алай ук маһир саналмаса да, диндарлыгы, тәүфыйгы белән халыкның мәхәббәтен яулап алган. Коръән һәм догалар укыганда ясаган хата һәм кимчелекләре өчен, дога артыннан өстәп, аерым бер гафу үтенү («укыганда ясаган хата һәм кимчелекләребез өчен гафу әйлә» дип сорау) гадәтен догачылар теленә ул керткән. Кыска төннәрдә ясигъ намазын ташламаска, витр намазларын да укып барырга халыкны өндәгән. Мөфти каршындагы «Җәмгыяте-шәргыя»да берничә тапкыр әгъза булып торган, Габдессәлам мөфтинең хөрмәтен казанган.

Сафакол хәзрәт озын буйлы, олы сакаллы, мәһабәт кешеләрдән икән. 1835 елда 78 яшендә вафат булган. Балалары да имамлык дәрәҗәләренә ирешкәннәр, ә икенче улы Мөхәммәт аның урынында муллалык иткән.

Бу якларның тагын бер галиме – Габденнасыйр Курсавиның олы абыйсы Габделхак. 1843 елда вафат була, Курсада җирләнгән. Шушы авылның таш мәчетендә имамлык хезмәтендә торган, мәдрәсә тоткан, анда мөдәррислек иткән.

Яшьлегендә үз авылларында һәм төрле зур мәдрәсәләрдә белем алгач, Бохарага китә һәм Ниязколый Төрекмәнинең мөрите хезмәтендә тора.

Хаҗ сәфәренә Габденнасыйр һәм Габделкәрим исемле туганнары белән бара. Әмма берникадәр вакытка Каһирәдә кала һәм монда тәҗвит гыйлеменнән дәресләр ала. Коръән укуда аның кебек оста кешеләр булмаган диярлек. Шәкертләрен бу гыйлемгә өйрәтүгә күп көч куйган. Коръәнне дөрес уку серләрен Диәрбәкер мөфтисе Әбу-Сөгуттан өйрәнгән. Башка төрле рухани гыйлемнәрдә үзенең остазы дип энесе Габденнасыйрны санаган. Хәдисләр китабы төзеп, аны китапчылар бик еш бастырып таратканнар, алардан файда тапканнар.

Габделхак хәзрәт шәкертләренә Коръәнне хатасыз, камил рәвештә өйрәтеп, аятьләргә һәм хәдисләргә дөрес һәм тугры шәрехләр бирә, бу мәсьәләләрдә катгыйлыкны, җаваплылыкны таләп итә торган булган.

Вафатыннан соң имамлык эше Газизә исемле кызының ире Хәмит улы Хәсәнгә кала.

Арча ягы тарихыбызда бөекләрне аз бирмәгән. Аларны барлау юлында килеп туган каршылыклы мәсьәләләрне ачыклауда гыйльми экспедиция материалларының әһәмияте чиксез. Сәфәребездә, бөтенләй көтелмәгәндә, Шиһабетдин Мәрҗаниның әлегә фәнгә мәгълүм булмаган хезмәтенең кулъязмасы табылды. Аны саклаганы һәм безгә тапшырганы өчен Арча районы Байкал авылыннан гомере буе колхозда эшләгән Ахунова Галиябану Габделфәрт кызына чиксез рәхмәтлебез. Ул китап аңа кайнанасы Газизә Хәким кызыннан (1901–1970) мирас булып калган.

Шиһабетдин Мәрҗанинең әтисе Баһаветдин исемле булган. Ул 72 ел гомер кичереп, 1856 елда вафат булган. Аның кабере Ташкичү зиратында. Гомере буе ул шушы авыл мәчетенең имамы вазифасын башкарган, мәдрәсә тоткан һәм анда мөдәррислек иткән. Баһаветдиннең әтисе – Сөбханкол Мәрҗани, аның әтисе

Габделкәрим исемле булган. Шушы Габделкәрим хәзрәт исә чыгышы белән Мәрҗан авылыннан. Ул авыл хәзер Япанчы исемен йөртә һәм Әтнә районына карый.

Нәсел башлары Габделкәрим хәзрәт Мәрҗан (хәзергечә Япанчы) авылыннан булганга, үзен «Мәрҗани», ягъни «Мәрҗан авылы кешесе» дип йөрткән. Шуның сәбәпле аның нәселенә дә «Мәрҗани» кушаматы йогып калган. Хәер, алар үзләре дә исемнәренә «Әл-Мәрҗани» тәхәллүсен өстәү гадәтен алганнар. Бу кушамат данлыклы галим уллары Шиһабетдингә дә, аның икетуган энесе язучы Мәхмүт Галәүгә дә күчкән. Берсе – Шиһабетдин Мәрҗани, икенчесе Мәхмүт Мәрҗани. Дөрес, Шиһабетдин Мәрҗани хәтта «Әл-Казани» имзасын да алган. Әмма тарихларга ул – «Мәрҗани», энесе – «Галәү» булып кереп калганнар. Шиһабетдин Мәрҗани исә тумышы белән Арча районы Ташкичү авылыннан булган. Аның атасы Баһаветдиннең беренче хатыны Ашыт авылыннан Сәйфелмөлек улы Габденнасыйрның кызы икән дә, әмма, вафат итүе сәбәпле, ул аның сеңлесен кияүгә алган.

Баһаветдин Мәрҗани Бәрәскәдә Ибраһим улы Бикчәнтәй мөдәррис мәдрәсәсендә, аннары Ашытта булачак бабасы (хатынының этисе) Габденнасыйр имам-мөдәррисітә, аннары Бохарада Рәхмәтулла улы Гайсә, Нәдер Хөҗәнди улы Салих мөдәррисләрдә белем алган.

Баһаветдин Мәрҗани мәдрәсәсендә Казан арты һәм Буа ягы шәкертләре укыганнар һәм үз чорларының данлыклы белем ияләре, имамнары буларак танылганнар.

Хатларыннан аңлашылганча, улы Мәрҗанигә киңәшләре белән дә, тарихи мәгълүматлар җыюда да ярдәм иткән, кайбер фикерләрен бәхәс итеп, гыйльми нигездә раслауда юнәлешләр дә биргән.

Тагын да бер галим – Оры авылы Галләм Хафиз нәселеннән Габдерразак мулла улы Ягъкуб хәзрәт. Ул, Риза Фәхретдиновның «Асар»да язуыннан аңлашылганча, заманында иң белемле кешеләрнең берсе булган. «Хөкем лаихәләре шулкадәр тәртипледер ки, буның кеби хөкем матдәсене тугыры асаслара бина идеп язан кемсә Собраниядә тордыгы бәңа мәгълүм

улмады, – дип белдерә ул. – Бәңа күрә бу зат тугъры фәһемле, зиһенле, гакыллы, вәкарьле һәм дә мәсләкле вә кермеш юлының ахырына чыкар ичүн гайрәтле бер адәмдер». Габдерразак хәзрәт Диния нәзарәтенә берничә тапкыр утырышчы итеп сайлана, шәригать кануннары нигезендә хөкемнәрне дөрес алып бара, дин эшләренә бәйле күзәтчелек эшләрен тигез йөртә. Мөфти белән даими хат алышып торучыларның берсе. Ул 70 ел гомер кичереп, 1869 елда Иж-заводта вафат була. Аның әнисе – Әсфәндияр байның кызы Шәһәрбану. Тирә-күрше авылларда бу нәселдән күп кенә имам-мөдәррисләр хезмәт иткән.

Алга таба 2016 елда Арча районына уздырылган комплекслы экспедиция вакытында табылган кулъязмаларның тасвирламалары тәкъдим ителә.

## 2016 елда Арча районына уздырылган комплекслы экспедиция вакытында табылган кулъязмаларның тасвирламасы

**Арча**

**№ 1: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,8×17,4 см. Сакланышына карaганда, кесәдә йөртер өчен һәм башкаларга уку максатында эшләнелгән. Мондый текстларны төрле аш мәҗлесләрендә һәм авыруларны сихәтләндерү өчен өшкергәндә укыганнар.

2. Арча районы Түбән Оры авылында табылды. Иске йортны сатып алган хуҗалары, өй кыекларын сүткәндә, чормадан чыккан китапларны, ташларга кызганып, саклап калдырганнар. Шулар арасында бу язма китапчык та була.

3. Язу карасы белән эшләнгән, узган гасырның урталарында төзелгән. Язу карасы зәңгәр төстә, урыны-урыны белән шәмәхә төскә күчә. Бу аның төрле вакытларда язылуы хакында сөйли. Мөгаен, башка бер нөсхәдән яки язмадан күчерелгәндер дигән фикергә этәрә. Үзе иҗат итүе дә ихтимал.

4. Татар телендә, гарәп графикасында. Язуы уртача, хаталары да очрый.

5. Дүрт сәхифәдән гыйбарәт. Авторы һәм күчерүчесе күрсәтелмәгән. Олы яшьтәге абыстай кеше язган булуы сиземләнә. Үзе хакында 1 б биттә шул хәбәрне калдырган. Догалар һәм күчермә сүрәләр булуы да бу фаразны раслый.

6. Алга таба (2 а биттә) догаларның нинди рухларга багышланырга тиешлеге хакында хәбәр бирелгән. Ул суфичылык традицияләре нигезендә төзелгән һәм татар халкының борынгы ышануларына, дини йолаларына барып тоташа, эчтәлеге белән тарихи-мәдәни әһәмияткә ия:

Җылкылар пире Балык атага дип укылыр,
Сыгырлар пире Зәнки атага дип укылыр,
Куйлар пире Чобан атага дип укылыр,
Игенчеләр пире Адәм галәйһис-сәлам дип укылыр,
Тегермәнчеләр пире Баба Пәһлеванга дип укылыр,
Кәҗәләр пире Локман Хәкимгә дип укылыр,
[Бер кемсә] пире Байхуҗага дип укылыр,
Сәүдәгәрләр пире шәех Гатауллага дип укылыр,
Кәрван пире Әхмәт Хәмиткә дип укылыр,
2 б Йитмеш пирнең башы Әхмәт Хәркам дип укылыр

Алга таба Әхмәтҗан исемле берәүнең күп ашавы һәм үлеме хакында тезмә килә. Аңа «Илаһи бәет» дигән исем бирелгән. Башка бәетләре дә аның турында. Алары да татарча, шул ук бәетне кабат эшләгән булуы да ихтимал.

**№ 2: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,0×17,4 см. Сакланышы уртача, урыны-урыны белән начар. Тулы түгел. Эчтәлегенә караганда «шәкерт дәфтәре»нә охшап тора. Кесәдә йөртер өчен уңайлы итеп ясалган. Димәк, аны еш укыганнар.

2. Арча районы Түбән Оры авылында табылды. Иске йортны сүткәндә, кәгазьләр арасыннан килеп чыккан. Кемнеке икәнлеген белмиләр.

3. Каурый каләм белән эшләнелгән, 15 сәхифәдән гыйбарәт. Күчермә булуы аңлашылып тора.

4. 1 а–2 а битләрендә гарәпчә-татарча сүзлекчә бирелгән. 2 б биттән 5 а биткә кадәр гарәпчә догалар күчерелгән.

5. Алга таба (5а биттә) мондый язуы бар: «Тәмам язып бетердем. Әхмәт-Салих Ирмашев, 1910 нчы сәнә, 15 гыйнвар, чәршәмбе көн тәмам булды!» Шушы язудан чыгып кульязманың хуҗасы Ирмашев Әхмәтсалих исемле кеше булганлыгын, 1910 елның гыйнварында аны төзеп бетерүен белдерә алабыз.

**№ 3: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,7×16,4 см. Уртача сакланышта, урыны-урыны белән буталган, башы-ахыры югалган. Форматы белән кесә дәфтәре. Гарәп графикасындагы язмалардан гыйбарәт. Татарча. Эш дәфтәренә охшап тора. Бәлки берәр агроном иясә кырчылык-игенчелек, бакчачылык белән шөгыльләнгән кешенекедер?

2. Арча районы Түбән Оры авылында табылды. Иске йортны сүткәндә, кыек астында сакланган кәгазьләр арасыннан чыккан.

3. 17 сәхифәле. Көндәлек табигать торышын тикшереп барган язмалары 6а биттән башлана. 1922 елгы һава торышын күзәтүләре 5 а биттә бар. Болардан чыгып, дәфтәрне авторы 1922, 1923, 1924 елларда алып баргандыр дигән нәтиҗәгә киләсең.

4. 1а биттә «Менә шушы язуда язылган исемнәрдән карагыз. 12 октябрь, 49» дип язып куелган. Кирилл хәрефләре белән грамоталы язылган. Башка кул язуы. Ә өстәрәк «1927 нче ел» дигән гарәп хәрефле язу бар.

5. 1 б биттә «Гариза. С. Мәхмүтов. 1890 нчы елда 9 октябрьдә туган. Герман сугышында булып һәм кызыл гаскәр хезмәтеннән 1920 нче елны кайтып, шул елдан бирле Орыда торучы» дигән язу бар. Гарәп графикасында.

6. Шушы мәгълүматлар нигезендә бу кулъязманың 1920 һәм аннан соң язылуын, куен дәфтәре булуын, шул еллардагы татар авылы кешесенең мәдәни дәрәҗәсен чагылдыруын, хуҗасының С. Мәхмүтов икәнлеген, Беренче бөтендөнья сугышында катнашуын, Гражданнар сугышында булуын, кызыл армия солдаты икәнлеген, 1920 елда Орыга кайтуын һәм игенчелек белән шөгыльләнеп яшәвен билгели алабыз. Дәфтәр әле 1949 елда да кемнәрнедер кызыксындырган. Алар аннан ниндидер исемлек эзләгәннәр. Әмма ул исемлек язылган бите ертылган.

**№ 4: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,0×17,0 см. Уртача сакланышта, кара төстәге кара белән язылган. Каурый каләм язмада, кәгазе – XIX йөз ахыры – XX йөз башыныкы. Кесә дәфтәре итеп төпләнгән.

2. Арча районы, Түбән Оры авылында табылды. Өй кыегы астында төреп сакланган булган, иске йортны сүткәндә табылган.

3. 94 сәхифәле. Татарча, урыны-урыны белән гарәпчә догалары да бар. Чисталык хакында, тәһарәтле йөрү мәсьәләләре хакында язма белән ачыла. 5 а сәхифәгәчә фарызлар хакында. Алга таба догалар.

15 биттән Коръән уку шартлары хакында бәхәс, язма татар телендә.

19 б биттә «Сибгатулла Хәлил» дип язган.

24 б биттә «солтан хуҗа Әхмәт Яссәвигә, дүшәмбе көн Ибраһим Әдһәмгә, чишәмбе көн солтан Исмәгыйльгә, чәршәмбе көн солтан Мөхәммәт Хөсрәвигә, җомга көн солтан Кирманига багышлый» дип язылган.

33 биттә мөнәҗәт бирелә.

40 биттән басма китаплар теркәлгән.

46 биттән «Сураи минел-Коръән» басма китабы («Ясин шәриф», Казан меәаны Фәтхулла Хәмидулла угылы Имашев акчасына Казан университеты басмаханәсендә, 1893 елда басылган).

52 а биттә мөритләр исемлеге.

80 а биттән җомга намазлары хасиятләре хакында хәбәрләр язылган.

**№ 5: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,5×18,0 см. Кара төстәге кара белән язылган. Уртача сакланышта, кесә дәфтәре буларак төпләнгән.

2. Түбән Оры авылыннан табылган. Тәүбә китапчыгы буларак тарихи-мәдәни әһәмияте бар.

3. Татарча.

1 а биттән «Бәдәвам» әсәре.

2 а биттән «Бәдәвам» башлана.

3 а биттә дога бирелә.

4 б биттән «Бәдәвам» кабатлана.

5 а биттән яңадан «Бәдәвам» тексты.

10 бит буш.

11 а биттән имансызлык хакында бәхәс һәм яңадан «Бәдәвам» тексты.

15–16–17 битләр буш.

18 а биттән яңадан «Бәдәвам» тексты.

18 б бите буш.

19 а биттә «бисмилла» язылган. Ул сызып ташланган.

19–21 битләр буш.

22 а биттән яңадан «Бәдәвам» тексты.

**№ 6: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,5×16,5 см. Башына басма догалык китапчыгы тегелгән. Алга таба кулъязма өлеше башлана. Намаз үзенчәлекләре һәм аларның шартлары турында бәхәс язылган.

2. Арча районы Түбән Оры авылында табылган. Сакланышы уртача. XIX гасыр ахырына карый. Каләм карасы белән эшләнелгән. 14 биттән гыйбарәт.

3. 1 а биттән намаз тәртипләре хакында.

4 а биттән Коръән аяте һәм догалар урнаштырылган.

**№ 7: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,5×16,5 см. Кара кара белән язылган. XIX йөз ахырына карый.

2. Арча районы Түбән Оры авылында табылган.

3. Эчтәлеге:

1 а биттән зиналар бәяны бирелгән.

2 б биттән зинадан саклану догасы бирелгән.

3 а биттә «Тәүбә догасы осбудыр» диелгән.

8 а биттә кирилл хәрефләре белән «Каюм Макшаев» дип, шәмәхә каләм белән язылган. Тышлыгы да булган булырга тиеш.

**№ 8: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×18,0 см. Сызыклы куен дәфтәренә кара һәм зәңгәр каралар белән язылган. 45 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Арча районы Байкал авылыннан табылган.

3. Сугыш бәетләре җыентыгы.

2 а биттә «Иске солдат бәете» башлана.

5 а биттән кабаттан шул ук сугыш бәете.

11 а биттә «Ошбуны язган Сабирҗан кызы Бибинаймә» дигән язу бар.

*Беренче шигырь*

Лә иләһе илләлланның карамагыл азына,
Лә илаһе илләллаһ ул мәңге бетмәс хәзинә.
Лә илаһе илләллаһны салма телдән бер заман,
Лә илаһе илләллаһтан айрылган кол – бик яман,
Лә илаһе илләллаһ ул гаиб малны таптырыр,
Лә илаһе илләллаһ ул һәркем ризкын артдырыр.
Лә илаһе илләллаһ ул Гарше Көрси баскычы,
Лә илаһе илләллаһ ул сигез оҗмах ачкычы.

Моннан соң Г. Тукайның «Уку» шигыре килә.

11 б биттә «Шәмсеҗиһан бәете».

12 а биттә шушы ук бәетнең кабаттан күчермәсе.

12 б биттә ат муенына тага торган дога.

13 а биттән «Гыйбрәт-намә» күчермәсе.

14 б биттә «1938 ел» дип, соңрак булса кирәк, карандаш белән язылган.

15 а биттән 16 б биткәчә мөнәҗәт килә.

17 а биттән зәңгәр кара белән шигырьләр күчермәләре килә.

21 а биттә Г. Тукайның «Бишек җыры».

21 б биттә «Имтихан бирдек» шигыре.

**№ 9: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×15,4 см. Алдагы кулъязмага тартым. Бер үк кеше тарафыннан эшләнгән булса кирәк. Каләм белән һәм зәңгәр кара белән язылган.

2. 12 битле мәктәп укучысы дәфтәре. Тышлыгы ясалма. Анда «Шура сигезьеллык мәктәбенең VIII б класс укучысы Фазылова Наиләнең география дәфтәре» диелгән. Дәфтәр 1971 елда фабрикада эшләнелгән. Эчтәге язмаларын гарәп графикасында башка кеше язган.

3. Эчтәлеге: 3 а биттә «Тимергали Габдуллин» дип язылган.

3 б биттә «Гыйбрәтнамә ошбудыр» диелә һәм аның тексты бирелә.

5 б биттә «Язаем бән мөнәҗәтне...» әсәре башланып китә.

6 б биттә «И балалар, менә сезгә тагын бер шигырь язамын» дип белдерә, әсәре килә.

7 б биттә «Лә илаһе илләллаһ...» тәкбире килә, аннары тәүбә догасы урнаштырылган.

8 б биттә «Ат муенына тагылучы дога» тексты язылган.

9 а биттән «Хакдин безгә фарыз улган «Аллаһ» әсәре килә.

11 а бит «Рәсүлемез әйткән...» дип башлана. Хәдис.

12 а биттән «Һәза бәйти кәза», ягъни «Кәҗә бәете» тексты урнаштырылган.

13 б биттә «Иман китер Аллаһга» әсәре, алга таба «Иллә дүрт фарыз бәяне» урнаштырылган.

16 а биттә «Ошбуны язгучы мәгълүмегез Габделхәй Гарифҗан угылы диеп белең, бер утырып хәер-дога кылың. 1916 нчы, 1915 нче күдә» дип язылган. Шушы ук биттә алга таба «Басылып чыккан сугыш бәетләре» башы астында бәетләр бирелә.

21 а биттә «Ошбуны язучы Габделхәй бине мулла Гарифҗан угылы» дип белдерелгән язуы бар. Кызыклы язмаларыннан берсе – «Һәза Куян бәете» (Бусы «Куян бәете»)

15 а. Алачыгым бар иде, Алла,
Оячыгым бар иде, Алла,
Унике балам бар иде, Алла,

15 б Унике балам алдылар, Алла,
Яшь йөрәгем ярдылар, Алла,
Муйныма пычак салдылар, Алла,
Кырга чыксам, кешеләр күп, Алла,
Авылга кайтса(м), этләр күп, Алла,
Мин кешегә тимимен, Алла,
Кеше миңа тиядер, Алла,
Туң усакны кимрә-кимрә, Алла,
Тешем суйлак булды инде, Алла,
Туным кар өстендә йөгрә-йөгрә, Алла,
Аягым тунгак булды, Алла,

Кисек астында ята-ята, Алла,
Кабыргам сынып бетте инде, Алла,
Эт тавышын тыңлый-тыңлый, Алла,
Колагым чукрак булды инде, Алла.
Тәмәтту-тәмам, Шераст Зәүдүк, 1916 нчы

**№ 10: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,0×17,5 см. 6 сәхифәдән гыйбарәт. Карандаш белән гарәп графикасында язылган.

2. Арча районы Хәсәншәех авылында йорт кыегын сүткәндә табылган.

3. Эчтәлеге: 1 а биттә Коръәнне багышлау догасы бирелгән.

1 б биттә «Сабирҗан бине Гали» диелгән, аннары җыр бирелгән:

Быел чапкан печәнемне
Кемнәр таратыр инде?
Кеше, кирәк, матур булмак,
Кызлар яратыр иде...

2 а биттә «Анасы кабере янында бер кыз» шигыре бирелгән:

Әкертен, кил, монда – кабер,
Монда анам күмелгән,
Монда ятимә баланың
Моңлы яше түгелгән.

Өрмә, җил, сызгырма, тукта,
Куркар әнкәем, җаным,
Бирмәсәң тын зарланырга,
Кортылар тенкәм минем.

Аһ ятимлек хәлләремне
Әнкәйгә әле сөйлим,
Монда түккән зарлар эчтән
Кайгымны ялкын(лат)ыр.

Һәр сәхәр килә кочаклыйм
Мин шушы кабер ташын,
Тыңлыймын татлы сүзен һәм
Өстенә салып башым.

Ул мине сөйгән иде, коч-
кан иде шәфкать белән,
Мин хәзер калдым җиһанда
Төрлечә михнәт белән.

Кочты тар ләхет, бас-
ты бу караңгы гүр,
(Балкыт) Хода аның оясын,
Нурласын рәхмәт белән.

2 а биттә сукачы турында шигырь (гимн) бирелә:

И сукачы, булса атың
Сукаларлык ашаган,
Мәгәр булса да ядау,
Булмасын, зинһар, яман.

Сукачы, син шәп сукала,
Йирне ертып бар да бар,
Чүпләсен кортларны карга
Артларыңнан «кар» да «кар».

Тартсын атың, туктамасын,
«На» да «на» кычкыргала,
Сука тешең үткән(д)ә йир –
Калак алып кыргала.

Йир эчендә туктат атны,
Аз-аз итен тоткала,
Йирдә комнар бер дә калмас,
Бик тә тырма тырмала.

Богъдаен сип, башкасын сип,
Арышын да тарысын,
Төрле кырга чәч боларны,
Сынап кара барысын.

Яхшы орлык чәч йиреңә,
Яхшы булыр богъдаең,
Көн дә, төн дә бетмәс урып,
Бирсә әгәр Ходаең.

Йирең әгәр ком-су булса,
3 б Ошбу йиргә арыш чәч,
Чәч богъдайны, үстерер –
Туфрагың булса кара.

Яңгыры булса болытның,
Монда богъдай күп сана,
Тарыңны чәчкел чирәмгә,
Тот та аны сөр сабан.
Шундаен йирләрдә тары
Шәп булыр, булмас яман.

Алга таба түбәндәге шигырь килә:

Бу – нурлы мәктәп, укыйк күмәкләп,
Булаек без шәп, укыйк, шәкертләр!

Без яшь булсак та, укыйк яшь чакта,
Калмаек артта, укыйк, шәкертләр!

Гомерләр кыска, ятмаек бушка,
(Көздә) һәм кышта укыйк, шәкертләр!

3 б Йөрмәек уйнап, урамны буйлап,
Киләчәкне уйлап укыйк, шәкертләр!

Укыймаганнар – фәкыйрьдер анлар,
Бушка калганнар. Укыйк, Шәкертләр!

Алга таба бу шигырь килә:

Чын хурлыкта торсаң да син
Дүрт йөз ел буе, Казан,
Сөембикә манараңда
Әйтелә бу көн азан.

И манара, шатлан бу көн,
Шатлана торган көнең,
Чөнки синдә гает укый
Татар гаскәре бу көн.

И манара, ач пәрдәңне,
Кара бунда бер балкып,

Дошманнарның кулларындин
Алдык сине без тартып.

4 а И манара, кайтты бу көн
Иске тормышың кире,
Тулы өмидләргә чумды
Бу көн ислам гаскәре.

Ничә йөз ел ятсаң да син
Каты хәсрәт эчендә,
Инде кайгыңнан коткарды
Шанлы татар гаскәре.

Озакламай төшә инде
Башыңнан «орел» синең,
Һәр бинадан биек булып
Күкләргә чыкган башың.

...Инде шатлан, инде сөен,
Сөенергә хакың бар,
4 б Чөнки бу көн якыныңда
Сөембикәң рухы бар.

Яшә инде тәкыямәт,
Төшмә хурлыкга тагын,
Шатландыр бу төн ханыңның –
Сөембикәңнең җанын.

Алга таба «Фәйзрахман белән мулла Гали бәете» бирелә. 6 б биттә бу шигырь язылган:

Кыш буе һич туктамастан
Эшләгән, арган иде,
Шул сәбәптән җәйдән үк
Тик бикләнеп калган иде.

Җәй үтеп, көз җиткәч үк
Мәктәп йөзен ачты,
Ялтырап китте урамнар,
Басты нур төрле ягы.

Букчасын аскан шәкертләр
Хәлфәләрен күрделәр,
Инде башланды дәресләр,
Инде мәктәп җанлана.

Нинди шат, нинди бәхетле
Монда кергән һәр бала,
Көн саен бер яңа гыйлем,
Яңа сүз ишетәләр...

Алга таба битләре юк.

**№ 11: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×17,5 см. Кызыл кара белән язылган. Шигырьләр. 19 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Арча районы Хәсәншәех авылында йорт кыегын сүткәндә табылган.

3. Эчтәлеге:

1 а биттә «Иман кәлимәсенә бәйле һәм зекер әйтү тәртибендә шигырь килә.

2 а биттә «Бисмилла дип башладым бу бәетне язарга,
Без мескеннәр тоткында, чыгардыр бер... »
шигыре урнаштырылган.

2 б биттә «Тәһарәт фарызлары хакында» шигырь килә:

«Әүвәл йөзеңне югыл,
Маңлайдан суны койгыл,
Яңак астыңны ю,
Йөзең ак булыр сәнең...»

3 б биттә мондый мәгълүмат бар: «1916. Ошбуны хуҗа Сабирҗан кызы Наймә Габдуллина диеп белерсез, укып бер дога әйләрсез».

4 б биттә «Мөхәррәм. Шигырь» дип, алга таба әсәр язылган.

5 а биттә «Мең өч йөз егерменче һиҗрия» дип белдерелгән, ул Милади ел исәбе белән 1902 елга туры килә.

6 б битендә «Гакыллы бала тавышы» шигыре урнаштырылган:

Кояш чыкты, нур балкыды,
Тәрәзәдән һәм калкыды,
Уян, атам, атам, уян,
Уяныргa вакыт җитте!

Безләр татарның баласы,
Кайда безнең хан каласы?
Бар да бетмеш, бар да үтмеш,
Инде безләр ни кыласы?

15 б биттә «Хикәяте җәдидә» һәм башка шигырьләр.

**№ 12: Я**

1. Кульязма китапчык, 11,0×17,5 см. Татар телендә, гарәп графикасында. 18 сәхифә теркәлгән. Карандаш һәм шәмәхә кара белән язылган текстлардан гыйбарәт.

2. Арча районы Хәсәншәех авылыннан. Татарча. Гарәп графикасында. Карандаш һәм шәмәхә кара белән язылган.

3. Эчтәлеге:

1 а биттә дога: «насыйпны сорау».

1 б биттә кызыл кара белән мөнәҗәт бирелгән.

3 а биттә карандаш белән мөнәҗәт язылган. Дәвамында – шигъри дога-мөнәҗәт.

4 б биттә карандаш белән мондый язу бар: «Әхмәтҗан Хәкимҗан... җан Нәҗип Закир Габделхак Васил»

5 а «Сәламәт. Ошбуны язучы Мөхәммәт Нәҗип Әхмәтҗан Мөхәммәтҗан угылы... » дигән карандаш язуы бар.

5 б биттә догалык-мөнәҗәт карандаш язуы белән бирелгән.

6 б биттә кызыл кара белән «Кол-кол Сәрҗиһан» догасы бирелгән.

7 а биттә карандаш белән «Иман» шигыре урнаштырылган.

7 б биттә карандаш язулы «Бисмилла» шигыре язылган.

8 б биттә карандаш белән «Иман китер» шигыре язылган.

9 а биттә «Васыятьнамә» шигыре зәңгәр кара белән язылган.

13 б биттән «Тәкый гаҗәп» әсәре зәңгә кара белән күчерелгән.

**№ 13: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,5×17,5 см. Яшел кара белән язылган. Шәмәхә каралы язулары да бар. Тышлыгы кара кара белән эшләнгән. 54 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Түбән Оры авылыннан. Арча районы.

3. Әүвәлге битләре тузган. 54 сәхифә күләмендә. Шигырьләр һәм мөнәҗәтләр җыентыгы.

4. Эчтәлеге:

5 б биттә мөнәҗәт бирелгән.

6 б биттә «Ошбуны язгучы мәгълүмегез Бибнаймә бине Сабирҗан кызы диеп беләсез, утырып хәер-дога кыласыз» дигән язу карандаш белән язылган.

7 а биттә яшел кара белән уянуга чакырган шигырь бирелгән.

8 а биттә яшел кара белән шигырь бирелгән:

Азат икән бунда бәнем газиз башым,
Кичә-көндез агадыр күздин яшем...

9 б биттә «Тәһарәт фарызлары турында» мөнәҗәт язылган. Алга таба үгет, тәрбия шигырьләре килә.

24 б биттә «Сак вә Сок хәлләре» әсәре урнаштырылган:

Дөньяда ниләр булмый.
Бәндәләр ниләр күрми,
Бәндәнең күргән эше
Матурдин тышта йөри.

Игезәк ике ир бала
Берәүгә Аллаһ биргән,
Мәхшә булганнар болар,
Гомергә хәсрәт күргән...

25 а биттән текст кызыл карага күчә.

26 б биттән яшел кара белән яза.

29 б биттә зәңгәр караны куллана. Мөнәҗәт бирә.

30 а биттә тәүбә догасы килә. Аннары зәңгәр кара белән яза:

Безнең Казан каласында
Уйнаталар граммофон,
Нурлы йөзләрне саргайта
Кара кашлы бер матур...

30 б биттә яшел кара белән балаларга нәсыйхәт иткән шигырь бирә.

37 б биттә «китапларга иман» хакында сүз бара.

40 б биттә кызыл, шәмәхә, зәңгәр каралар белән аралаш язмалар бара.

41 б биттә «Яңа җиңгәчәй көе» җырының тексты бирелә:

Сандугачың булаем,
Күкрәгеңә кунамын,
Икегез дә бигрәк матур,
Кайсыгазга булаем?..

40 б биттән «Инану-Иман догасы» башлана, аннан соң шигырьләр күчерелгән.

**№ 14: Я**

1. Кулъязма китапчык, 13,0×21,0 см. Карандаш язулы. Сызыклы дәфтәрдән гыйбарәт. 14 сәхифә күләмендә.

2. Театр уенына әзерлек максатыннан күчереп эшләнгән текстка охшый. Башкарылучы рольнең сүзләре язылган.

3. Арча районында Кызылъяр авылыннан табылган.

4. Эчтәлеге:

1 а, б битләре буш.

2 а биттә «Кунакка җыелган егетләр чыктылар. «Син безне көчләп урыс ясаргамы» дип, тотындылар тегене кай җире кычыта. Аның артыннан казагы кергән иде, анысын да кыйнадылар, эштән чыгардылар...» монологы, М. Галәүнең «Мөһәҗирләр»еннән алынганга охшый. Аннары буш битләр килә.

6 а биттә «Ай бәгырем, вай бәгырем» җыры тексты бирелгән.

Без ал идек, гүзәл идек,
Без болай түгел идек,
Бар сандугач сайраган күк
Сайраша торган идек...

6 б биттә:

Аргы җактын бирге җакга
Чыгар идем өч атлап,

Бер генә кич кунар идем
Зифа буең кочаклап...

7 а биттә тагын бер монолог бирелә.

9 а биттән 11 б биткәчә буш.

11 а биттән 12 б биткәчә тагын бер монолог (битнең асты өскә куелган).

14 б биттә «көлдегеч-мәзәк» тексты бирелгән. Әсәрнең исеме «Очрашу түбәнлегенә» дип күрсәтелгән.

Тексты: «Очрады көннәрдә бер көнендә миңа бер яшь кеше. Яшь булып та, калмаган агызында ялгыз бер теше. Мин аңар әйттем: «Нәгаҗәп!» Вә сорадым гыйльләтен. Аңладым: ул бик сөя, имеш, үзенең милләтен. Йоклый алмый уздыра, имеш, бу адәм төннәрен. Милләт уенда кылмыш тереклек көннәрен, милләтнең түбәнлегенә кайгыручы бу адәм һич».

**№ 15: Я**

1. Кулъязма китап, 16,0×20,0 см. Мәктәп дәфтәрләреннән гыйбарәт. Берсенең тышында 1952 елда фабрикада эшләнгәнлеге язылган. Тышлыгындагы адрес урыны болай дип тутырылган: «Балтач урта мәктәбенең 8 Е класс укучысы Нуриева Факиянең алгебра дәфтәре».

2. Арча районы Байкал авылында табылган. 25 сәхифә күләмендә.

3. Сәхифәләренә төрле догалар язылган. Димәк, укучы бала дәфтәренә әбисе догалар күчереп язган. Догаларның хасиятләре хакында аңлатмалары да бар. Текстлар укучы карасы белән язылган, гарәп графикасында, татарча. Көндәлек вакыйгалар теркәлгән урыннары да бар.

18 а биттән мәхәббәт әсәре башлана, шигъри, озын.

**№ 16: Я**

1. Төпләнгән кулъязма китап, 17,0×20,8 см. Тышлыгы юк. Гаҗәеп матур язулы. Чиста ак кәгазьле. XIX гасырның икенче яртысына караганлыгы беренче карашка ук аңлашылып тора. Язулары кара һәм шәмәхә каралар белән, каләм язуы белән башкарылган. Ас-койрыклы хәрефләрен матур итеп түгәрәкләп язуы

үзенчәлегеннән чыгып, авторының тормышчан фикерләр, мөстәкыйль һәм төгәл белемнәр вә асыл мәгълүматлар иясе икәнлеге аңлашыла. Грамоталы. Ашыкмыйча язган. Әмма кайбер урыннарда биттән читкә чыгулары да күзәтелә. Тулы, әмма тышлыгы юк.

2. Китапны Арча районы Байкал авылы Ахунова Галиябану Габделфәрт кызы шушы көнгә кадәр саклаган. Ире дә Габделфәрт. Кайнанасы мирасы икән. Үзе гарәпне укый белми. Гомере буе сыер савуда эшләгән. Ире балта остасы икән. Хәзер авырып ята.

3. 1 а тышлык битендә мондый язу бар «Гыйлем берлә тасвир мәрадиф. Бу тасвир дүрт төрле...» («Белем белән куәтле тасвир. Бу тасвир дүрт төрле...»).

1 б биттә күзнең күрү үзенчәлекләренә бәйле схематик сызым бирелгән. Аннан аңлашылганча, автор күздә сурәтләрнең башаяк борылуын белмәгән, аларны турыдан-туры чагылалар дип күзаллаган, әмма предметларның ераклашкан саен зуррак булырга тиешлеген дә күзаллаган. Боларны схемага салып аңлаткан.

2 а бит. Тасвирламада күзләрнең күрү үзенчәлекләре һәм аңда чагылыш хакында трактат икәнлеге аңлатыла.

4 а бит. Комментарийлар. Гарәпчә.

4 б бит. «Бәхәсел-мөгаләмәт» бүлеге башлана.

5 б биттә, текст ахырында: «Әл-мескин Әбүл-Хәйр Мөхәммәт Мөгынетдин...» дигән язу бар.

6 а биттә зәңгәр кара белән «Әснәгыйдүн фил китабәт бил каләм» дигән язу килә, ягъни «Каләм белән язуда сәнгатьчәлек» дигән бүлек башлана.

7 а биттә сәхифә уртасыннан язу кара карадан зәңгәр карага күчә. Фәлсәфи гарәп сүзләренә татарча аңлатмалар бирелә башлый. Комментарийлар икәнлеге аңлашыла. Алга таба да язу татарча бара.

8 а биттән «Дәрсе рабигъ» дигән бүлек башлана. Шушы «Дүртенче дәрес» дип аталудан китапның дәрес бирү өчен, мәдрәсәдә укыту өчен төзелгәнлеген аңларга була. «Тәүхидүн-мохтар» дип куелган. Бусы хакыйкатьне танып белүдә татарча фәлсәфә дәресе. Ул герменивтик анализ белән үрелеп бара.

13 а биттә «Шәех Әр-Рази кәләменнән мәфһүмдер» дип, ягъни шәех Әр-Рази сүләреннән аңлашыладыр дип, аерым бүлекчә башлап китә.

14 а биттән «Тәваифе-ислам» (Ислам нигезләмәләре фәлсәфәсе башлана).

15 б биттә өске урында «271 нче нурда» дигән язу аерым тора. Аннары гарәпчә бүлек килә: «Вилаяте шаһидателгайн» (Күз белән күреп белү өлкәсе) килә.

33 б биттән зәңгәр кара белән язу башлана. Кайбер сәхифәләре кафиле, аңлатмалары һәм шәрехләр белән.

68 б биттән татарча аңлатмалар һәм анализ бирүгә «әмма» дип күчә.

70 а биттән кара каралы язуга күчә. Фикер сөрешен сораужавап рәвешендә кора.

72 б биттән бөек сәхабәләрне, аларның шәҗәрәсен схематик рәвештә тикшерүгә күчә.

73 а биттә мәркәп мәсьәләсе, ягъни җайдакны йөрткән хайваннар тикшерелә.

75 б биттә «Тәгърифе көллият» хакында бәхәс ачыла.

83 а биттән бәхәсләр һәм күз алдына китерүләр хакында зәңгәр кара белән язылган, бүлекчә атамалары кызыл кара белән язылган хезмәт килә.

96 б биттән «Мәүзугъ һәм табигать арасында фирак» бүлеге килә.

102 а биттән «Гыйльме китабы-тасвир», ягъни күңелгә килгән сурәтләр турында язма килә

116 б биттә «[Дөресләүче] Шиһабетдин Әл-Казани Әл-Мәрҗани» дигән язу бар.

Алга таба шушы рухта китап дәвам итә. Гомуми зурлыгы 123 бит. Ахыры бозылган. Тышлыксыз.

4. Китапны беренче өйрәнү аның авторы татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани икәнлеген билгеләргә мөмкинлек бирә. Фәндә моңа кадәр билгеле әсәрләре арасында мондый хезмәте барлыгы билгеле түгел. Ул аны мәдрәсәдә укыту материалы буларак әзерләгән, лекцияләр рәвешендә төзегән, практик өлешләргә дә бүлгән.

Китапның заманында Мәрҗанинең әтисе яшәгән, аннары энесе торган йортка, Ташкичү авылына (Арча районы) кайтарылган булуын, соңыннан илдә булган һәртөрле сәяси туздыруларны узып шушы хәлгә төшүен, әмма халык тарафыннан саклап алып калынганын билгеләргә мөмкин.

**№ 17: Я**

1. Кулъязма китап, 19,0×22,0 см. XIX йөз башына карый. Кара караны каурый каләм белән язып эшләнгән. 20 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Арча районы Байкал авылыннан табылган.

3. Начар сакланышта. Таракан ашаган. Битләре бозылган, ертык. Тулы түгел.

4. «Бакырган китабы» тупланмасы шигырьләренә тартым күчермәләрдән тора. «Шәмсетдин» исеме белән колофон өлешләрендә авторы телгә алынган очраклар да моны раслый. Алары аның шигырьләре.

5. 11 а биттән «Һәза Китабы Әдһәм» поэмасы башлана.

6. Төрки-татар телендә.

**№ 18: Я**

1. Кулъязма китап, 17,0×21,0 см. Кәгазенә бәйле караганда, XIX йөз башы (беренче чиреге) күчермәсе. Тышлыгы юк.

2. Арча районы Кызылъяр авылында табылган.

3. Кәгазе калын. Кайбер битләре арасында борынгырак нөсхәнең сәхифәләре бар. Димәк, шуннан күчерелгән ( мәсәлән, 102 а бит).

4. Тулы түгел, әмма беренче битләр бар. Ахыры юк. 37 б биттән «Китабы талак» бүлеге, 97 а биттән «Китабы тәһарәт» язылган.

5. Гарәп телендә.

**№ 19: Я**

1. Кулъязма китапчык, 16,0×20,5 см. Сызыклы дәфтәрдән эшләнгән, 49 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Арча районы Байкал авылында табылган.

3. «Бибигазизә дәфтәре» дип, язучысына бәйле исем бирергә була. Эчендә берничә дата очрый. 1958 ел белән дә, 1966 ел да

язылган урыннар бар. Шигырьләр, догалар, истәлек сүзләре язылган. Авторучка язмалы булуы 1969–70 елларга да нисбәт итәргә мөмкинлек бирә.

4. Эчтәлеге:

1 а биттә бабалар рухына дога, Коръән багышлау догасы: «Хуҗа Нәкъшбәнди, Шәех Касыйм, Баба шәех, Бәһлүл дивана, Хуҗа Хәким, Ата Хөбби, Хуҗа Әсгар, Хуҗа Зәнки, Баба шәех Билалетдин, Җиһан баб, Хуҗа Насретдин, Хәсән Басрый, Хуҗа Бәрус, Шәех Нәҗметдин вә җөмләбезгә мәгълүм булмаган мөшәихләрнең әрвах шәрифләренә... »

2 а биттә бу мөнәҗәт бирелгән:

Рәсүлуллаһ ятим үсте,
Ятимнәрне сөяр иде,
Ятим балаларны күрсә –
Башларындин сыйпар иде.

Рәсүлуллаһ җомга көннәрдә
Урамнарга чыгар иде,
Агач төбендә җылап утырган
Берчә ятим баланы күрде.

Аның янына утырып
Ятимнең хәлене сорды,
«Атам да юк, анам да юк»,–
Дип бала җавап бирде...

4 б биттә мондый мөнәҗәт башлана:

Бер кемсә намаз укыса,
Алдан салават әйтмәсә,
Кыямәт көнендә булганда
Шәфәгать көтмәсен ул кемсә...

6 а биттән мондый мөнәҗәт бирелгән:

Хәдичә, Фатыйма, Гайшә –
Ападыр бу өч хатын,
Кыямәт көн шәфәгатен
Насыйп әйләсен, йа Рабби...

(һәм тагын бер куплеты бар).

7 б биттә бу әсәр бирелгән:

Хәлем бик авыр,
Җаным бик татлы,
Җан алучыбыз
Газраил атлы...

(Һәм тагын ике куплеты бар).

11 а биттә «Иманны дөрес саклау» мөнәҗәте язылган.
11 б биттән төрле догалар язылган: албастыга каршы бөти, бала йокламаганда өшкерү догасы һ.б.
14 б биттән салаватлар бирелгән.
17 б биттә хәзрәте Фатыйманың вафат булуы хакында хикәят язылган.
22 б биттә «Рәсүлуллаһның мөбарәк мөһер сәватының хасилы» хакында хәбәр урнаштырылган.
23 а биттән «Рамазан касыйдәсе», догалар, мөнәҗәтләр һ.б. төрле текстлар урнаштырылган.

**№ 20: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,0×16,7 см. Шакмаклы дәфтәр битләреннән тегеп ясалган. 6 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Тышлыгы зәңгәрсу төстәге дәфтәр тышлыгы. Анда болар язылган: «Ахырзаман яки Тәкый гаҗәп китабы», «1912 нче елда басылган», «1953 нче елда язылды».

3. Арча районы Байкал авылында табылган.

4. Сөләйман Бакырганиның «Ахырзаман китабы», Гали Чокрый тарафыннан эшләнелгән басма варианты.

Башы: Йирне нитәк ярат дисә, күкне һоман,
Айны нитәк ярат дисә, көнне һоман,
Әүлия-рәсүлләрне әйтсәм тәман,
Андин артык тәкый гаҗәп Таңнары вар.

Замана ахыры булса – нәләр булгай:
Дөньяга төрлүк-төрлүк бәла тулгай,
Галимнәр гаҗиз булып зари кылгай,
Андин артык тәкый гаҗәп Таңнары вар...

6 б биттә болар язылган:

Кол Сөләйман тәгать кылгыл, гафу кылгай,
Уганым лотфы берлә хөкем кылгай,
Ахирәт әсбабыны төзү виргәй,
Андин артык тәкый гаҗәп Таңнары вар.

Мескин Гали бу китапны тәртип итде,
Күп мисрагын тәҗдит идеп,
Мондин соңра бераз тәкърир мәнзүм итте,
Аны тәкый бастырмага моряды вар.

Бу сәхифәдәге «Кол Сөйләйман» дигәне Сөләйман Бакырганига карый, «Мескин Гали» дигәне Гали Чокрыйның үзенә. «Таңнары» сүзе «Кыямәт көне» дигәнне белдерә.

**№ 21: Я**

1. Кулъязма китап, 17,0×21,5 см. Татар телендә. 72 сәхифә күләмендә. Ахыргы битләре башка китаптан кушылган. Аннары гарәп телендә язмалар китә.

2. Арча районы Сәрдәбаш авылында табылган.

3. Беренче сәхифәсе бар. Алга таба битләрне тәртипкә салырга кирәк.

4. XIX йөз кәгазе. Каурый каләм белән язылган. Кара кара файдаланылган.

5. Эчтәлеге гакыйдә хәбәрләреннән гыйбарәт. «Хакыйкательгакыйдә» стилендә. Оҗмах һәм тәмуг вакыйгалары язылган. Эчтә «Нәсыйхәтес-салихин» дигән язу да бар.

**№ 22: Я**

1. Кулъязма китапчык, 21,5×18,3 см. Үзара тегелгән гадәти дәфтәр битләреннән гыйбарәт. 3 сәхифәдән тора.

2. Арча районы Шура авылында табылган.

3. «Кырык бишенче хикәя. Рәсүлемез саллаллаһы галәһиссәлләм» дип башлана. 2 а битнең 3\2 нче өлешендә дәвам ителә.

**№ 23: Я**

1. Кулъязма китапчык сәхифәләре, 11,0×16,2 см. Зәңгәрсу төстәге XVIII йөз ахыры – XIX гасыр башы кәгазьләренә язылган.

2. Арча районы Ташкич авылында табылган.

3. Шигъри тезмәләрдән гыйбарәт. Эчтәлеге илаһи мәхәббәт турында, суфичыл характерда.

4. Иҗат итүченең үз кулы белән язылган булырга кирәк.

**№ 24: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×17,5 см. Коръән аятьләреннән гыйбарәт. Урта җирдә догаларның хасиятләре хакында татарча язылган.

2. Арча районы Сеҗе авылында табылган.

3. Кәгазе XIX йөз башына карый. Матур язылган. 21 сәхифәдән гыйбарәт.

**№ 25: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×17,5 см. «Һәза китап» дип куелган, гарәпчә һәм татарча салаватлар язылган. 5 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Арча районы Сеҗе авылында табылган.

3. 1 а биттә «1883 нче елда» дигән күчерүче язмасы бар.

4. Каурый каләм белән кара кара кулланып язылган.

**№ 26: Я**

1. Кулъязма китапчык, таркау. 10,0×17,2 см. Дини мәсьәләләргә багышланган, аерым китап итеп төпләнгән.

2. Арча районы Түбән Оры авылында табылган.

3. Ахырда «Габделкәрим угылы Йосыфның торыр» дигән язуы бар.

**№ 27: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×17,5 см. Башы-ахыры юк. Намаз вакытлары, әдәп мәсьәләләре хакында кесә китапчыгы.

2. Арча районы Ташкич авылында табылган.

3. XIX йөзгә карый. Татарча. Теле күркәм. Төзәтмәләре дә бар.

**№ 28: Я**

1. Кулъязма китапчык, 11,0×17,0 см. Тышлыгы советлар чоры газетасыннан гыйбарәт. 12 сәхифәдән тора.

2. Арча районы Ташкич авылында табылган.

3. Кәгазе XIX йөз ахырына карый. Каурый каләм белән язылган. Татарча. Башта дини-схоластик поэма килә. 7 б биттән «Хикәяте Гадерразак» әсәре башлана.

4. Авторлары һәм күчерүчесе билгесез.

**№ 29: Я**

1. Кулъязма китапчык, 10,5×17,0 см. Башы-ахыры юк. XIX йөз ахыры кәгазе. Кара кара белән язылган. Каурый каләм язуы.

2. Арча районы Ташкичү авылыннан табылган.

3. Хикәятләр җыентыгы. «Тутый әйтте...» сүзләре очрауга карап «Тутыйнамә китабы» икәнлеген ачыклап була.

4. Татарча. Шактый тузган.

**№ 30: Я**

1. Коръән тәфсире сәхифәләреннән гыйбарәт берничә кулъязма бит.

**№ 31: Я**

1. Кулъязма китап, 15,0×20,0 см. Коръән сүзлеге фрагментлары сакланган. Ике багана итеп тезеп бара. 13 сәхифәдән гыйбарәт.

2. Арча районы Ташкичү авылында табылган.

3. 13 б биттә «1838 нче елны июньнең 22 көне» дигән язуы бар.

**№ 32: Я**

1. 1. Кулъязма китап сәхифәләре, 15,0×20,0 см. 9 бит күләмендә, татарча һәм гарәпчә язмалар. XIX йөз башына карыйлар.

2. Арча районы Ташкичү авылында табылган.

3. Беренче җиде сәхифәсе иман һәм аның аңлатмалары, гакаид фәлсәфәсе гыйлеменә карый, калган ике сәхифәсе «Шикаятьнамә»дән гыйбарәт.

**№ 33: Я**

1. Кулъязма китап. 15,7×20,0 см. Каурый каләм белән язылган. Кара кара файдаланылган. XIX гасыр кулъязмасы. 67 сәхифәдән гыйбарәт. Башы-ахыры юк, тышлык куелган.

2. Арча районы Хәсәншәех авылында табылган.

3. Дини мәсьәләләр һәм хәбәрләр, фәлсәфи бәхәсләр китабы. Кыямәт көне, аның хәбәре, шул хакта хикәятләр һәм төрле төрдәге дәлилләр теркәлеп язылган татарча хезмәт.

18 б. «Фасыл. Намаз» дип куелган.

**№ 34: Я**

1. Кулъязма китап, 17,0×22,0 см. 34 сәхифәдән гыйбарәт. Башы-ахыры юк. Каләм белән язылган. Таркау.

2. Арча районы Пөшәңгәр авылыннан табылган.

3. XX йөз башы җәдит мәдрәсәсе шәкерте дәфтәре. «Мифтахел-тәварих»тан конспектлары да бар.

**№ 35: Я**

1. Кулъязма китап, 17,0×21,0 см. 80 сәхифәдән гыйбарәт. Гарәп телендә. Яхшы кәгазьгә каләм йөретеп кара кара белән язылган. Башы-ахыры юк.

2. Арча районы Пөшәңгәр авылыннан табылды.

3. Хәдисләр турында тикшеренү китабы. XIX йөзгә карый.

**№ 36: Я**

1. Кулъязма китап, 17,0×20,0 см. 200 сәхифәле. Сүтелгән. Таркау һәм начар сакланышта. Кара кара белән язылган. Каурый каләм язмасы.

2. Арча районы Каргалы авылында табылган.

3. XIX йөз башына карый. Шәригать китабы.

**№ 37: Я**

1. Кулъязма китап фрагментлары, 13,0×21,0 см. Урта Азия кәгазенә эшләнгән, гарәп телендә.

2. Арча районы Каргалы авылында табылган.

3. Шәригать хөкемнәренә бәйле хезмәт.

# КУЛЪЯЗМАЛАР ҖЫЮ ТАРИХЫННАН

*Марсель Әхмәтҗанов*

Төрле елларда Татарстанның Арча төбәге авылларында археографик эзләнүләр алып бару нәтиҗәсендә шактый гына борынгы кулъязма китаплар табылды. Алар хәзер Казанда, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклаupdated. Шуларның бер өлеше белән татар җәмәгатьчелеген таныштырып китәргә булдык. Алар Үзәктә билгеле бер тәртип саннары белән күрсәтелеп куелганнар. Түбәндә шул табышларның бер өлешенең исемлеген китерәбез:

**№ 5705.** Кулъязма китап: 1–97, кәгазь форматы 16,0×20,9 см.

Кулъязманың тышлыгы һәм ахыр битләре югалган. Ул яхшы калын кәгазьгә, коңгырт төстәге карада, тәгъликъ ысулында, гарәп телендә язылган. Кустодлар (ягъни тыныш билгеләре) куелган. Пагинацияләрне (ягъни бит саннарын. – *М.Ә.*) кулъязманы тасвирлау вакытында суктык. Ул кулъязма китапның исеме «Шөрутес-салават» (ягъни дини салават әйтүнең шартлары. – *М.Ә.*). Кулъязма Ногман бине Сөләйман Мәрҗани кулында булган (21а биттә). Ул XIX йөзнең беренче яртысында язылган дип танылa.

Әлеге китап 1989 елда археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Татарстанда Арча төбәге Урта Бирәзә авылында Зәкия Ногмановадан алынды һәм тасвирланды.

**№ 5706.** Кулъязма китап үрнәге, 1–20 кәгазьдән гыйбарәт. Кәгазьләр зурлыгы 17,5×22,5 см, 13 юл текст.

Текстлар гарәпчә-татарча (татар теленә тәрҗемәдә бирелә, тәгъликъ ысулындагы гарәп язмасында, коңгырт төстәге кара белән язылганнар (1–8 нче санлы кәгазьләр). Татар телендә намаз уку тәртипләре бәян ителә, зәкят түләү һ.б. (9–29 б.) Кулъязма Арча төбәге Зур Бирәзә авылында 1989 елгы археографик экспедиция вакытында М. Әхмәтҗанов тарафыннан табыла.

**№ 5708.** Бер бит. XVIII йөз ахырыннан калган кулъязма, бит зурлыклары 14×10,5 см. Һәр биттә 17 әр юл язу текст теркәлгән. Кәгазьдә Гайсә пәйгамбәр турында татар телендә язылган поэманың фрагменты сакланган. Ул коңгырт төстәге кара белән тәгъликъ ысулында язылган. Бер өзек:

Диде аңа Муса и пирһәнир,
Усы китди, дөшди улынча хәйер.
Үрә тордый, соңра чук гозер итди.
Тәүбә кыйлдый, йа Рабби әмана, диде.

Бу сюжетка язылган поэманың өзекләре без тасвирлаган кулъязмалар арасында очраганы бар иде. Кулъязма 1989 елда Арча төбәге Зур Бирәзә авылында археограф М. Әхмәтҗанов тарафыннан табылып тасвирланды.

**№ 5709.** Кулъязма китап фрагменты: 1–14 кәгазь, 17×22 см, 13 юл.

Текст гарәп телендә, тәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылган. Кустодлар куелган. Пагинациясе тасвирлаучы кулы белән сугылды. Фрагмент Арча төбәгенең Зур Бирәзә авылында археограф М. Әхмәтҗанов тарафыннан табылды һәм тасвирланды.

**№ 5710.** Кулъязма китап: 1–194 кәгазь: 10,6×15,7 см, 18 юл. Кулъязманың тышлыгы һәм ахыр битләре югалган. Ул гарәп телендә, тәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылган. Бүлек башлары кызыл карадан башкарылган. Кулъязманың кәгазе 1781 елда эшләнгән. Ул ислам диненең «Сөаль-Җавап» әсәренең бер версиясенә охшый. Китап 1989 елда археографик экспедиция барышында Татарстанның Арча төбәге Зур Бирәзә авылында М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Бану ханым Халитовадан алынып тасвирланды.

**№ 5711.** Кулъязма китап: 1–88 бит (кәгазь), 16,5×22 см зурлыкта, 17 юл. Кулъязманың тышлыгы, баш һәм ахыргы битләре югалган. Текст «Коръән» тәфсире рәвешендә, гарәпчә фразалар (җөмләләр) китерелгән, алар татар теленә тәрҗемәләрдә бирелә. Эчтәлек оҗмах-тәмуг һәм башка ислам дине проблемаларына кагылышлы. Язмалар тәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән теркәлгәннәр. Текстның баштагы бер-ике бите генә юк, ахырда күпмесе югалганы мәгълүм түгел. Кустодлар куелган, пагинацияләр гарәпчә саннар белән сугылган.

Күчерелү урыны, елы, күчерүченең исеме сакланмаган.

Кулъязма 1989 елда археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Татарстанда, Арча төбәгенең Түбән Аты авылында Миңлебикә апа Ихсановадан алынды һәм тасвирланды.

**№ 5712.** Кулъязма «Әмәли китабы»: 1–5 кәгазь, 18,8×20,2 см, 10 юл. Текст гарәп телендә, нәстәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылган. Әсәр поэзия жанрында, һәр биттә икешәр шигъри багана рәвешендә 10 ар юл булып теркәлгән. Кустодлар куелмаган, күчерү елы. урыны һәм китап исеме сакланмаган. Күчерү дәвере XVIII йөзнең соңгы чирегенә тәңгәл килә.

Кулъязма археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан 1989 елда, археографик экспедиция вакытында Татарстанның Арча төбәге Зур Бирәзә авылында табылып тасвирланды.

**№ 5713.** Кулъязма фрагменты: 1–18 кәгазь; 19×20 см, 12 юл.

Кулъязманың тышлыгы һәм соңгы битләре югалган. Текст: намаз уку тәртипләре турында – татар һәм гарәп телләрендә, тәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылган. Кустодлар куелган, пагинация тасвирлаучы кулы белән сугылды. Кәгазь битенең читенә чыгарып искәрмәләр язу күренешләре бар, су билгеләре төшерелмәгән. Кулъязма XVIII йөзнең соңгы чирегенә нисбәтле.

Китап археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан 1989 елда Арча төбәге Зур Бирәзә авылында табылды һәм тасвирланды.

**№ 5714.** Кулъязма фрагменты: ике кәгазь, 15,5×20,2 см, 15 юл.

Пәйгамбәр заманындагы хәлләр тасвирлап язылган татарча поэма фрагменты. Төп каһарманнар – Җиһаншаһ, Гали, Җәһүд, пәһлүан.

Кулъязмадан бер өзек:

Дәстүр биргел ханаин…
Ничә кирәк булса андый кылайын.
Бу халык күбәи килүр йакыйн,
Ишеткел нә кыйлды рәсүл хакыйн.
Бу җәһүд килеб мазарда әйдәйен
Ул сәгатьтә җәһәннәмгә барду җаны
Битүлди мәлик айә Шәһрийар,
Бер кул моны миндин берү сусагыйл йар…

Кулъязма тәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылган. Бер бит кулъязманың башлангычын күрсәтә. Ләкин анең эчтәлеге белән фрагмент бәйләнеше ярашып бетми (татар телендә булса да).

Текст язылган кәгазьләрдә су билгеләре күренми, ул XVIII йөзнең соңгы чирегендә җитештерелгән кәгазьгә ошый.

Кулъязма археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан 1989 елда Арча төбәге Урта Бирәзә авылында Зәкия Ногманова-дан алынып тасвирланды.

**№ 5716.** Кулъязма фрагменты: 1–37 кәгазь битендә, 17×22 см, 14 юл.

Кулъязманың тышлыгы юк. Ул җыентык рәвешендә төзелгән. текстлар тәгъликъ ысулында гарәби татар графикасында язылганнар.

Анда: 4–12 битләрдә татар телендә ислам риватьләре;

13 а биттә, галимнәр сүзе (татарча);

14 а биттә 1870 елгы татарча язма;

15 а биттә дога текстлары;

15 б–16 б битләрдә гарәп телендә «Хөтбәи гайед фитыр».

17 а–37 битләрдә татар телендә ислам тарихи риваятьләре.

Язылу вакыты, урыны, кятиб исеме сакланмаган. Кәгазьдә су билгеләре күренми. Ул XVIII йөзнең соңгы чирегендә җитештерелгән кәгазьгә язылган дигән фикер нигезле булыр.

Кулъязма 1989 елда археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Татарстанның Арча төбәге Урта Бирәзә авылында Зәкия Ногмановадан алынып тасвирланды.

**№ 5717.** Кулъязма фрагменты, 1–102 кәгазь язма: 16,6×20,5 см, 15 юл.

Текст фарсы телендә язылган поэтик әсәрнең өзеген тәшкил итә. Ул коңгырт төстәге кара белән, нәстәгъликъ ысулында язылган, кустодлар кулланылган, кәгазь читләре чиста.

Кулъязма 1989 елда М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Арча төбәге Урта Бирәзә авылында Ногмановадан алынды һәм тасвирланды.

**№ 5718.** Кулъязма китап: 1–99 кәгазь; 16×20 см, 16 юл.

Кулъязманың тышлыгы, баш һәм ахыргы битләре югалган. Ул татар телендә, тәгъликъ ысулында, коңгырт кара белән язылган. Кустодлар куелган, пагинацияләр тасвирлаучы кулы белән сугылды. Су билгеләренә караганда, кәгазе (29 бите) 1804 елда Россиядә фабрикада эшләнгән.

Текстта сүз иман проблемасын йөрәктә ныгыту турында бара.

Кулъязма Арча төбәге Зур Бирәзә авылында 1989 елда М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылып тасвирланды.

**№ 5719.** Кулъязма китап, татар телендә: 1–74 кәгазь, 16×20 см, 17 юл.

Кулъязма катыргы һәм киндердән ясалган тышлыкта сакланган. Кәгазьләрдә су билгеләре күренми, шулай ук текст язылу вакыты да ачык беленми. Китапның ахыргы битләре югалган.

Әсәр татар телендә, ислам пәйгамбәрләре нәселләренең барлыкка килү тарихларына багышлана. Язмалар нәстәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылганнар. Кустодлар күренә, ләкин кайбер битләрдә юкка чыкканнар. Кулъязманың битләре читенә искәрмәләр чыгарып язу рәвеше күзәтелә.

Китапның кәгазенә караганда, ул XVIII ахырларында язылган.

Кулъязма 1989 елда археограф М. Әхмәтҗанов тарафыннан Арча төбәге Урта Бирәзә авылында Зәкия Ногмановадан алынып тасвирланды.

**№ 5720.** Кулъязма китап, тышлыгы юк, ул гарәп телендә, тәгъликъ ысулындагы әлифтә, коңгырт төстәге кара белән язылган, ахыргы өлеше югалган. Аның сакланып калган 1–45 битләрен Шәрәфетдин бине Мөхәммәдшәриф Рәхимколый ислам тарихына мөнәсәбәттә язган (45 а бит).

Кулъязманың 46 б–56 б битләренә Чубутлый дигән кешенең гарәп телендәге язмасы теркәлгән һәм гарәби текст тагын 62 б–91 б битләрдә дәвам итә.

Кулъязма XVIII гасыр ахыры кәгазенә язылган.

Китап 1989 елда археограф М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Арча төбәге Утар Аты авылында 1989 елда табылды һәм тасвирланды.

**№ 5721.** Татар телендә, XX йөз урталарында язылган шигырьләр җыентыгы.

Кулъязма 1989 елда Арча төбәге Урта Бирәзә авылында археографик эзләнүләр вакытында М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылды һәм тасвирланды.

**№ 5722.** Кулъязма җыентык: 1–77 кәгазь.

Кулъязма катыргы тышлыкта, тәгъликъ ысулындагы гарәби графикада татар телендә язылган шигырьләр җыентыгы. Язмалар 1950 елларда эшләнгән кәгазьгә язылганнар.

Китап 1989 елда Татарстанда Арча төбәге Утар Аты авылында М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылды һәм тасвирланды.

**№ 5723.** Кулъязма китап фрагменты: 1–4 кәгазь, 13,5× 21,5 см, 17 юл.

Кулъязма аерым кәгазь битләреннән гыйбарәт, язмалар тәгъликъ ысулында, коңгырт төстәге кара белән язылган. Алар ислам дине темасына карыйлар.

Кәгазьләрдә су билгеләре төшерелмәгән. Язмалар XIX йөзнең беренче яртысына карыйлар.

Кулъязма 1989 елда, июнь аенда М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Татарстанда Арча төбәге Утар Аты авылында табылып тасвирланды.

# «КАЗАН АРТЫ» ТАРИХ-ЭТНОГРАФИЯ МУЗЕЕНДА ГАРӘБИ ЯЗУЛЫ ТАТАР ЧЫГАНАКЛАРЫ

## («Сөбател-гаҗизин» әсәренең кулъязма һәм «Рисаләи Газизә»нең басма нөсхәләре мисалында)

---

*Ленар Гобәйдуллин*

Татар әдәбияты ядкәрләреннән Суфи Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк») әсәре «Кыйссаи Йосыф», «Җөмҗөмә солтан», «Төхфәтел-мөлек», «Диваны хикмәт», «Бакырган китабы», «Мөхәммәдия» кебек тарихи, әдәби хезмәтләр белән бер дәрәҗәдә танылган хезмәт. Арча шәһәренең «Казан арты» тарих-этнография музеенда әлеге әсәрнең кулъязма нөсхәсе саклана. Аны безнең музеебызга Кысна авылында яшәүче Фәйзрахманов Мәһеди, башка шуның кебек гарәби язулы кулъязма китаплар белән бергә, бүләк итте. Палеографик билгеләренә – графикасына һәм кәгазенә карап, кулъязманың күчерелү датасын XIX гасырның I яртысына нисбәтләргә мөмкин, әмма текстында бу дата күрсәтелми. Кулъязма 57 кәгазьдән гыйбарәт. Гарәп язуының сөлес төре белән язылган, төрки-татар телендә. Идел буенда күчерелгән (мөгаен Казан артында). Кулъязма зур күләмле шигъри әсәр булып, ике юллык шигъри строфалардан төзелгән. Текстның бездә булган кулъязма нөсхәсендә башы юк. Кулъязмада булган беренче ике юлы:

Төшермәй йир йөзигә саясени,
Йитерде гарш өйигә паясени.

Кадәм баскан мәназил ирде пөргатыр,
Сәхабел-әбьяз ирде башида чатыр[1].

Бу әсәрнең 44, 45 нче юллары. Бер биттә 15 юл санасак, димәк, кульязманың алдагы 2 кәгазе сакланмаган. Сакланмаган өлешкә титул бит һәм аның икенче ягыннан әсәрнең башлам өлеше, ягъни Ходайны олылау өлеше, пәйгамбәребезне мактау турындагы 5 юлы керә. Кульязманың азагы тулысынча сакланган. Ул Аллаһияр Суфиның үзе турындагы юллар һәм газәлләр белән тәгәлләнә.

Кульязма каты кәгазь белән тышланган. Сакланышы уртача. Китап өлешчә тергезелде, гасыр тузаннарыннан чистартылды, ләкин ул тулаем реставрациягә мохтаҗ әле.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен халык ни дәрәҗәдә яратып укыса, бу әсәр дә татар халкы арасында бик киң таралган, аны изге китаплар исәбеннән йөртеп, кульязмаларын кулдан-кулга күчереп язганнар, мәктәп-мәдрәсә шәкертләре өчен уку-укыту әсбабы буларак та файдаланганнар. Хәтта, фәнни хезмәтләрдә, бу әсәрне тарихчы галим, дин белгече Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең (1818–1889) дә бик яратып укуы һәм аны үзе белән хаҗга алып баруы турында мәгълүмат бар.

Әсәрнең авторы – Әбү Мөхәммәд Аллаһияр бине Аллаһкули, ягъни татар җәмгыятендә Суфи Аллаһияр исеме белән мәгълүм шәхес[2] – Урта Азиядә яшәп иҗат иткән мәшһүр төрки-татар

---

[1] Бу юллар Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәрендә түбәндәгечә шәрехләнә: «Пәйгамбәр г-мнең күләгәсе җир йөзенә һич төшмәде, аның эче-тышы нур иде. Нурның исә күләгәсе булмас. Аның мәртәбәдәрәҗәсе вә могъҗиза булуы гарше (күктәге) йортның иясе – Аллаһтандыр. Пәйгамбәрнең мөбәрәк кадәм-аяклары кайсы урынга басса, ул урыннан хуш ис килер иде. Кая гына барса да, түбәсендә бер ак болыт бергә йөри иде». (Ялчыгол Т. Рисаләи Газизә. Казан: «Хозур» нәшрияты, 2014. Б. 68–69.)

Шагыйрь, галим Фәрит Яхинның шигъри тәрҗемәсе:

«Төшермичә җиргә күләгәсен Ул,
Җиткерде күкләр катына үзен Ул.
Аяк баскан җирендә үсеп чәчәк,
Баш очында ак болыт йөрде һәрчак».

[2] Суфи Аллаһиярның туган-вафат булган еллары фәнни әдәбиятта төрлечә язылa: 1616–1713, 1630–1723, 1644–1721.

суфи шагыйре, шәригать белгече. Югарыда әйтелгән әсәре өстенә шагыйрьнең «Морадел-гарифин» («Укымышлыларның максаты»), «Мәсләкел-мөттәкыйн» («Тәкъвалар мәсләге») «Михрабел мотыйгыйн» («Күндәмнәрнең михрабы») кебек әсәрләре дә бар. Бу әсәрләр шагыйрьнең суфичылыкның нәкышбәндия тарикате тарафдары булган шәех Хәбибулла остазда 12 ел тәрбия алып, югары рухи дәрәҗәгә ирешүенең күркәм нәтиҗәсе. 1708 елда шагыйрь Казан каласына килә, аннан Болгар шәһәренә барып ата-бабаларыбыз туфрагын зиярәт кыла.

«Сөбател-гаҗизин» әсәре суфичылык рухы белән сугарылган. Мәгълүм ки, XVII гасырда – татар халкының иң катлаулы, дәүләтчелеге күптән бетерелгән, дини, милли, икътисади изелгән дәверендә суфичылык традицияләре яңа төсмерләр ала. Әсәрнең идея-тематикасына килгәндә, анда төрле диниәхлакый характердагы дини-дөньяви сюжетлар, үгет-нәсыйхәт эчтәлекнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып бара:

Мәхәббәт әһеленең җуйаны булгыл,
Ушал кем очрады корбаны булгыл.

(Мәхәббәтле бәндәне эзләүче бул,
Шундый кеше очраса, корбаны бул.)

Яки:

Чыгармагыл агыздин кылмас эшне,
Кылырмын димә кулдин килмәс эшне.

(Чыгарма авыздан син булмас эшне,
«Эшләрмен!» – димә кулдан килмәс эшне.)

*(Фәрит Яхин тәрҗемәләре)*

Суфи Аллаһиярның төп идея-максаты да шуның кебек фәлсәфи фикерләр, акыллы гыйбарәләр, гадел, күркәм тормыш, намуслы яшәү үрнәкләре аша матур (кылган гамәлләре, күңеллерухы белән матур) кеше тәрбияләү һәм шулар ярдәмендә төрле катлау халкын Аллаһы Тәгаләгә якынайту, аның рәхмәтенә ирештерү.

Шунысын да онытмыйк, «Сөбател-гаҗизин» – татар халкының рухи ихтыяҗын кәнәгатьләндерүче тәүге мәртәбә басылган

(1802 елда) татар китабы. Шулай ук бу китапның бер басмасы 1841 елда якташыбыз, Яңа Кишет авылында туып үскән Рәхмәтулла Әмирханов тарафыннан да дөнья күрә. Болары исә Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар фондында саклана.

Шулай ук «Казан арты» тарих-этнография музеенда Таҗетдин Ялчыголның (1768–1838) «Рисаләи Газизә шәрхе сөбател-гаҗизин», ягъни без югарыда сөйләгән әсәрне шәрехләп язган (комментарий) китабының 1893 елда Казан университеты (бу чорда Император) табгыханәсендә (басмаханәсендә) якташыбыз, Казан өязе Түбән Курса авылының Шәмсетдин Хөсәен угылы тарафыннан нәшер ителгән басмасы да саклана (китап 348 биттән гыйбарәт).

Бу чәчмә һәм шигъри юллар белән язылган әсәрне халык яратып укыган, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку китабы буларак файдаланган. Шагыйрь Габдулла Тукай да үзенең танылган «Исемдә калганнар» әсәрендә: «Бервакыт көз көне, өйләдән соң, әти белән әни ындырда иде, мин җан тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады», – дип яза.

Таҗетдин Ялчыгол – татар иҗтимагый, әдәби тормышында мәгълүм шәхес. Ул тарихи хезмәте – «Тәварихе Болгария», халык медицинасы буенча «Фәваиде Баһавийә»[1] һәм безгә мәгълүм дини-әдәби «Рисаләи Газизә» һ.б. китаплары белән танылган. Гомерен хәзерге Татарстан Республикасы Түбән Кама һәм Зәй районнары авылларында уздыра. Бу урында шунысын да искәртеп китү урынлы булыр: Арча районы Яңа Кишет авылында яшәүче Таҗетдинов Фәрит Марс улының да нәсел-нәсәбе Ялчыголга барып тоташа.

Китапның эчтәлегенә килгәндә, алда әйткәнебезчә, текст шәрехләү характерында язылган. Әсәрнең поэтик өлешендә «Сөбател-гаҗизин» әсәреннән юллар китәрелә, ә аннан соңгы чәчмә өлештә шуның мәгънәсе, эчтәлеге аңлатыла. Әмма, Шә-

---

[1] Х. Миңнегулов «Фәваиле бәһайиәт» дип яза.

рык традициясендәге шәрехләүгә хас буларак, авторның үз сюжетлары, өстәмәләре дә әсәрдә чагылыш таба.

Бүген русларның «Слова о полку Игореве» әсәре турында берничә дистә фәнни китап, йөзләрчә мәкалә, хәтта махсус 5 томлык энциклопедия дә бар. Бу әсәрнең һәр җөмләсе, һәр сүзе диярлек фәнни тикшерелгән. Әмма Россиянең көнбатышыннан көнчыгышына сибелгән рус авылларыннан бу әсәрнең кульязма нөсхәләрен чыра белән яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Таба алу гына түгел, рус милләтенең рухи җәүһәре саналган әлеге әсәр турында рус мужигы берни дә белмәгән. Ә татар авылларыннан әдәбиятыбыз, мәдәниятебезнең рухи җәүһәрләре даими рәвештә табылып тору – бу безнең милли горурлыгыбыз, татар халкының укымышлылыгын, зыялылыгын күрсәтүче бик зур дәлил. Кызганыч, «Сөбател-гаҗизин», «Рисаләи Газизә» кебек ядкәрләребез хакындагы фәнни хезмәтләрнең саны бер дистәгә дә тулмый.

Бу ике әдип кайда гына туып яшәмәсен, әсәрләре кайда гына язылмасын, күчерелмә-нөсхәләре Казан артында табылу һәм әби-бабаларыбыз тарафыннан укылган булуы – бу аларга булган рухи ихтыяҗ турында сөйли. Әлеге ике китап музеебызның язма чыганаклар һәм фото-документлар фондында алыштыргысыз мирас булып саклана.




«Рисаләи Газизә» китабының титул бите





«Сөбател-гаҗизин» кулъязмасы

# ӨЙРӘНЕЛГӘН ТАШ ШОМАРА, ЯТКАН ТАШ МҮКЛӘНӘ

*Айдар Гайнетдинов*

Халкыбыздан безгә мирас буларак гаять күп сандагы тарихи-мәдәни истәлекләр сакланып калган, шул исәптән гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары да бихисап. Алар халкыбыз тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнүдә, һичшиксез, әһәмиятле роль уйный. Соңгы елларда тарихи-мәдәни истәлекләргә игътибар көчәеп китте һәм аларны өйрәнү дә бик актуаль юнәлешкә әверелде. Шуңа күрә татарлар яшәгән һәр төбәк җентекләп өйрәнелергә тиеш, әби-бабаларыбыздан сакланып калган бер генә эпиграфик ядкәрне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый, аларның һәрберсен түкми-чәчми халыкка кайтаруда җиң сызганып эшләү таләп ителә. Бу вазифаны һәр фидакарь эпиграфист кулыннан килгәнчә үтәргә тырышкан һәм эстафетаны бер-берсенә тапшырып килгәннәр.

Бөек татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) күп кенә борынгы кабер ташларын ачыклаган һәм үзенең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә аларның тулы текстларын теркәп калдырган[1]. Галим тапкан эпиграфик материаллар арасында Түбән Оры авылына

---

[1] Кара: *Мәрҗани Ш.Б.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 416.

караган ташъязма да бар, ләкин ул бүгенге көнгә хәтле сакланып калмаган.

1927–1928 елларда күренекле галим Гали Рәхим (1892–1943) Арча районының (ул вакытта Арча кантоны) кайбер авылларындагы борынгы кабер ташларын өйрәнгән. Нигездә, аны XVI–XVII асырларга караган ташлар гына кызыксындырган. Ул Казан университеты каршындагы Татарстанны өйрәнү җәмгыятендә һәм Тарих, этнография, археология җәмгыятендә фәнни эш алып барган, берничә эпиграфик экспедициядә катнашып, шактый күп ташъязма истәлекләрне өйрәнгән. Г. Рәхим Иске Ашыт авылында – өч, Түбән Орыда бер борынгы ташбилге тапкан һәм аларны, җентекләп анализлап, фәнни әйләнешкә кертеп җибәргән[1]. Моннан тыш Әтнә һәм Биектау районнарына кергән авылларда да йөреп, барлыгы алтмышка якын ташъязма истәлек ачыклаган.[2] Инде ул заманнарда ук ташларның сакланышы куандырырлык булмаган, текстларының шактый өлеше күренмәгән. Г. Рәхимнең эпиграфик эшчәнлеге шунысы белән игътибарга лаек: ул Ш. Мәрҗани укыган кайбер таш текстларында хаталар табып, аларның дөрес укылышын тәкъдим иткән.

XX гасыр урталарында төрле галимнәр Казан арты төбәгендә археологик истәлекләр эзләгән һәм шул исәптән борынгы кабер ташларына да игътибар иткәннәр. Табылган материаллар нигезендә археологик карталар, альбомнар төзелгән. Арча районында иң борынгы ташбилгеләр XIII–XIV йөзләргә караган. Атаклы галим Һ. Йосыпов (1914–1968) Иске Ашыт, Иске Кишет авылларында Алтын Урда чорына караган борынгы кабер ташларын тапкан[3]. XV йөзгә кагылышлы ташбилгеләрне ул Урта Аты саласында, XVI гасырга карый торганнарын Түбән Оры, Иске Ашыт, Иске Кишет, Кишмәт, Кадрәк, Урта Аты, Югары Аты, Зур Бирәзә, Наласа, Түбән Мәтәскә, Казиле, Югары Курса авыл-

---

[1] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Р. Мәрданов, И. Һадиев. Казан: Җыен, 2008. Б. 274–279.

[2] Шунда ук. Б. 214–274.

[3] *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л.: Изд-во Академии наук СССР, 1960. С. 21.

ларында, XVII йөз белән билгеләнгәннәрен Түбән Оры, Түбән Мәтәскә һәм Кәче зиратларында ачыклаган[1].

Мәшһүр татар галиме Марсель Әхмәтҗанов Арча районы эпиграфикасын өйрәнүгә аеруча зур өлеш керткән: 1996 елда басылып чыккан «Арча төбәге тарихы» китабында ул үзе тарафыннан табылган шактый күп ташъязма истәлекләрнең укылышын биргән, анализлаган һәм кызыклы күзәтүләр ясаган. Ул хезмәттәге иң борынгы таш 1357 елга караган, ягъни ул вакытта әле Алтын Урда чорына караган ташлар да сакланган булган. Китапта кырыктан артык ташның тасвирламасы бирелгән[2]. Шулай ук галимнең «XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре» исемле кыйммәтле хезмәтендә дә Арча төбәге белән бәйле булган берничә борынгы ташъязма истәлек китерелгән[3].

Районның эпиграфик истәлекләрен ачыклап, фәнни яктан тикшеренүләр алып баручылар югарыда санап киткән шәхесләр белән генә чикләнми әлбәттә, ләкин башкалар бу дәрәҗәдә үк зур өлеш кертмәгәннәр.

Арча төбәгенең борынгы кабер ташлары әле һаман фәннипрактик яктан тулысынча өйрәнелмәгәнгә, андагы татар авылларының зиратларында һәм аерым каберлекләрендә хәзерге көннәргә кадәр юкка чыкмыйча сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау һәм өйрәнү өчен без берничә фәнни экспедициягә чыктык. Шул рәвешле, 1939 елга хәтле вафат булган кешеләргә куелган гарәп язулы кабер ташларының һәрберсен эзләп табып, фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык һәм текстларын укыдык. Эшебезнең нәтиҗәсе игътибарыгызга тәкъдим итеlә торган әлеге китапта тулаем чагылды. Барлыгы 93 авыл зиратында 1288 борынгы кабер ташы табылды. Бу бер район өчен гаять зур сан, чөнки Татарстанның башка районнарында 4–5 мәртәбә кимрәк ташбилге табылган. Мәсәлән, Әлмәт районында гарәп

[1] *Юсупов Г.В.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. С. 23–27.

[2] Арча төбәге тарихы (История Арского края). Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 39–52.

[3] *Әхмәтҗанов М.И.* XVII–XVIII гасыр татар ташбилгеләре. Казан, 2011. 260 б.

язулы 53[1], Әгерҗе районында – 230[2], Кукмара районында – 305[3] борынгы кабер ташы табылган. Хәтта зур территория биләүче Мамадыш районында да аларның саны 342 генә[4].

Арча районының кайбер авылларында борынгы кабер ташлары бөтенләй табылмады, ә кайбер салаларда исә аларның саны йөздән артып китте. Әгәр дә кайсыдыр таш безнең игътибардан читтә калган икән, димәк, ул таш инде юкка чыккан яки таба алмаслык җирдә яткан булырга мөмкин. Без инде, көчебездән килгәнчә, бөтенесен дә эзләп табарга, берсен дә калдырмаска тырыштык.

Иң күп ташъязма истәлек ачыкланган авыл Яңа Кенәр булды (барлыгы 154 таш), чөнки анда өч зират бар. Икенче урында Түбән Оры саласы: 116 ташбилге табылды. Иске Ашыт авылының ике зиратында 112 борынгы кабер ташы сакланып калганлыгын ачыкладык, димәк, әлеге сала ташлар саны буенча өченче урында саналырга хаклы. Кызылъяр, Яңа Кишет, Югары Оры авылларында да шактый күп эпиграфик истәлек табылды. Нигездә, аларның күплеге теге яки бу торак пункт халкының

---

[1] *Әхмәтҗанов М.И.* Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. Казан, 2000. Б. 13–66, 143.

[2] *Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г.* Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре. Казан: Тамга, 2008. Б. 5.

[3] *Һадиев И.Г., Мәрданов Р.Ф.* Кукмара төбәгенең ташъязма истәлекләре. Казан: Милли китап, 2014. Б. 5.

[4] *Һадиев И.Г., Мәрданов Р.Ф.* Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. Б. 5. Мамадыш районына оештырылган археографик экспедицияләребезнең нәтиҗәләре хакында без төрле конференцияләрдә чыгыш ясап, алар түбәндәге фәнни җыентыкларда һәм журналларда басылып чыкты: *Гайнетдинов А.М.* Түбән Ушмы авылы эпиграфик язмалары // Традиционная культура народов Поволжья: материалы Всероссийской научно-практической конференции (11–13 февраля 2014 г.). Казань: Ихлас, 2014. Б. 45–51; *Гайнетдинов А.М.* Түбән Ушма эпиграфикасы // Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 5. Казань: Ихлас, 2014. Б. 8–15; *Гайнетдинов А.М.* Мамадыш районы борынгы эпитафияләре // Татарская фольклористика. Исследования молодых. Вып. 5. Казань: Ихлас, 2014. Б. 105–119; *Гайнетдинов А.М.* Ташка язу осталары бертуган Солтанбәковлар // Эхо веков – Гасырлар авазы. 2015. № 3–4. Б. 254–258; *Гайнетдинов А.М.* Мамадыш районының борынгы ташъязмалары // Түгәрәк уен. 2016. № 1. Б. 54–57.

матди һәм рухи яктан нык үсеш алганлыгын күрсәтә. Гадәттә, ташбилгеләрне бай югары катлау вәкилләре куйган, чөнки аларны эшләтү бик кыйммәткә төшкән. Элекке заманнарда бер таш яздыру бер ат, югары зәвык белән ясалганы берничә ат бәясенә тиң булган[1]. Шуңа күрә гади халыкның фәкать тамгасы төшерелгән кечкенә агач багана яки эшкәртелмәгән примитив бер таш кына куярга хәле җиткән.

Кызганыч ки, бүгенге көндә безгә хәтле башка галимнәр ачыклаган кайбер борынгы ташбилгеләр кабер ияләре кебек үк инде юкка чыккан. Мәсәлән, эшебез барышында без Арча районында Алтын Урда чорына караган һәм тексты сакланган бер кабер ташы да очратмадык. Урта Аты авылында орнаменты һәм язу үзенчәлекләре белән XV гасыр ташын хәтерләткән бер ташбилге табылды, әмма, текстының аскы өлеше ватылганга, кырылганга күрә, кемгә һәм кайсы елда куелганлыгы билгесез.

Без ачыклый алган иң борынгы кабер ташы Казан ханлыгы чорына туры килә, төгәлрәк әйткәндә, 1520–1521 елларга карый. Җураш Галиэддин улына куелган бу таш Наласа авылының зиратында табылды:

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Кааләллааһү Сүбхәәнәһү вә Тәгааләә күллү нәфсиң зәәикат-

2) -үл-мәүүт вә каалән-нәбии галәйһис-сәләәм

3) әд-дүнйәә сәгатүн фәҗгальһәә тагаһ

4) тарих тукуз йөз йегерме йитедә

5) Галийеддин углы Җураш даре

6) фәнадин даре бәкага [рихләт кыйлды]».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караари».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары».

---

[1] *Усманов В.М.* Тарихи ядкәрләр. Уфа: ДизайнПолиграфСервис, 2005. Б. 56.

Арткы ягы (калкытып язылган): «Бу ләүхне хәләле Солтан би бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Аллаһ Сүбхәнәһү вә Тәгалә әйтте: «Һәр җан иясе үлемне
2) татыячак», пәйгамбәр, аңа сәлам булсын, әйтте:
3) «Дөнья бер сәгатьлек, аны [Аллаһка] итагать белән үткәр».
4) Тугыз йөз егерме җиденче [елда]
5) Галиэддин углы Җураш фани
6) дөньядан мәңгелек дөньяга [күчте]».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары».

Арткы ягы: «Бу ташны хатыны Солтан би куйды».

Таш үлчәмнәре: 108×49×19.

Наласа авылында элекке галимнәр тарафыннан теркәлгән җиде борынгы ташъязма истәлекнең икесе табылмавы гына кызганыч булды. Моннан тыш бередә 1536–1537 елларга караган Тәвәккәлбай хатынына куелган кабер ташын табу да безнең өчен зур ачыш булды:

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Кааләллааһү Тәбәәракә вә Тәгаалә
2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү Раббикә
3) зүл-җәләәли вәл-икраам
4) тарих тукуз йөз кырык
5) өҗдә Тәвәккәлбай гыйалы ...
6) ... даре фәнадин даре
7) бәкага рихләт кыйлды».

Уң ягы (калкытып язылган): «Әраад-дүнйәә хараабән бигътибәәрии фәләә йәбка мүдәмән бил-караари».

Сул ягы (калкытып язылган): «Күрәрмен дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:

2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать

3) Олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның йөзе генә кала.

4) Тугыз йөз кырык

5) өченче [елда] Тәвәккәлбай хатыны

6) ... фани дөньядан мәңгелек

7) дөньяга күчте».

Уң ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары».

Сул ягы: «Күрәм дөньяны: җимерек бары, бернәрсә дә мәңге булмас, юк карары».

Таш үлчәмнәре: 104×44×17.

Шулай ук Югары Аты авылының борынгы зиратында табылган таш һиҗри белән 945 елның рабигыль-ахир аенда (милади белән 1538 елның сентябрь-октябрь айларына туры килә) вафат булган Бакыйгамбәр Галиҗан улына анасы Җанкырай ясатып куйдырганлыгын да ачыклый алдык:

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Кааләллааһү Тәбәәракә вә Тәгаалә

2) күллү мән галәйһәә фәән вә йәбкаа вәҗһү

3) Раббикә зүл-җәләәли вәл-икраам

4) тарих тукуз йөз кырык бишдә

5) Галиҗан углы Бакыйгамбәр рабиг-

6) -ыль-ахир айында дарел-фәнадин дарел-бәка-

7) -га рихләт кыйлды...».

Арткы ягы (калкытып язылган):

1) «Бу ләүхне анасы

2) Җанкырай бина кыйлды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә әйтте:

2) «Анда [җир йөзендә] булучы һәркем, һәрнәрсә фани, фәкать

3) Олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның йөзе генә кала.

4) Тугыз йөз кырык бишенче [елда]

5) Галиҗан улы Бакыйгамбәр рабиг-

6) –ыль-ахир аенда фани дөньядан мәңгелек

7) дөньяга күчте...».

Арткы ягы:

1) «Бу ләүхне анасы

2) Җанкырай куйды».

Таш үлчәмнәре: 152×49×22.

Казиле авылы янындагы борынгы зиратта табылган таш, беренче тапкыр укылды һәм аның Уҗур Кәмяш улына куелганлыгы һәм һиҗри 945 елга (безнең ел исәбе белән 1538–1539 еллар) нисбәт ителүе мәгълүм булды:

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

«...

1) тарих тукуз йөз кырык бишдә

2) Кәмяш углы Уҗур даре фәнадин

3) даре бәкага рихләт кыйлды... рәхмәт кыйлсун».

Арткы якларындагы язулары бөтенләй күренмәс хәлгә килгән.

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

«...

1) тугыз йөз кырык бишенче [елда]

2) Кәмяш улы Уҗур фани дөньядан

3) мәңгелек дөньяга күчте, [Аллаһ] рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 100×55×21.

Аннан инде бераз соңгырак дәвер, ягъни 1540–1546 еллар ташбилгеләре дә табылу һәм аларны укып, кемгә куелуын ачыклауга ирешелде. Бәхеткә каршы, кайберләренең текстлары әле табигатьнең кырыс шартларына бирешмәгәннәр, даталарын һәм исемнәрен, авырлык белән булса да, укырга мөмкин иде.

Халык әйтүе буенча, Арча районындагы күп авыл зиратларында уеп эшләнгән бертөрле типтагы XIX–XX гасыр ташбилгеләре, нигездә, хәзерге Мари Эл Республикасының Бәрәңге төбәгендә урнашкан бер таш карьерыннан алынганнар. Аларның эшкәртү осталыгын Бәрәңге ягына Ташкичү авылыннан күчеп килгән Насретдин һәм Борһанетдин нәселләре алып килгәннәр[1]. Шулай ук кабер ташларын ясау өчен материал хәзерге Мари Эл Республикасының Яңа Торъял авылындагы таш чыгару карьерыннан китерелгәнлеген ачыкладык. Олырак яшьтәге кешеләр сөйләвенчә, кайбер ташбилгеләрне махсус заказ белән Оренбург якларыннан, Урта Азиядән алып кайтып, каберләр өстенә урнаштырганнар.

Эш барышында без 15 ташка язу остасын ачыкладык: Нурмөхәммәд мулла Габдрахман улы, Рәсмиеддин Корбангали улы, Габделкаюм Шәриф улы Вәлитов, Габдрахман Мөхәммәд улы, Мулла авылыннан Хуҗа мулла һәм Фәтхелкадыйр, мулла Вафа, Фидай, Зариф, Габделбари, хаҗи Фәтхулла Газани, Каргалы бистәсеннән Сәйфеддин хаҗи Хафизеддин улы, мулла Гобәйдулла Кәлимулла улы, Сибгатулла Төхфәтулла улы, Гобәйдулла Сибгатулла улы, Гыйльван Гыйльфан улы. Аларның кайберләре ташбилгеләрне бик зәвыклы, матур, купшы, бай орнаментлы итеп эшләгән һәм каллиграфик стиль белән язган, кайберләре гади, примитив рәвештә язган, тик шулай да һәрберсенең эшләре игътибарга лаек.

Шулай ук тышкы сыйфатлары һәм текстлары белән кайсыдыр ташка язу остасы эшләре икәненә ишарә итеп торучы ташъязма истәлекләр дә бар, тик аларда язучы-оста үзенең исемен теркәп калдырмаганга, моны нәкъ менә шул кеше язган, дип төгәл әйтеп булмый. Бер үк калып һәм стиль белән эшләүче һәм бер дәвердә яшәүче каллиграфлар да юк түгел. Казан арты төбәгендә байтак ташка язу осталары яшәп, үзләреннән соң бик күп югары дәрәҗәдә эшләнгән «шедеврлар» калдырган.

---

[1] *Әхмәтҗанов М.И.* Мари Эл Республикасы, Бәрәңге төбәге татар ташбилгеләре // Восточные рукописи: современное состояние и перспективы изучения: Материалы Круглого стола (Казань, 1 декабря 2011 г.). Казань, 2011. Б. 145.

Кызганычка каршы, күпләре үзләренең эшләрендә исемнәрен теркәп куюны кирәк дип санамаган. Беренчедән, татар халкы электән үк тыйнак булган һәм эшләре белән мактануны сөймәгән, икенчедән, кабер ташына вафат булучы белән беррәттән, үз исемеңне дә язу, төрле ышанулар, хорафатлар белән бәйле булып, ничектер, үз үлемеңне дә чакыру кебек тоелгандыр.

Эш барышында без ташъязмалар аша бик күп атаклы шәхесләр, изгеләр, дин әһелләре, мөгаллимнәр, иганәчеләр, байлык һәм кодрәт ияләре каберләрен табуга ирештек. Мисал өчен, Ш. Мәрҗанинең газиз ата-анасы, әби-бабасы, башка туганнары истәлегенә куелган ташбилгеләрне ачыкладык:

**Баһаведдин Сөбхан улы Мәрҗанигә һәм Хөбәйбә Габденнасыйр кызына куелган кабер ташы, 1856 ел:**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Һәзәә мәркадү галләәмәтил-әнәәми

2) вә мәшһәдү фәһһәәмәтил-әгъләәмил-мүштәһәри бил-фәдъли

3) вәл-гыйльми мин бәйнә әкърааниһи вәт-тәфәүвүкый галәә әмсәәлиһи

4) вәхиидү дәһриһи вә фәриидү гасриһи бәһәәүл-хәккый вәддиини

5) Әбелгаляэ Мөхәммәд бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани

6) таййибәллааһү Тәгааләә рамсәһү вә таррабә фии гааләмил-кудси нәфсәһ

7) түвүффийә йәүмәл-иснәйнил-хаамиси мин шәһри рабигыйль-әүвәли

8) сәнәтә сәләсин вә сәбгыыйнә вә миәтәйни вә әлфин вә гумруһүл-газиизү

9) кад нәййәфә галәс-сәбгыыйн».

Уң ягы (калкытып язылган): «Йәә вәәкыйфән фии кабрии тәфәккир фии әмрии кад күнтү әмси мислүкә фә-тәсыыйру гадән мислии».

Сул ягы (калкытып язылган): «Тарих хәзрәт Баһаэддин әл-Мәрҗани саахибү фәдълин бикәрам».

Арткы ягы (калкытып язылган):

1) «Вә йәтлүүһү мин мәгърибиһи кабру халиләтиһ-

2) -ил-гафиифәтис-саалихәтил-бәәррати үммил-гыймәәди

3) Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бәррадәллааһү

4) мәәъвәһәә вә җәгаләл-җәннәтә мәсвәәһәә түвүффийәт

5) фии зил-хиҗҗәти сәнәтә сәмәәнин вә сәләәсиинә вә миәтәйни вә әлфин

6) мин һиҗрати мән ләһү кәмәәлүл-гыйззи вә тәмәәмүш-шәрәф

7) йәә ихвәәни вә әүләәди вә әхфәәдии ләә тәгурраннәкүм-

8) үд-дүнйәә фәиннәд-дүнйәә фәәнииййәтүн вәл-әәхыйратү әәтиййәтүн

9) вә күллү әәтин кариив».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «Бу – кешеләрнең белүчерәге,

2) гыйлем ияләре арасында белемлелеге һәм аңа тиң булганнардан өстенлеге

3) белән танылган, галимнәрнең галиме булган затның кабере.

4) Үз чорының һәм заманының бердәнбере, хаклыкның һәм диннең гүзәллеге булган

5) Әбелгаляэ Мөхәммәд бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани

6) Аллаһ Тәгалә аның каберен яхшы итсен һәм изгеләр галәмендәге аның җанын шатландырсын.

7) мең ике йөз җитмеш өченче елның

8) 5 рабигыль-әүвәлендә дүшәмбе көн вафат булды, газиз гомере [яше]

9) җитмештән артты».

Уң ягы: «Әй, каберем янында басып торучы, минем эшем хакында фикерлә: кичә мин синең кебек идем, иртәгә син минем шикелле булырсың».

Сул ягы: «Юмартлык белән өстенлек иясе хәзрәт Баһаведдин Мәрҗани».

Арткы ягы:

1) «Аның көнбатыш ягында

2) тыйнак, изге, яхшы күңелле сөеклесе, терәк анасы

3) Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек кабере. Аллаһ аның

4) урынын суытсын һәм җәннәт итсен.

5) Мең ике йөз утыз сигезенче елның зөлхиҗҗәсендә вафат булды,

6) [ел исәбе] камил дәрәҗәдәге олылык һәм тулы хөрмәт иясе булган зат [Мөхәммәд пәйгамбәр] һиҗрәтеннән [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән] соң.

7) Әй, кардәшләрем, балаларым, оныкларым, дөньяга

8) алданмагыз, чынлыкта, дөнья фани, аның ахыры киләчәк,

9) һәм һәр киләчәк нәрсә якын».

Таш үлчәмнәре: 104×40×17.

Бөек татар галиме Шиһабеддин Мәрҗанинең газиз этиәнисенә куелган ташны табу безнең өчен зур ачыш булды. Бүгенге көнгә хәтле әле аның тулы текстының тәрҗемәсе беркайда да басылып чыкмаган иде. Шунысы кызганыч, таш инде тәмам җимерелеп, юкка чыгу алдында тора, текстының кайбер өлеше укылмаслык дәрәҗәгә килгән. Шуңа күрә бу таш мөмкин кадәр тизрәк реставрацияләнергә һәм дәүләт тарафыннан саклауга куелуга мохтаҗ.

Ш. Мәрҗани атасының шәҗәрәсе түбәндәгечә: Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим бине Габдеттәүваб бине Габделгани бине Габделкоддус бине Ядәш бине Ядкяр бине Гомәр[1]. Ул 1201 (1786–1787) елның рабигыль-әүвәл аенда хәзерге Яшел Үзән районы Олы Җәке авылында дөньяга килгән, тик 1989 елда басылып чыккан «Мөстәфадел-әхбәр» хезмәтендә, басмага әзерләүчесе хаталанганга күрә, Баһаветдин хәзрәт Бәрәскәдә ту-

---

[1] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). Б. 3.

ган, дип ялгыш язылган[1]. Белгәнебезчә, мулла Баһаведдин бик гыйлемле, укымышлы кеше булган, башта Япанчы авылында, аннан Ташкичү авылында кырык елга якын имам һәм мөдәррис булып, халыкка хезмәт иткән. Ни өчендер Ш. Мәрҗани атасын, 1273 (1856) елның 25 рабигыль-әүвәлендә дүшәмбе көн вафат булды, дип язган[2]. Ташта исә шул елның 5 рабигыль-әүвәлендә икәнлеге ачык күренә.

Ш. Мәрҗанинең анасы 1209 (1795) елның 3 рәҗәбендә туган[3]. Аның шәҗәрәсе түбәндәгечә: Хөбәйбә бинте Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек бине Мозаффар бине Мортаза бине Гали бине Йосыф[4]. Кайбер тарихчылар ялгыш аның исемен Хәбибә рәвешендә язалар, чөнки әлеге исемнәрнең икесе дә гарәп телендә һәм графикасында бертөрле языла. Чынлыкта исә, нәкъ менә Хөбәйбә булырга тиеш икәнлеген җәмәгать һәм дин эшлеклесе Шәһәр Шәрәф аңлатып язган[5]. Хәбибә Хөбәйбәнең сеңлесе, ягъни Ш. Мәрҗанинең үги әнисе булган. Галим үзенең китабында анасының вафатын төгәлрәк әйткән, ягъни 1238 (1823) елның 8 зөлхиҗҗәсендә 29 яшь тулар-тулмас вакытында Гафифә исемле баласын тапканда үлгәнлеген язып калдырган[6].

Югарыда искә алынган ташның текстын заманында Шәһәр Шәрәф бастырып чыгарган булган[7], әмма ул кайбер сүзләрне укымыйча төшереп калдырган. Ш. Шәрәфнең һәм башкаларның

---

[1] *Мәрҗани Ш.Б.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 314 б.

[2] *Мәрҗани Ш.Б.* Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. Б. 132.

[3] Шунда ук. Б. 149.

[4] Шунда ук. Б. 147.

[5] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). Б. 8.

[6] *Мәрҗани Ш.Б.* Әл-кыйсмес-сани мин мөстәфадел-әхбари фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Казан университеты тәбгыханәсе, 1900. Б. 131.

[7] Кара: Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). Б. 6.

Ш. Мәрҗанигә багышланган мәкаләләре 2010 елда хәзерге татар теленә күчерелгән иде[1], тик анда бөтенләй бу ташъязма китерелмәгән.

**Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани һәм Зәгыйфә Габделбакый кызына куелган кабер ташы, 1834 һәм 1835 еллар:**

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «...Сөбхан бине

2) Габделкәрим әл-Мәрҗани вә интәкалә иләә дәәрилкараари вә җәннәәти

3) фии зил-хиҗҗәти сәнәтә тисгыйн вә әрбәгыыйнә

4) вә миәтәйни вә әлфин мин һиҗрати мән ләһү кәмәәлүлгыйззи вәш-шәрәф

5) вәл-мәрҗүввү ләһү...».

Уң ягы (калкытып язылган): «Вәдага һәзәәл-ләүха Шиһабеддин бине Баһаэддин әл-Мәрҗани 1285 сәнә».

Сул ягы (калкытып язылган): «Вә мин йәлииһи мин җәһәтилкыйбләти халииләтүһү Зәгыйфә бинте Габделбакый түвүффийәт 1250 сәнә».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе

Алгы ягы:

1) «...Сөбхан бине

2) Габделкәрим әл-Мәрҗани ахирәт йортына һәм җәннәтләргә

3) мең ике йөз кырык тугызынчы елның

4) зөлхиҗҗәсендә күчте, [ел исәбе] камил дәрәҗәдәге олылык һәм хөрмәт иясе булган зат [Мөхәммәд пәйгамбәр] һиҗрәтеннән [Мәккәдән Мәдинәгә күченүеннән] соң.

5) Аңа... сорыйбыз».

Уң ягы: «Бу ташны Шиһабеддин бине Баһаведдин Мәрҗани [һиҗри] 1285 елда куйды».

Сул ягы: «Аның кыйбла ягында сөеклесе Зәгыйфә бинте Габделбакый, [һиҗри] 1250 елда вафат».

---

[1] Кара: Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. 704 б.

Таш үлчәмнәре: 114×36×19.

Бу бөек татар галиме Шиһабеддин Мәрҗанинең әтисе ягыннан әби-бабасына куелган таш. Бабасының шәҗәрәсе түбәндәгечә: Сөбхан бине Габделкәрим бине Габдеттәүваб бине Габделгани бине Габделкоддус бине Ядәш бине Ядкяр бине Гомәр[1]. Ул бик күп җирләрдә гыйлем туплаган һәм күптөрле фәннәр өйрәнгән. Башта Галич төбәгендәге (хәзерге Яшел Үзән районы) Олы Җәке саласында, аннан соң Кысна авылында имам булып торган.

Зәгыйфәнең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Бибизәгыйфә бинте Габделбакый бине Мөслим[2] бине Мостафа бине Сәлим[3]. Аның вафат булу датасы кабер ташында ялгыш язылганлыгы хакында Ш. Мәрҗани үзе үк китабында искәртеп узган һәм, чынлыкта, әбисенең 1251 (1835) елда үлгәнен һәм ташны да үзе яздыртып куйганлыгын әйткән[4]. Әлеге ташбилгене нәкъ менә Ш. Мәрҗани үз куллары белән куйган икәнлеге ташның уң ягында искәртелгән. Ул әби-бабасының икесенә бер таш кую белән чикләнгән. Димәк, ике кешегә бер таш кую гадәтен галим хуплаган.

Белгәнебезчә, Шиһабетдин Мәрҗани – бөек җәдидче галим, тарихчы, педагог, этнограф, шәркыять белгече, дини реформатор. Ул, бөтен көчен милләтебез, динебез өчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган, халыкны аң-белемгә, иҗтиһадка (шәригать мәсьәләләрен үзлектән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртүгә) чакырган һәм схоластикадан, тәкълидтән (мәзһәбләргә

[1] Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). Б. 3.

[2] Мәрҗанинең 1989 елда басылган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында бу исемне кириллицага күчергәндә нигәдер Мөсәллим дип биргәннәр, бу дөрес түгел, «Асар» хезмәтендә бу исем Мөслим дип дөрес бирелгән (Кара: Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 том. Казан: Рухият, 2009. Б. 68).

[3] *Мәрҗани Ш.Б.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 239.

[4] Шунда ук. Б. 240.

сукырларча иярүдән) арынырга өндәгән. Шуңа күрә аның иң якын туганнарының кабер ташлары, һичшиксез, тиз арада дәүләт тарафыннан саклауга куелырга тиеш.

Күлтәси авылында күренекле мәгърифәтче, дин әһеле, җәдитче галимнәрнең берсе Шәмсетдин (чын исеме Шәмсемөхәммәд) Күлтәси каберенә дә ташъязма истәлек куелган, тик ул борынгы түгел, тексты кириллицада язылган. Шулай да мәшһүр галимнеке булганга күрә, без аны игътибардан читтә калдыра алмадык:

Таштагы текстның укылышы

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Шәмсетдин
2) Күлтәси
3) Шәмсетдин
4) Нурмөхәммәт
5) улы
6) Таһиров
7) (1837–1932).
8) Син гомереңне
9) халыкка
10) багышладың».

Шулай ук Ш. Күлтәсинең ата-анасы – Күлтәс авылының имамы Нурмөхәммәд Таһир улы һәм анасы Сабира Ибраһим кызы – әлеге авыл зиратында җирләнеп, икесенә бер таш куелган:

Таштагы текстның укылышы

Беренче ягы (уеп язылган):

1) «Мүхәммәдүр-расүүлүллааһ
2) Нурмөхәммәд бине Таһир Күлтәс
3) карйәсендә күб сәнә
4) имамәт идеб 63 йәшендә
5) миладиййә 1886 беренче
6) май вә һиҗриййә 1301
7) 16 нчы рәҗәбдә вафат
8) уларак ошбу
9) кабердә мәдфүн».

Икенче ягы (уеп язылган):
1) «Ләә иләәһәә илләәллааһ
2) бу тарафда ошбу имам-
3) -ның зәүҗәсе Сабира
4) Ибраһим кызы 71 йәшендә
5) миладиййә 1900 нче йылда
6) 5 үктәбрдә вә һиҗриййә
7) 1318 дә 24 нче
8) җөмадиәл-үхрада
9) вафат уларак
10) мәдфүн».
Өченче ягы (уеп язылган):
1) «Фәгыйш мәә шиътә фиид-дүнйәә
2) вә әдрик
3) биһәә мәә шиътә мин
4) сыйтин вә саүтин
5) фәхәблил-гайши мәүсуулүн
6) бикатгый
7) вә хайтуль-гумри
8) мәгъкуудүн бимәүүт».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе
Беренче ягы:
1) «Мөхәммәд – Аллаһның илчесе.
2) Нурмөхәммәд бине Таһир Күлтәс
3) авылында күп еллар
4) имамлык итеп, 63 яшендә
5) милади 1886 [елның] беренче
6) маенда һәм һиҗри 1301 [елның]
7) 16 рәҗәбендә вафат
8) булып, бу
9) кабердә җирләнде».
Икенче ягы:
1) «Аллаһтан башка табынырга лаеклы зат юк.
2) Бу тарафта бу имам-
3) -ның хатыны Сабира

4) Ибраһим кызы 71 яшендә
5) милади 1900 елның
6) 5 октябрендә һәм һиҗри
7) 1318 [елның] 24
8) җөмадиәл-ахирендә
9) вафат булып,
10) җирләнде».
Өченче ягы:
1) «Дөньяда теләгәнчә яшә
2) һәм теләгәнчә
3) дан-шөһрәткә
4) иреш,
5) тормыш бавы өзелү белән
6) бәйле,
7) гомер җебе
8) үлем белән бәйләнгән».
Таш үлчәмнәре: 108(143)×37×37×37.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: барлык ташъязма истәлекләребезне кулдан килгәнчә саклап калырга тырышыйк, ягъни үлгәннәрнең каберен белик, борынгы кабер ташларының кадерен белик!

## ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ

*Флера Баязитова*

Татарстан территориясе халык телендә элек-электән үк Казан арты, тау ягы, Кама аръягы дип бүлеп йөртелгән. Фәнни хезмәтләргә дә ул шулай кереп киткән.

Казан арты атамасы безгә бала вакытлардан ук Г. Тукай иҗаты буенча бик таныш һәм якын.

«И Казан арты!
Сиңа кайттым сөеп тагын да мин»...

Экспедициядә минем максатым авылларда халык традицияләренә, гореф-гадәт, йолаларга, җирле сөйләш үзенчәлекләренә, йорт-җир төзелешенә, гомумән рухи һәм матди мәдәнияткә караган фәнни мәгълүматлар туплау иде. Диалектолог (җирле сөйләшләрне өйрәнүче) һәм этнограф (гореф-гадәт, йолалар, мәдәниятне өйрәнүче) буларак, бик тырышып халык хәтерендә, бигрәк тә өлкән буын кешеләрендә сакланып калган борынгы сүзләр, йолаларга караган күпсанлы этнолингвистик текстлар яздырып алып кайту насыйп булды.

Түбәндә шул экспедиция материалларының берникадәр өлеше укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

«Урта Идел һәм Урал төбәге татар халык сөйләшләре атласы» материаллары күрсәткәнчә, Казан арты төбәгендә бер-берсенә бик якын торган берничә сөйләш аерылып чыга: арча-балтач, мамадыш, дөбъяз, лаеш сөйләшләре. Күрше Киров өлкәсендәге чиктәш авыллар һәм Мари Эл республикасындагы Бәрәңге һәм Мари-Төрек районнарында таралган сөйләшләр дә

Казан арты төбәге сөйләшләре, бигрәк тә Арча, Балтач, Әтнә төбәге сөйләшләре белән бик якын.

Казан арты сөйләшләрен күп диалектологлар өйрәнгән (Л. Җәләй, Н.Б. Борһанова, Ф.Й. Йосыпов, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б.). Казан арты сөйләшләре татар теленең урта диалектына карыйлар, әдәби телгә иң якын торган сөйләшләр.

Казан арты сөйләшләре катлаулы этник процесслар белән формалашкан. Мәсәлән, Казан арты (бигрәк тә Арча, Балтач, Әтнә, Кукмара төбәкләре) авылларының кайбер атамалары фин-угор телләренә барып тоташа торган топонимнар, мари һәм удмурт телләре яссылыгында аңлатыла:

*Күкшем* < мар. *кӱкшо* ‘высокая + *ил* ‘деревня’;

*Күwәм* < мар. *куан* ‘каменистая’;

*Күңгәр* < мар. *ку* ‘камень + *нгәр* ‘река’;

*Шода* < мар. *шудо* ‘сено’; ‘трава’;

*Тоштойал* < мар. *тошто* ‘старая’ + *ял* ‘деревня’;

*Шекә < мар. шика // шига* ‘леший’;

*Наласа* < удм. *нюлес* ‘лес’;

*Сеҗе* < удм. *сез'*ы ‘овес’;

*Сәрдә* (Сюрда) < удм. *сӱрд* ‘роща, лес’ һ.б.

Татар теленең лексик байлыгында торак (яшәү урыны) мәгънәсендә йөри торган сүзләр байтак: **авыл, сала, ил, йорт**.

**Аwыл** (орфоэп. аwыл) ‘село, деревня’ – хәзерге телдә иң киң каралган лексик берәмлек. Әдәби сүз буларак, татар теле территориясенең барлык төбәкләрендә дә билгеле. Г. Тукай иҗаты буенча бала чаклардан ук таныш атама.

«Нәкъ Казан артында бардыр бер аwыл – Кырлай диләр»...

*Авыл~аул~агыл~айил~аел* > бор. төрки *агыл* лексемасы хәзерге төрки телләрнең күбесендә бар һәм ул төрле мәгънә төсмерләре белән кулланыла. Борынгы төрки телдә *агыл* ‘загон для скота’ мәгънәсен белдергән (ДТС 1969, 18).

XIV йөз кыпчак теле язма истәлекләрендә дә (мәсәлән, «Коман мәҗмугасы»нда) *аул* сүзе шушы мәгънәдә теркәлгән.

Кыпчак телләрендә *авыл~авул~аул* һәм Себер зонасындагы телләрнең кайберләрендә (тува, хакас – *аал,* якут – *ыал*) бу сүз торак пункт (село, деревня, поселение) мәгънәсендә кулланыла.

**Сала** сүзе Арча районындагы Яңасала авылы атамасында сакланган.

**Сала** – алынма сүз, хәзерге телдә пассивлашкан (искергән сүзләр рәтенә кергән), ләкин, кайчандыр, халыкның сөйләшү телендә актив кулланылган. Лингвистик әдәбияттан билгеле булганча, *сала* лексемасы бигрәк тә Дагстан һәм Кырым топонимиясендә еш очрый. *Сала* борынгы чорларда ук хазар һәм коман телләренә кергән славян алынмасы (< село нас. место, хозяйственные постройки) итеп санала[1].

Татар телендә *сала* сүзе баштарак аерым төбәкләрдәге сөйләшләрдә генә кулланылган булырга тиеш. Мәсәлән, касыйм сөйләшендәге *Дүрт сала*, *Бием сала авыллары*[2].

*Ил* сүзен *авыл* мәгънәсендә куллану татар теленең һәр ике диалектында да бар, аерым сөйләшләрдә бу сүз хәзер дә актив сакланып килә. Топонимиядә һәм язма истәлекләрдә теркәлеп калган фактлар *ил* сүзен авыл (деревня, село) мәгънәсендә куллану татар теленең башлангыч чорларына ук хас булганлыгын раслыйлар. Моңа дәлилләр бигрәк тә Казан арты топономиясендә еш күзәтелә. Мәсәлән, авыл исемнәре: *Булиле* (< бул + иле), *Чуриле* (< чура + иле), *Йанил* (< Йаңа + ил); шулай ук Балтач районында: *Борнак иле, Йаңгул иле* авыллары һ.б.

Татар телендә *ил* (< борынгы төрки *әл*) сүзен авыл, торак пункт мәгънәсендә куллануерактан, борынгы болгар диалектларыннан ук килә торган күренеш дип санала[3].

Казан артында бик борынгы археологик истәлекләргә барып тоташа торган авыллар да бар. Мәсәлән, Арча районындагы Әйшияз авылы (хәзер Әтнә районында) «Әйшийаз (варианты:

---

[1] *Фасмер М.* Этимологический словарь русского языка. М.: Прогресс, 1971. С. 596; Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. М., 1978.С. 175.

[2] *Махмутова Л.Т.* Описание грамматических особенностей касимовского говора татарского языка // Известия КФАИ СССР, серия гуманитарных наук, вып. 1. Казань, 1955. С. 82.

[3] *Борһанова Н.Б.* Татар телендә авыл төзелешенә караган лексик-семантик төркемнәр // Исследования по диалектологии и истории татарского язык. Казань, 1982. С. 54.

«Әшийаз, Әйшийасты < Әйши + йаз +асты) название деревни в Арском районе. Недалеко от деревни, на берегу реки Ашит находится древний археологический памятник, известный в источниках как ашийазовское городище»[1].

*Әйшийаз* ойконимы *Әйшә + йаз* сүзләреннән тора. Аның беренче компоненты *Әйшә* (< *Гайшә*) антропонимына барып тоташа. Казансу елгасы бассейнында Әйшә исемендәге ике авыл бар. Шуларның икесе дә (Югары Әйшә, Түбән Әйшә) Иске Казан шәһәрчегеннән ерак түгел. «В местных преданиях название этих деревне связывают с именем «святой» Әйшәбикә (видимо, местного феодала)»[2].

*Йаз* сүзе борынгы төрки, *jazï* ‘степь, равнина’ ягъни ‘дала, тигезлек сүзләренә барып тоташа. Казан арты төбәгендә *йаз* сүзе белән ясалган авыл атамалары шактый күп. Мәсәлән: *Дөбъяз* > *Төпйаз* – Биектау районында – *төп йаз* – җир эшкәртү, игенчелек эше урыны, басу, кыр. Шулай ук: *Арпайаз*, *Олойаз, Борчаклыйаз* һ.б.[3]

Казан арты сөйләшләре өчен уртак булган иң борынгы игенчелек эшенә караган лексика да хәзерге әдәби телнең нигезен тәшкил итә. Мәсәлән, үсемлек, иген атамалары: *бодай, борай, тары, йасмық, солы борчак* һ.б.; хезмәт кораллары: *сабан, сука, сәнәк, тырма, урак, чалгы* һ.б.; җир эшкәртү иген үстерү урыны: *кыр, басу*; җир эшкәртү процессы: *сабан сөрү, суқалау, урақ уру, печән чабу, тырмалау* һ.б. барлык казан арты сөйләшләре һәм әдәби тел өчен уртак.

Казан арты төбәгендә, бигрәк тә аның төньяк-көнчыгыш өлешендә борынгыдан килгән җыеннар турында истәлекләр сакланган.

*Җыйын* сүзенең татар телендә түбәндәге мәгънәләре бар. 1. Элек бер төркем авылларда гадәттә сабан эшләре тәмамлангач

[1] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. Казань, 1877. С. 488.

[2] Шунда ук. С. 94.

[3] Бурганова Н.Б. К вопросу о формировании земледельческой лексики в татарском языке // Лексика и стилистика татарского языка. Казань, 1982. С. 48.

үткәрелә торган бәйрәм. Ул һәр төркем авылда берәр атна булып, айдан артык дәвам иткән. 2. Нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен җыйналган җәмәгать җыелышы. 3. Яшьләрнең җыелып күңел ачу кичәсе.

**Җыйын** – җәйге бәйрәм. Ул язгы чәчүләр беткәч тә башланып, печән өстенә кадәр дәвам иткән. Җыенны бер төркем авыллар берләшеп, бер-берсенә кунакка йөрешеп үткәргәннәр[1]. Мәсәлән, **Ашыт җыйыны**. Бу җыенны Ашыт елгасының югары агымы тирәсендәге: Иске Ашыт, Иске Кенәр, Печмәнтау, Сәрдә, Ташкичү, Мәмсә, Ташчишмә (Иске Тазлар) авыллары май аенда үткәргәннәр. Җыенның үзәге – Иске Ашыт авылы булган.

**Наласа җыйыны** – июнь ахырында үткәрелгән, Югары Аты, Урта Аты, Түбән Аты, Яңа Аты авыллары катнашкан һ.б.

**Сәрдә җыйыны, Кушлауч җыйыны** – июньнең 17–20 ләрендә бәйрәм ителгән, Югары Сәрдә, Урта Сәрдә, Кушлауч авыллары катнашкан.

**Әйшә җыйыны** – июнь ахырында бәйрәм ителгән, Өмбе, Кырасна, Әйшә авыллары катнашкан *Әйшә> Гайшә* исеменә бәйле дип аңлатыла.

**Ийәбаш җыйыны, Қырлай җыйыны** – июнь ахырында, Ашыт җыенынннан соң дүртенче атнада уздырылган: Иске Ийәбаш, Йаңа Ийәбаш, Йаңа Қырлай , Ашытбаш, Кысна авыллары катнашкан һ.б.

## Фонетик үзенчәлекләр

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, казан арты сөйләшләрендә түбәндәге уртак фонетик үзенчәлекләр сакланган:

*Җ*-ләштерү күренеше урта диалектның төп билгеләреннән санала. *җ*-ләштерү казан арты сөйләшләрендә шактый системалы рәвештә чагыла. Ләкин татар әдәби теленең йогынтысы астында, аеруча яшь буын телендә, хәзерге көндә аның

[1] Бу турыда кара: Бурганова Н.Б. О системе народного праздника джиен у казанских татар // Исследование по исторической диалектологии татарского языка. Казань, 1982. С. 20–65.

системалылыгы берникадәр җимерелә бара. Бу үзенчәлек – составында калын сузыклар булган сүзләргә дә, нечкә сузыклар булган сүзләргә дә карый: *җаулық//йаулық, җул//йул, йаңгыр//җаңгыр, җәшел//йәшел, җәмне//җәмле//йәмле* һ.б.

Әдәби телдәге өрелмәле *җ* авазын кушык *дҗ* авазы итеп әйтү ягыннан казан арты төбәгендәге дөбъяз сөйләше аерылып тора: *дҗил* – җил, *дҗиде* – җиде, *дҗимеш* – җимеш һ.б. Ә кайбер сүзләрдә *җ* авазы *ж* белән әйтелә: *хужа* – хуҗа, *кәжә* – кәҗә.

Әдәби телдән һәм урта диалектның башка сөйләшләреннән аермалы буларак, *ч* авазы да дөбъяз сөйләшендә кушык аваз: *тч/ч* булып әйтелә. Шартлау элементы булган тартык авазлар, нигездә, мишәр диалекты сөйләшләре өчен хас, урта диалектта ул үзенчәлек касыйм, бастан сөйләшләрендә сакланган.

Тирән тел арты (увуляр*) қ, ғ* авазларын куллану – урта диалектка карый торган барлык сөйләшләргә дә хас күренеш. Ул казан арты сөйләшләре төркемендә дә системалылыгын тулысынча саклый.

**Авазлар тәңгәллелеге.** Алда әйтелгәнчә, казан арты сөйләшләре әдәби телгә иң якын торган сөйләшләр, бу бигрәк тә Арча, Балтач, Әтнә авыллары сөйләшендә ачык чагыла. Шулай да кайбер борынгы, диалекталь үзенчәлекләр өлкән буын кешеләре сөйләшендә әле дә күзәтелә.

**Сузыклар.** *а* авазы көчле иренләшкән аваз: *кала, қақ, җамансы*–йамансу (ямансу), *бал, қара*.

Берничә иҗекле сүзнең ахырына таба иренләшү төсмере кими: *бақчаларда, балаларга* һ.б.

Өйрәнелгән төбәктә сузыклар тәңгәллегенең түбәндәге очраклары теркәлде:

**и~э (е).** Аерым сүзләрдә әдәби телдәге э урынына и авазын әйтү: *инә* – энә, *ире* – эре

**э(е)~ә:** *тәкермәч*–тәгәрмәч.

**и~ә:** *сике* – сәке

*җийәү* – җәйәү (җәяү)

*пирәмәч* – пәрәмәч

**ә~а:** әчкеч – ачкыч,
*әчә* – ача, *әче* – ачы

*Ишек әчтек – түр күрдем,*
*Түргә кердем – гөл күрдем.*

**ә~и:** *бәк* – бик
**ы~а**: *чыныйак̡* – чынаяк
**ү~ө**: *җүгерү* – йөгерү

**Дифтоноглар** – *өй* дифтонгы, нигездә, әдәби вариантта кулланыла. Шуның белән бергә, аның *и/-и (й)/-и й* булып әйтелү очраклары да бар:

*Төймә/тиймә/тиймә* – төймә
*Көйәнтә/кийәнтә* – көйәнтә (көянтә).

Сөйләштә әдәби телдәге *-ай/-әй* дифтонгына *-ый/-ий* дифтонгы тәңгәл килү очраклары бар:

*Чөмөкий* – чөмәкәй (өеп тутырып),
*Йәшлий* – йәшләй (яшьли)

**Тартык авазларның** әйтелеше әдәби телдәгечә. Фонетик үзенчәлекләр кайбер авазларның үзара тәңгәллекләренә кайтып кала.

Түбәндәге сүзләрдә борынгы *п* авазы саклана: *керпек* – керфек, *җапрак̡* – йафрак (яфрак), *тупрак̡* – туфрак, *җепәк* – йефәк (ефәк), *к̡алпак̡* – калфак. Бу күренеш, нигездә, өлкәннәр телендә генә күзәтелә.

Кайбер очракларда алынмаларда гына кулланыла торган, безнең телебез өчен чит булган *ф* авазына *п* туры килә: *Нәпис* – Нәфис, *пәк̡ыйр* – фәкыйрь, *панар* – фонарь һ.б.

Кайбер алынмаларда сүз яки иҗек башында, киресенчә, *ф~п* тәңгәллеге күзәтелә;

*фамидур* – помидор,
*сифарат* – сепарат һ.б.

Түбәндәге сүзләрдә ике сузык арасындагы *д* авазына *з* тартыгы туры килә:

*к̡азак̡* – кадак,
*изән* – идән,

*инә қазый* – энә кадый,

*йозороқ* – йодырык

Янәшә килгән сонор һәм шартлаулы авазларның, әдәби тел белән чагыштырганда, активрак кулланылуы игътибарга лаек:

*Түңкәк* – түмгәк, *шақылтата* – шакылдата, *дөбөрти* – дөберди һ.б.

Әдәби телдәге *ң* авазына тел очы *н* тәңгәллеге иялек килеш кушымчасында II зат берлек сан хикәя фигыльдә һәм кайбер сүзләрдә күзәтелә: *безнен* – безнең, *суғасын* – сугасың, *төйәсен* – төйәсең (төясең), *мен* – мең, *ин* – иң, *уна* – уңа һ.б.

*Җ*-ләштерү системалы түгел, бер үк сүз, аеруча калын сузыклардан торган сүзләр, *җ* белән дә, *й* белән дә әйтелергә мөмкин: *йарый/җарый* – йарый (ярый),

*йул/җул* – йул (юл),

*йастық/җастық* – йастык (ястык)

Алынмаларда:

*Мәрҗәм* – Мәрйәм (Мәрьям),

*чимҗә* – симйә (семья),

*wәринҗә* – варенье

Кушма сүзләрдә: *берйулы/берҗулы* – берйулы (берьюлы),

*алҗапқыч* – алйапкыч (алъяпкыч) һ.б.

Аерым сүзләрдә генә күзәтелә торган тәңгәллекләр: *м~н: үләм* – үлән;

*н~м: барнақ* – бармак;

*н~л: төснәү* – төсләү

*к~г: тәкермәч* – тәгәрмәч.

**Ассимиляция һәм диссимиляция.** Тулы, кире ассимиляция сүз башындагы *с, ч* авазларының *ш* тартыгына охшашлануында чагыла: *шаршау* – чаршау, *шыршы* – чыршы, *шубагаш* – чабагач.

*Агыйделдән ағып килә*

*Ақ шыршы бүрәнәсе...*

Түбәндәге сүзләрдә тел очы *с* тартыгы үзеннән соң килгән *ч* авазына тулысынча охшашлана: *чийырчық* – сыйырчык (сыерчык), *бачқыч* – баскыч, *қычқыч* – кыскыч; алынмаларда шул ук *с* авазының тулы уңай ассимиляциясе күзәтелә: *чичла* – число, *чистыра* – сестра.

Сүз азагындагы *н* авазы кушымчадагы *л* авазына тулысынча охшашлана. Ләкин бу күренеш Әтнә төбәгенең кайбер авылларында гына күзәтелә. Күрше Мари Эл (бәрәңге), дөбъяз сөйләшләрендә мондый үзенчәлек шактый актив. Әтнә төбәге сөйләшеннән мисаллар: *чыллап* – чынлап, *биргәлләр* – биргәннәр, *урмаллыķ* – урманлык һ.б.

**Диссимиляция:** *тушы* – шушы, *тишмә* – чишмә, *тушындый* – шушындый.

**Аваз төшеп калу.** Күпчелек сөйләшләргә хас булганча, ике сузык арасындагы *ғ/г* тартыгы төшеп кала: *җ̧ерләү* – диал. җегерләү. Аерым сүзләрдә тел очы *ч, д, с* тартыклары алдындагы *н* төшә: *муча* – мунча, *мучала* – мунчала. Сүз азагында *н* төшә: *белә* – белән; *м*: *алыш*-тилеш – алмаш-тилмәш. Кайбер сүзләрдә тулы иҗекләр төшеп кала: *әпкил* – алып кил, *апчыķ* – алып чык, *аппара* – алып бара. Кайбер сүзләр, сүзтезмәләр кыскарып, үзенчәлекле яңгыраш ала: *андары* – аннан ары, *айса* – *алайса* – алай булса.

*Һ* авазы төрки, шул исәптән татар теленә дә хас булмаган аваз. Шунлыктан ул күпчелек сөйләшләрдә кулланылмый. Казан арты сөйләшләре исә *h* авазының инде өлкәннәр телендә дә кулланылышка кергән булуы белән аерылып тора. Шулай булса да, *h* авазын әйтмәү очраклары сакланып килә. Мәсәлән, сүз башында: *үнәр* – һөнәр, *аwа* – һава һ.б.

Бу уңайдан сөйләшләрдә *х~h* тәңгәллегенең дә сирәк кенә булса да очравын күрсәтеп үтәргә кирәк: *хөнәр* – һөнәр, *хаwа* – һава, *Хашим* – Һашим, *Хади* – Һади һ.б.

**Аваз өстәлү.** Ике сузык арасындагы *ң* тартыгыннан соң *ғ/г* өстәү очраклары күзәтелә: *шуңга* – шуңа, *миңга* – миңа, *сиңға* – сиңа, *аңғарчы* – диал. *аңарчы* – аңа хәтле, *моңгар* – моңа, *җ̧аңгадан* – йаңадан (яңадан), *иңгелек* – иң элек.

**Регрессив ассимиляция.** Тел очы *н* авазы *ғ/г*, ирен-ирен *б* авазлары алдында өлешчә охшашлана: *җ̧аңған* – *йанған* (янган), *күреңгән* – күренгән, *сиксәмбиш* – сиксән биш, *урмам булған* – урман булган, *озомборон* – озынборын, *ум малай* – ун малай һ.б. Шул ук аваз, ирен-ирен *м* авазы алдында килгәндә, тулысынча охшашлана: *кийеммәде* – киенмәде, *уммы* – унмы, *күреммичә* –

күренмичә, *ум митыр* – ун метр һ.б. Түбәндәге сүзләрдә сүз башындагы тел очы *с, ч* авазлары *ш* авазына тулысынча охшашлана: *шишкәндә* – чишкәндә, *шишмә* – чишмә, *шишәмбе* – сишәмбе, *шәршәмбе* – чәршәмбе.

Метатеза: *җегерем бер* – егерме бер, *күгәлә* – күләгә:

*Җөзләредә қойаш уйный,*
*Гәүдәңдә күгәләсе...*

## Морфологик үзенчәлекләр

Казан арты сөйләшләре әдәби телгә иң якын сөйләшләр буларак, Арча, Әтнә төбәге авыллары сөйләшендә диалект күренешләр күп түгел. Грамматика өлкәсендә алар өчен уртак булган үзенчәлекләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

а) *қайсы, монысы, шунысы* алмашлыкларына, *бер* санына икеләтелгән тартым кушымчасы ялгау: *қайсысы, монсысы, шунсысы, берсесе.*

б) *-мага/-мәгә* кушымчалы инфинитивның *алмаға, асрамага* сүзләрендә даими кулланылу: *Асрамаға бала алғаннар, қатыны бәбәй китерми икән. Қышны Қазанда чықтым, сарығымы да, таwықларымы да күршемә асрамаға қалдырдым. Алмаға килсәләр қайтырсың микән?*

в) хикәя фигыльнең II зат күплеген катлаулы кушымча белән ясау: *Башта мин генә керермен, сез тороп торосыгыз (торырсыз). Базарға барасыгыз (барасыз) дип ишеткәнидем. Сез иннекне (киртә капка) күрмәгәнсегез (күрмәгәнез), әйләнеп кергәнсегез (кергәнсез).*

Казан арты сөйләшләрендә (бигрәк тә Арча, Балтач төбәкләрендә) *ич* кисәкчәсен кулланып сөйләү сакланып килә (*ич* – рус телендәге утвердительная частица ‘ведь’, ‘же’).

*Мин анда бардым ич. Безгә қунақлар килде ич, тизерәк қайтыгыз өйгә.*

*Ич* кисәкчәсе күрше фин-угор телләреннән кергән дип санала. Мәсәлән:

мар. *-с (-ыс), -ш (-ыш),*

удм. *-ось*, манш. *-ос,* венг *-is*

Тикшерүче галимнәр фикеренчә, әлеге кисәкчәләр нечкә *с'* авазына кайтып кала һәм көчәйткеч функцияне үтиләр[1].

Татар телендә *ич* кисәкчәсе бары тик урта диалект сөйләшендә генә кулланыла, көнбатыш (мишәр) диалектында ул күзәтелми. Чепца елгасы бассейнында таралган нократ, глазов сөйләшләрендә (Удмуртия) *ич* кисәкчәсе бигрәк тә актив кулланыла. Бу үзенчәлеккә әлеге сөйләшләрне беренче бутып өйрәнүче галим Җ. Вәлиди дә игътибар иткән булган[2].

*Ыштыр чормадылар ич, ыштыр-чабата киделәр ич. Чәй эчмә* (эчәргә) *барасы ич* (глз. сөйл.)

Татарстанның төньягында нократ, глазов сөйләшләрендә *ич* кисәкчесенең еш кулланылуы шулай ук күрше удмурт, мари телләре белән уртак үзенчәлеккә кайтып кала[3].

Казан арты сөйләшләренең характерлы үзенчәлекләреннән берсе – *дағын/дәген, тағын/тәген* теркәгечен яки кисәкчәсен куллану: *Урманга җиләккә мендек тәген* (мендек тә) *баштан-айақ җаңғырға чыланып қайттым. Мин дәген* (мин дә) *Қазанға барам дип җөрим*. Балтач, Арча төбәкләрендә аның әле *дағысын/дәгесен, тағысын/тәгесен* формалары да сакланып килә: *Сезне күрдем дәгесен* (күрдем дә) *артығыздан ийәреп килдем. Сабан туйын да җырладым дагысын* (җырладым да), *бийедем дәгесен* (биедем дә), *қул чаптылар, бүләк бирделәр*.

*-дагын/-дәген, -тагын/-тәген* кисәкчәләрен куллану башка төрки телләрдә дә бар. Бу үзенчәлек бигрәк тә кыргыз теленә хас, шулай ук азәрбайҗан, төрек, караим, кумык телләрендә дә билгеле[4].

Казан арты сөйләшләрендә, бигрәк тә Әтнә урынчылыгында *-мы/-ме* сорау кисәкчәләренең киң сузык белән *-ма/-мә*

---

1 *Галкин И.С.* Историческая грамматика марийского языка. Морфология, ч. 1. Йошкар-Ола, 1964. С. 183–185.

2 *Валиди Дж.* Наречие каринских и глазовских татар // Труды общества изучения Татарстана. Казань, 1930. С. 139–140.

3 *Бурганова Н.Б.* О формировании татарских говоров Заказанья // К формированию языка татар Поволжь и Приуралья. Казань, 1985. С. 3–31.

4 Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков. М., 1980. С. 122–124.

формасында кулланылуы сакланган: *исәнмә* – исәнме, *утырасызма* – утырасызмы, *өйдәмә* – өйдәме.

**Исемнәр.** I һәм II зат тартым кушымчалы исемнәрнең төшем килеше кыпчак телләре тибында да, угыз телләре тибында да формалашырга мөмкин: *бозаwымы/бозаwымны* – бозавымны, *үлчәwеңе/үлчәwеңне* – үлчәвеңне һ.б.

**Алмашлыклар**. I һәм II зат алмашлыкларының юнәлеш килешен *мийа, сийа; миңга, сиңга* вариантларында куллану очраклары күзәтелә.

Күрсәтү алмашлыкларының юнәлеш килешендә борынгы *-ар/-әр* кушымчасы саклана: *Моңгар* (моңа) *да кирәк була бер китап. Шуңгар* (шуңа) *җаңа өй салалар икән.*

Шушы ук алмашлыкларның юнәлеш килеше *-арга/-әргә* кушымчасы белән дә ясала: *Шоңарга* (шуңа) айырым *урын кирәк. Тегенәргә* (тегеңә) *дә эшкә әйтергә кирәк.*

**Рәвешләр.** Ел фасылларын белдерә торган сүзләрдән *-лый/-ли(й)* кушымчалары ярдәмендә дәвамлы вакыт белдерә торган рәвеш ясала Бу вакытта басым беренче иҗектә була: *Кышлай* (кыш буе) *айагы белән бүлнистә җатты. Җәйли* (җәй буе) *машинада эшләде, кышлый* (кыш буе) *қараwылда тордо*.

*Қыш, җәй, яз, көз* сүзләреннән *-лыкта/-лектә* кушымчасы ярдәмендә вакыт рәвешләре ясала: *Көзләктә* (көз көне, көзен) *суғым ашларына җөрибез. Кышлықта* (кыш көне, кышын) *ат җигеп райунга барабыз*.

Өлкәннәр сөйләшендә *әwәл(е), әwәлтен//әwәлтеннән*, *элгәртеннән* тибындагы рәвешләр актив: *Без үзебез арурақ тормошлы кеше идек элгәртеннән* (электән үк*). Әwәл-әwәлтеннән* (электән) *сабан туйында сөлге җыйып җөрделәр.*

**Фигыльләр. Затланышлы формалар.** II зат күплектәге *хикәя фигыльләрдә* катлаулы кушылмалар ялгану күренеше: *Менә барғач күрерсегез* (күрерсез). *Сез кем буласыгыз* (буласыз)?

Бу үзенчәлек казан арты сөйләшләренең барысында да бар, тик аның активлыгы төрле сөйләшләрдә төрлечәрәк.

Тамырлары *-р* га беткән киләчәк заман хикәя фигыльләрне I һәм II зат берлек һәм күплектә кыскартылган вариантларда да

куллану: *Барым* (барырмын) *дип уйламаганыйым. Индениләр күрем* (күрермен) *икән.*

Дәвамлы үткән заман, әдәби *-адыр иде (башландыр иде), -а торған иде (бара торган иде)* формаларыннан тыш, *-ыр, иде* формасы белән дә белдерелә: *Қышлый йылқы шулпасы ашар ыйық ат сулгач. Ашлықны кибәннәрдә сақлар ыйық.*

**Затланышсыз формалар. Инфинитив.** Инфинитивның әдәби телдәге *-ырга/-ергә* формасы белән беррәттән, *-маға/-мәгә* формасы да шактый актив кулланыла: *Күкәй сатмага* (сатарга) *базарга барам. Мал-туwарны қарамага* (карарга) кешегә *қушып қалдырам.*

**Хәл фигыльләр.** Эшнең максатын белдерә торган *-сынга/-сенгә* кушымчалы хәл фигыль формасын актив куллану: *Суwық тимәсенгә* (тимәсен өчен) *қалын шәл бөркәнеп җөрим. Тизрәк үссенгә* (үссен өчен) *қаз бибиләренә ашлық ашатабыз.*

*-мас борон* формалы хәл фигыльнең чагыштырмача активрак кулланылуы игътибарга лаек*: Көтү чыкмас борон сыйырны саwарға кирәк. Күрмәс борон җуқны сөйләп җөрмәгез.*

Әдәби телдәге *-ганчы/-гәнче* кушымчалы хәл фигыльгә кайбер очракта *-мастан/-мәстән* формасы туры килә: *Таң атмастан* (таң атканчы) *эшкә әйтергә килгән.*

*Аwылга җитмәстән* (җиткәнче) *җылғаны чығарга күпер салдылар.*

*-ғач/-гәч* кушымчалы хәл фигыльләрнең кулланылыш үзенчәлекләре әдәби телдәгечә. Тик ясалыш вариантлары ягыннан гына аерымлыклар күзәтелә: *-ғачтыннан/-гәчтеннән, -гачыннан/-гәченнән* вариантлары ешрак кулланыла. *Чәчүгә чыққачыннан* (чыккач) *күкәй тәгәрәтерләр ийе. Бала туғачтыннан* (тугач) *да қуйы итеп қаймаклап чәй эчерттеләр. Күреп қалғачыннан* (калгач) *сезне сағынырмын инде.*

### Лексик үзенчәлекләр

Әдәби телгә якынлык һәм үзара уртаклык лексика өлкәсендә дә ачык чагыла. Казан арты сөйләшләренең лексик-семантик системасы татар әдәби теленең сүзлек фондына бик якын. Ул төп татар сүзләреннән һәм алынмалардан (рус, гарәп-фарсы,

фин-угор) тора. Туганлык мөнәсәбәтенә караган сүзләр, кием-салымнар, эш кирәк-яраклары, флора һәм фауна белән бәйле төп терминология әдәби телдәгечә. Шул ук вакытта бу сөйләшләрдә борынгы һәм диалекталь сүзләр, яисә аларның вариантлары да юк түгел. Кайбер тематик төркемнәрне күрсәтеп үтик.

*Туганлык кардәшлекне белдерә торган сүзләр: тәтә* – бертуган апа һәм сөйләүчедән өлкәнрәк яшьтәге хатын-кыз туғаннар; *бал тәтә* – иренең апасына эндәшү сүзе; *дәү җиңги тәтә* – әбисенең ире ягыннан туган тиешле өлкән хатын-кызга эндәшү сүзе; *аппай* – бертуган апасына һәм өлкән хатын-кызга эндәшү сүзе; *алма аппай* – гаиләдә бертуган апаларының берсенә эндәшү сүзе; *абый* – ир туган; *әпи абый* – ир туганнар арасында кечесенә эндәшү сүзе;

*Йолаларны белдерә торган сүзләр: чүлмәнчек* – яңгыр ботка-сы (озак вакыт яңгыр яумый торса, ярма, он, йомырка май һ.б.ны җыеп, су буенда пешереп ашау һәм соңыннан су сибешү); *нигез боткасы* – өйнең нигезен коргач пешерелә торган ботка, мәҗлес; *орлык чыгару* – яз көне беренче көн чәчүгә чыкканда пешкән йомыркаларны һәм түгәрәк икмәкне кырга алып чыгу, җиргә тәгәрәтү; *бирнә* – гомумән бүләк һ.б.

*Кешенең холкы һәм тышкы кыяфәте белән бәйле сүзләр: че-кери* – бик үткен, әрсез, күп сөйләшүчән кеше; *алаҡай* – ваемсыз, дорфа кеше; *әпә* – телсез; *ийеңке* – ягымлы, игътибарлы.

*Хуҗалык һәм тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр: ҡуш* – бала утыргычы; *әче* – тавыкларга ашату өчен әзерләнгән ашам-лык; *ташайаҡ* – касә; *ҡотыйчыҡ* – шикәр, бал, май һ.б. салып кую өчен кулланыла торган, капкачлы кечкенә агач савыт; *бо-гыл* – печән кибәне; *ҡалаҡ* – тимер кашык; *өй асты* – идән асты базы; *кәнәфи* – үреп ясалган диван.

*Кием-салым һәм бизәнү әйберләре: Кәзәки* – өске юка кием; *тупый* – хатын-кызлар кия торган түгәрәк бүрек; *инечле күл-мәк* – иң эчле күлмәк; *ышлапыр* – күлмәкнең якасына, күкрәк турысына тегеп куела торган тар балитәк.

*Аш-су: чәй ашы* – табада пешкән камыр ашлары; *пирәмәч* – пәрәмәч; *ҡаты күмәч* – майсыз гына пешерелгән төче камыр күмәч; *суҡта* – суелган малның эчәгесенә ярма, ит тутырып

пешерелгән ашамлык; *дерелдәwек* – койка (холодец); *шабырча* – итле ашның өстенә чыга торган күбек.

*Терек һәм терек булмаган табигать: ташборчак* – пешмәгән җиләк; *гөләп* – гөлҗимеш; *селәү* – селәүчән; *мыжый* – эт балыгы; *бабай башы* – тузганак; *кәлтә* – курпы, *марҗа башмагы* – баллы сары чәчәк.

## Халык тардицияләре, йолалар
## Туй, кыз бирү

### *Димче*

– Элек замандарак булған ул димчеләр. Хәзер бик димләгәнне көтеп тормыйлар, җегет белән кыз үзләре танышалр ич. Ата-аналары җыйылып сөйләшәләр, киңәшәләр дә хәл итеп тә қуйалар хәзер.

### *Сөлге бирү, ризалық билгесе бирү*

– Қызны бирергә риза булсалар, бер сөлге биргәннәр җегет җағына әйбәт кенә, үзләре суққан сөлге, үзләре суққан ашаулық.

– Шулай итеп, сөлге-ашаулық биреп, «ризалык билгесе» дип биреп қайтарғаннар.

### *Билге итеп биргән ашаулық белән сөлге*

– Алай-болай булып, килен айырылып китсә дә шул билге итеп биргән ашаулық белән сөлгене элеп қалдырырга тийеш булған. Алып китә икән, гомер буйы бәхете булмый, алдагы тормышы уңмый, ди.

### *Килен төшү*

– Килен қыш көне төшә, атлар белән төшә. Кашаwай чана, кашувка. Шул кашувкага дүрт митырлы йастық қуйалар. Анда җегет белән қыз утыра.

Дилбегә тотучы алда утыра.

«Килен төшә, килен төшә, – дип, бала-чага җегерешеп җөри килен төшкәнен күрергә.

### *Килен сандыгы*

– Байырақ кешеләр сандық белән килгән, сандық тутырып килгәннәр. Килен сандыгында әйберләр була. Сатулашып сандықны сатып алалар.

– Киленнең сандыгында бирнә әйберләре, үзе әзерләгән әйберләр булган. Бит элек үзләре киндер сугып әзерләп утырғаннар ич. Чаршаулар, мендәр тышлары, мендәр җапқычлар, аслапөсләп эләргә тастымаллар. Аннан арыгысын тагын: айақчулар әпкилергә тийеш чиккәнне; күлмәклек – бийемгә, күкерәк – бийемгә, мунча җәймәсе, мунча сөлгесе һ.б.

### *Өйгә әйбер элү*

– Тәрәзә арасына чүпләмле сөлгеләр элгәннәр. Менә безнең әнинең дүрт сөлгесе, җегерме ике тастымалы бар дип санаганнар. Кийемнәрен дә элеп қуйғаннар.

– Ничә күлмәк элгән бүлмә тақтасына, ничә алҗапқычы бар аның.

**Түр қормасы** – бөтен өйне әйләндереп түргә элгән, ике-өч митрлы түр қормасы, кеше сайын булган ул.

**Чаршау** эләләр.

«Чаршау баулары қысқа», – диләр, қызлар ақча сорыйлар.

### *Тел йәшерү*

– Тел йәшерү булған. Киленнәр бийем белән сөйләшкән, бийата белән сөйләшмәгән. Какуй талашу-қычқырышу.

## Аш-сулар

### *Паштит*

**Паштит** – әд. паштет. Ул казан арты, чистай, бәрәңге, минзәлә сөйләшләрендә өстенә повидло яки җиләк-җимеш изеп ягылган, матур итеп бизәкләп пешерелгән ачык бәлешне белдерә.

*Паштит* – алынма сүз, ул безгә немец теленнән кергән: *Pastete* – паштит, пирожок. Шулай ук поляк телендә – *pasztet,* француз телендә *pastete, pate,* латин телендәге *pastata* – камырга төреп пешерелгән ит мәгънәсен белдергән[1].

---

[1] Фасмер М. Этимологический словарь русского языка. М., 1987. С. 221.

**Қабартқан паштет –** гадәттәгегә караганда йомырка һәм шикәр комы күбрәк салынган камырдан пешерелгән. [Гарифә]: *Таҗиларга чәйгә барған идем, қабартқан паштетлары нәкъ менә тақта шикелле булған.* Г.Камал.

**Пар паштит, ике паштит:**

– Туйларға, қунаққа барасы булса пар паштит пешерерләр иде, бәбәй ашына да паштит.

Парлап барасы булса – пар паштит, үзе генә барса – бер таба паштит та җитә *(каз.ар. сөйл.)*

– Қыз барған җиренә пар пуднус белән паштит алып бара *(дөб. сөйл.)*

– Қыз әнисе ике паштит алып килә. «Қодагыйның паштиты бик уңган икән», – диләр. Мичтән матур чыга паштит. Күп җөрдем туйларга паштит пешерергә. Қырыйларын ишмәкләп (ишеп), бизәкләп үреп саласың, өстен шақмақлап сырлап қуйасың нәзек қамыр белән.

– Таштетны туй қунақларына күчтәнәч итеп биреп итә җибәрәсе *(бәрәңге сөйл.)*

**Паштит табасы**. Ул дәү таба була, әле дә тора дәү паштет табалары. Шул дәү табада бийек итеп қабартып, өстенә пабидлы җагып, өсләрен бизәкләп пешергәннәр паштетны *(каз.ар. сөйл.)*

## ***Төш, қақтөш***

Татар теленең җирле сөйләшләрендә *төш* сүзе чәкчәк яки вак бавырсак мәгънәләрендә еш кулланыла.

**Төш** – казан арты, бәрәңге, чистай, урал сөйләшләрендә. Әдәби телгә аның *қақтөш* > *қақ* + *төш* формасы кергән. Ул туй йоласы мәҗлесләрендә кулланыла торган ашамлык буларак искә алына. Табынга биргәндә төш өстенә, гадәттә, *қақ* ябып чыгара торган булганнар, шуннан *қақтөш* атамасы калган булса кирәк.

– Төш пешерәләр иде туйларга, бәбәй чәйләренә. Оста кешене чақырып пешертәләр иде төшне.

– Мич алдында табада җукә утыны белән пешерәләр.

– Қамырны басасың күкәйгә генә. Бармақ җуwанлыгы итеп тәгәрәтәсең, қаплап қуйасың тастымал белән қатмасқа. Кисеп-кисеп пешерәсең. Табаға туң май, сыйық май саласың. Бер

өч-дүрт мәртәбә болғатасың алып-алып. Шуннан соң төшне алып, тағын икенче, салқынрақ май өстәргә кирәк. Шулай итмәсәң, төш җарыла.

Төш өстенә бал белән писүкне эретеп сибәләр.

Пешергән кеше – пешергән сайын остара бара ул.

«Кул җиле» дип, төш пешерүчегә ниндидер бүләк биреп ризалаталар. Тағын икенче пешерергә дә кирәк була ич ул оста кеше.

### *Чәкчәк, чәкчәги*

**Чәкчәк** – камырны эрбет чикләвеге зурлыгында яки хөрмә кебек озынча итеп кисеп, кайнап торган сары майда пешереп, барысын бергә баллап катырып ясалган ашамлык.

Чәкчәк – татар халкының кунак каршылау, туй йолаларында, төрле мәҗлесләрдә яратып кулланыла. *Чәкчәк* сүзе фарсы теленнән кергән: *чәки-чәки – тамчы-тамчы.* Казан артының Арча, Балтач төбәкләрендә *чәкчәги чәкчәки* формаларының саклануы да шуныраслый. – *Чәкчәгиләрне бик уңдырып пешерделәр, қодаларға қайтқан чағында биреп тә җибәрделәр.*

### *Қоймақ, баз қоймағы*

**Қоймақ** – сыек камырдан табадан пешерелгән чәй яны ашамлыгы. Қоймақ сүзе *қой* тамыры һәм + *-мақ* кушымчасы ялганып ясала. Башка төрки телләрдә: башк. *коймак*, уйг. *куймақ*, кум. *къуймак.*

Элек сабан туйларына қоймақ пешергәлләр пичкә жағып. Қунақлар атлар белән килә ич, чәй эчәргә кергәлләр туғалларына, дусларына, таныш-белешләргә. Қунақ чәй эчәргә керсә, күңгелле була. Бер кеше дә кермәсә, бәйрәм булмый инде ул.

Қоймақ – әче қоймақ була, әче қамырдан. Қоймақ қамыры қалса, аны базга төшереп қуйғаллар. Аны икенче көнне дә пешергәлләр.

«Баз қоймағы, мич қоймағы» дип үзенә күрә тәмле қоймақ булды ул.

### *Таба ипийе*

Таба ипийе дип ипи қамырыннан табага салып пешерәләр, йуқарақ итеп. Балалар уқырга киткәнче тиз генә иртә белән пе-

шереп тә бирәләр. Ипи пешкәнче таба ипийе белән чәй эчеп китәләр балалар.

### *Ипи пешеру*
### *Мич җагу, мичнең көлен себеру*

– Мичкә салам җағып, мунчаладан җасаған зур пумала белән мичнең көлен себерәләр, пумаланы суга манчып-манчып.

Мичкә алты түгәрәк ипи салабыз.

– Ипи ул сәғәт йарымда пешеп чыга. Ул ипинең тәмне исләре бөтен урамға чыга.

Җилпуч белән җилпеп чүпләрен чығарғаннар ашлықның. Ипиләр шуңга күрә бик тәмне, хуш исле булған.

Ипи куwасында бер чиләк судан қамыр басабыз озақ итеп.

Тал чыбығыннан үреп җасаган чара табақлар булды. Шуларға тастымал җәйеп, ипиләрне әwәләп салып қуйабыз күпертергә. Өсләренә тастымал җабып.

Бер дәү пичкә алты ипи сыйа тушылай. Пичнең бер қултығына теге кечкенә ипине салып пешерәбез әле. Шул ипине бер әбигә, җә абыстайга илтеп бирәбез.

Аны балалар: «Мин илтәм дә, мин илтәм», – дип торалар ыйы. Теге әби бер шақмақ шикәре булса, шуны wақлап, балаларға бирә икән, җаным. Қуwандырып җибәргән балаларны. Ул wакытта кибетләрдә шикәр-камфитлар бик жуқ ич.

### *Ипи башы*

– Ипи башы қалдыралар куwаста. Шуны башта су салып әчесен чыгаралар да икенче су салып әчетәләр қамырны. Ипиләр бик тәмле була торған ыйы.

### *Куwас төбе ипийе*

– Сәдәхәгә куwас төбе ипийе җарамый. Аны ипи башы итеп қалдыралар. Аны әwәләп он эченә салып қуйалар. Икенче ипи пешергәндә шуның белән қамырны әчетәләр. Ипи башын суға изеп, ипи қамыр басалар.

### *Чүперә*

– Казанга барган кеше бик озак эзләп кенә базардан бармақ хәтле итеп төргән чүперә алып кайтыр ыйы.

– Шул Қазаннан алып қайтқан чүперә белән ғәйет қоймағы пешерәләр ийе.

### ***Бәбәй чәйе, бәбәй қотлау, әлбә***

**Әлбә** – майга он, шикәр комы салып пешерелә торган татлы чәй ашы. Җирле сөйләшләрдә ул йола ашы буларак билгеле һәм аның төрле фонетик һәм лексик вариантлары бар: *әлбә, алба, алwа, кәлбә, халwа, қомәлбә, қомғабар* һ.б.

*Әлбә* – гарәп теленнән кергән сүз (гар. *halva*)[1]. *Әлбә* – татар халкының борынгылыкны нык саклаган архаик төркемнәрендә, әстерхан һәм керәшен сөйләшләрендә, себер диалектларында туй һәм үлгән кешене җирләү, искә алу, бәбәй туу мәҗлесләрендә кулланыла, изге һәм тылсымлы йола ашы булып санала.

– Әлбә пешергәлләр элек. Ул бик қадерле аш булган, он белән май, шикәрне қайнатып җасағаллар әлбәне. Аны пешерә белә торған оста кешегә қушып пешерткәлләр әле әлбәне.

Җыруwы да бар ич:

Ашыйсымнар килә әллә ни,
Табаларда пешкән әлбәни.
Ашау-эчү безгә берни түгел,
Бер күрешүләре әллә ни.

– Әлбәне бәбәйләгән кешегә пешереп аппаралар ыйы: «Хәл керсенгә, сөте булсынга».

Сары майлар, шикәр, он белән оста кеше пешерәдерийе. Хәзер менә ул әлбәне пешерүләр бетте инде.

### ***Бәбәй чүперәкләрен җуу***

– Бәбәй чүпрәкләрен җудым да җуған суны ишек алдына сиптем.

Күршем әйтә:

«Ай, Мәймүнә, балаларың очып бетә бит. Синең җаныңда берсе дә қалмас. Ишек алдына сипмә бәбәй чүпрәкләрен җуған суwыңны», – диде.

Шуннан сун алай итмәдем, җуған суларны бер урынга гына түктем.

---

[1] Фасмер М. Этимологический словарь русского языка. М., 1987. С. 217.

### ***Ипи, бер җомарлам атламмай***

– Менә килелләре бәбәйләгән дә, ди, бәбәй чәйенә қотлап алып барырга әйбер жуқ, ди. Әни әйтә: «Мин менә кичәгенәк ипи салдым. Қызыл ашаулыққа бер ипи қуйыйқ та, бер җоморо атламмайны қуйыйқ та җиңги җанына төшеп меник, бәбәйләгән», – ди.

Шулай барғаллар. Бер ипи, бер йомарлам атламмай белән хәл белергә барғаллар.

Алар бик рәхмәтләр әйтеп қалғаллар. Әле үзләре дә күчтәнәч биреп җибәрәләр. Тақта чәйнең җартысын бүлеп, бер әчмуха чәй дип, шуны күчтәнәч итеп үзләренә биреп җибәргәлләр. Бик қуwанышып қайтып кергәлләр.

### **Пәрәмәч, қабартма**

– Бәбәй ашына бер дә чамасы булмаса бер таба пәрәмәч, җә қабартма булса да пешереп барырлар ыйы.

### ***Сугым***

Татар халкында элек-электән, игенчелек белән беррәттән, хайван асраучылык та төп урыннарны алып торган. Бигрәк тә ат һәм сарык итләре күп кулланылган. Шулай ук сыер, бозау, кош итләрен, аерым төбәкләрдә кыргый җәнлекләр итен дә яратып файдаланганнар.

Ашатып симертелгән, суяр өчен әзерләнгән эре мал: ат, сыер яки тана – **сугым** дип атала.

– Сугым суйгач, иң беренче муйын итеннән алып пешерергә салалар. Ул йомошақ, тәмле ит була, тиз пешә. Шулпа кайнап тора. Қабырғалы ит тә саласың.

### **Сугым суйганда куwырдык пешерү**

– Сугым суйганда *қуwырдык* дип, үпкә-баwырны қыздырып сугымчыларга ашаталар. Итне дә майга салып қыздыра «қуwырдық» дип. «Тиз пешә торган әйбер», дип ашаталар сугымчыларга.

### ***Суқта***

**Суқта** – мал суйгач эчәгесенә ит яки бавырын, суган, ярма белән аралаштырып тутырып, шулпага салып пешерелә торган

ашамлык, тутырма. *Сукта* сүзе шушы мәгънәдә казан арты, бәрәңге, нократ сөйләшләрендә билгеле. Борынгы төрки телдә *soqtu*. Башка төрки телләрдә: карач.-балк. *сохта*[1], кум. *сокъта*[2], чув. *сухта*. Мари телендә *сокта, шокта*[3].

– Суқта да пешерделәр. Эчәгене әйләндереп әйбәтләп жуwалар, түлке пешекләмиләр.

– Пешектергәч әйбәт булмый суқта. Пешектермәгән эчәккә тутыралар йарма белән итне, үпкә-баwырларын машинада чыгарып. Шулпага салганда аны буш кына итәргә кирәк. Шулпада ул киңгәйә, сузайа, йарылмый, бүртеп тулып пешә. Кисеп-кисеп ашый торган була.

### *Угыз тәбәсе*

Сыер бозаулаганнан соң берничә көнгә кадәр савыла торган куе сөт әдәби телдә *угыз* дип атала. Терлекчелек белән шөгыльләнгән бик күп төрки халыкларда, шул исәптән татар халкында да угыз пешерү, угыз белән күршеләрне сыйлау йолалары күп сакланган.

– Сыйыр бозаулагач, сыйырны саwабыз да угыз сөтен мичкә тәбә итеп тығабыз. Ул сап-сары, тәмне була. Күршегә кертәбез, чақырып та ашатабыз.

Сөбханалла,
Хәләл ризыклар булсын,
Татлы нигъмәтләр булсын,
Игелекле маллар булсын,
Игелеген күреп йәшәргә насыйп булсын!

Теләмичә генә булмый, теләргә кирәк.

---

[1] Отаров И.М. Очерки карачаево-балкарской терминологии. Нальчик, 1987. С. 50.

[2] Гаджиева С.Ш. Материальная культура кумыков XIX–XX вв. Махачкала, 1960. С. 149.

[3] Сепеев Г.А. Традиционная пища луговых марийцев // Археология и этнография марийского края. Йошкар-Ола, 1981. С. 117.

## Арча районы авылларында сөйләп мәгълүмат бирүчеләр

**Апаз:**
Рәхмәтуллина Үлмәскамал Сәмигулла кызы (89 яшь)
Мөхәммәтҗанова Рәисә (1932 елгы)
Гыйльмуллина Клава Николаевна (1939 елгы)

**Ак чишмә авылы:**
Сабитова Рәшидә
Хәбибуллина Мәскүрә (92 яшь)
Хафизова Венера (31 яшь)

**Байкал авылы (Яңа Тазлар):**
Зарипова Рәмзия (57 яшь)
Вәлиуллина Мәскүрә (77 яшь)
Бәйрәмова Суфия Юныс кызы (1948 елгы)
Гыйниятуллина Мәдинә Вафа кызы (1940 елгы)
Сәмигуллина Гүзәл (40 яшь)
Гыйниятуллин Сөнгатулла (1939 елгы)

**Гөберчәк авылы:**
Габидуллина Халидә Кыям кызы

**Каргалы авылы:**
Әхмәдуллина Зәйнәп
Нуриева Фирая (77 яшь)

**Кызыл Яр:**
Шәрипова Маһирә Фазылҗан кызы (95 яшьтә)
Шәрипов Илдус (56 яшь)
Фазылҗанова Тәнзилә (1952 елгы)
Галиева Хәдичәбикә Лотфулла кызы (83 яшь)
Хәйруллина Вәсилә Илгиз кызы (1949 елгы)

**Кырлай авылы:**
Зарипова Рәшидә (1938 елгы)

**Кушлавыч авылы:**
Вәлиева Мәрхәмбикә (1940 елгы)
Галимҗанова Рабига (1930 елгы)

**Мәмсә:**
Шәфигуллина Минзифа Габдулла кызы (75 яшь)

Шәфигуллин Шәйдулла Шәрифулла улы (76 яшь)
Касыймова Гарифә (1917 елгы)
Әхмәтханова Сәрия (1932 елгы)

**Пөшәңгәр:**
Фазылҗанова Фәүзия (1936 елгы)

**Пүчинкә-Поник:**
Павлова Елизавета Васильевна (80 яшь)
Әпсәләмова Нурия Тимерхан кызы (77 яшь)
Әпсәләмов Шәриф Шәйхулла улы (1938 ел)

**Сәрдәбаш:**
Сәмигуллина Римма
Николаева Ника
Ефимова Таисия
Осипова Вера
Семенова Александра Николаевна (1940 елгы)

**Сеҗе авылы:**
Корбанова Рәзинә
Камалиева Ләлә (1941 елгы)

**Ташкич авылы:**
Нәҗипова Илсөяр Әхмәди кызы (1943 елгы)
Таҗиева Бәрия Хәлим кызы (64 яшьтә)

**Түбән Оры:**
Нуриева Нәфига Сәлахетдин кызы (84 яшь)
Шәрипова Тәслимә (75 яшь)
Мөхәммәтшин Бари Фәйзи улы (1939 елгы)

**Шура авылы:**
Вәлиев Камил Кави улы (58 яшь)
Кашапова Рәшидә
Вәлиева Фәридә
Хәсәнова Клара

**Шурабаш авылы:**
Петрова Зинаида (83 яшь)
Акбарова Онай (80 яшь)
Максимова Лыстакай (1936 елгы)

## БАБАЛАР СҮЗЕ – АКЫЛНЫҢ ҮЗЕ

**Халык иҗаты үрнәкләре**

*Ильмир Ямалтдинов*

Казан арты, аерым алганда әлеге район җирлегендә яшәүче халкыбызның фольклоры, авыз иҗаты белән кызыксыну ике йөз елдан артык элек башлана дип әйтсәк, һич тә ялгыш булмас.

Россия Фәннәр академиясе эшчәнлегенең аерылгысыз бер юнәлеше буларак, күпмилләтле илдә яшәүче халыкларның тарихын, этнографиясен өйрәнү өчен экспедицияләр оештырыла. Казан университеты галимнәре хезмәтләрендә дә кыр тикшеренүләре нәтиҗәләре яктыртыла. Башка чыганакларда да татар халкының тарихына, рухи мирасына һәм фольклорына караган материаллар бар[1].

Арча төбәгендә халык авыз иҗатын өйрәнү буенча эш татар галимнәре һәм әдипләре тарафыннан дәвам итә. Бу өлкәдә, иң беренче итеп, әлеге төбәккә турыдан-туры мөнәсәбәте булган бөек шагыйребез Габдулла Тукай исемен әйтергә кирәк. Ул кечкенәдән туган ягының, татар халкының рухи байлыгын, шул исәптән фольклорын күңеленә сеңдерә барган, халык лирикасы үрнәкләрен халыктан җыйган һәм үзенең иҗатында кулланган.

Алга таба халык иҗатын җыю һәм өйрәнү буенча К. Насыйри һәм Г. Тукай традицияләрен Х. Бәдигый дәвам итә.

---

[1] Ямалтдинов И.И. Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 35–36.

1906 елның көзендә фәнни командировкага Казанга венгр ориенталисты Юлий (Дюла) Мессарош килә. Йосыф Акчура тәкъдиме буенча мәдрәсә шәкертләре арасыннан Хуҗа Бәдигый аңа татар телен өйрәнү буенча ярдәмче һәм авылларда йөрү өчен юлдаш итеп билгеләнә. 1907 елның язында Арча районы Түбән Курса авылына баралар. Алар икәүләп Арча төбәгендәге татар авылларында булып фольклор материаллары җыялар. Мессарош киңәше белән Х. Бәдигый үзе язып алган материалларны тәртипкә сала һәм бастыру өчен әзерли. Венгр галиме киткәннән соң да Х. Бәдигый тагын дүрт ел дәвамында халык арасында йөреп, төрле жанрлар буенча бай материал язып ала һәм тупланган байлыкның бер өлешен 1912–1914 еллар дәвамында «Халык әдәбияты» дигән уртак исем белән «Мәкальләр», «Табышмаклар, такмаклар, такмазалар», «Бәетләр» һәм «Җырлар» җыентыклары итеп бастырып чыгара[1].

1935 елда Казан марксизм-ленинизм институтының беренче фольклор экспедициясе оештырыла. Үзләренең укытучылары җитәкчелегендә әлеге институт студентлары Арча районының да берничә колхозында булып такмаклар, бәетләр, әкиятләр, халык уеннары, мәкаль-әйтемнәр һәм табышмаклар язып алалар[2].

1951 елда хәзерге Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Казан артына иң беренче фольклор экспедициясе атаклы фольклорчы галим, филология фәннәре докторы Хәмит Ярми җитәкчелегендә оештырыла. Экспедиция эшендә түбәндәге хезмәткәрләр катнаша: Х. Ярми (җитәкче), Х. Гатина, Э. Касыймов, Н. Гыйззәтуллин, М. Богданова. Галимнәр 27 июньнән алып 30 июльгә кадәр Татарстанның Кукмара, Балтач, Чепья, Арча, Чүриле, Кызыл Юл, Әтнә районнарының авылларында булалар. Фольклорчылар Арча районының Пөшәңгәр, Чүриле, Сеҗе, Сикертән, Казаклар, Масра, Казанбаш, Арча, Наласа, Урта Аты, Субаш Аты, Орнашбаш, Кушлавыч, Югары Сәрдә авылларын өйрәнәләр. Аларның экспедиция хисапла-

---

[1] Хуҗа Бәдигый: тел галиме, фольклорчы, педагог: фәнни мәкаләләр җыентыгы. Казан, 2008. 192 б.

[2] Ярмухаметов Х. Татарская советская фольклористика за 40 лет // Известия Казанского филиала АН СССР. Юбилейный сборник. 1957. С.176.

рына күз салсак, түбәндәгеләрне күрәбез: 6 әкият, 1543 җыр, 6 бәет, 24 халык уены, Тукай турында 1 истәлек, 20 юл такмаза язып алынган[1]. Шулай итеп, Институт хезмәткәрләре, Арча районының 14 авылында булып, фән өчен бик кыйммәтле халык иҗаты материалларын туплап кайтканнар.

Төрле елларда бу төбәктә галимнәр, язучылар, студентлар тарафыннан тупланган халык иҗаты әсәрләре Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана. Әлеге материалларның бер өлеше Институт әзерләгән унике томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасында (1975–1988) һәм соңрак нәшер ителгән әлеге җыелманың «Балалар фольклоры» китабында (1993) басылган, яисә җыентыкларның искәрмәләрендә вариант буларак күрсәтелгән.

Һәм, ниһаять, 2016 елның июнь ахыры – июль башында, нәкъ 65 елдан соң, әлеге төбәккә яңадан комплексы фәнни экспедиция оештырылды. Арча районында урнашкан 15 авылда (Пүчинкә-Поник, Ташкич, Сеҗе, Кызылъяр, Түбән Оры, Байкал, Шурабаш, Шура, Сәрдәбаш, Шекә, Кызыл Игенче, Пөшәңгәр, Апаз, Мәмсә, Акчишмә) булып, шәхсән мин үзем бер атна эчендә 200 дән артык берәмлек авыз иҗаты үрнәкләре язып алып кайттым.

Арча районында яшәүче татарлар арасында сан ягыннан карганда, иң киң таралган авыз иҗаты жанрларыннан җырларны аерып чыгарырга була. Биш дистәдән артык җыр язып алынды. Аларның күбесе кыска җырлар һәм такмаклар.

Озын көйләр Сеҗе, Түбән Оры, Шура авылларында күбрәк сакланган, «Олы юлның тузаны», «Рәйхан», «Сарман буйларында» һ.б. җырларны исә һәрбер авылда очратырга була.

Автор җырлары да халык тарафыннан бик яратылып башкарыла.

Шура авылында Бөек Ватан сугышы ветераны Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль улыннан (1923 елда туган), татар җырлары белән беррәттән, сугыш вакытында окоплорда отып алган украин һәм рус җырлары да язып алынды.

[1] Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 42 коллекция, 1 папка, 2, 5 сак. бер.

Ияләр, җеннәр турындагы мифологик хикәятләр халык арасында борынгыдан сөйләнеп килгән, халык аларга ышанган, буыннан-буынга тапшырган. Бигрәк тә, татар халкында киң таралганы – атның ялын үрүче абзар иясеннән башлап, Арча төбәгендә генә була торган, аерым алганда, Ташкич авылы янына эт яки бүре кыяфәтендә килүче Рус Понигы сихерчеләре һәм мунчадан өйгә таба баручы утлы шар формасындагы җен[1], Байкал авылы башында Лумба елгасы суына төшә торган убыр уты һәм туйдан-кунактан кайтып килүче җен-пәриләр[2], Шура авылында күмгәнче үк бугазларына имән чөй кагылмаган мәетләрнең кабердән чыгып, ачулары калган кешеләргә зыян салучы Убыр һәм мич арасыннан шакмаклы күлмәк киеп, әби кыяфәтендә чыга торган өй иясе[3], Пөшәңгәр авылында нәкъ шимбә көнне сәгать уникедә җенле наратка тәгәрәп килеп сүнүче ут һәм район түрәсе кыяфәтендә, төнлә, килеп барган җиреннән кызарып юкка чыгучы җен[4], Шушмабаш авылы тирәсендәге елга буенда, атның дирбиясен кире җиккән очракта гына котылып була торган адаштыручы җенле урыннар һәм Акчишмә авылы тирәсендә кеше адаша торган Кутлый дигән җир[5]ләр турындагылары.

Тарихи һәм топонимик риваятьләр язып алынды, авыл тарихларына (Шура, Кызыл Игенче, Пөшәңгәр, Мәмсә, Апаз, Акчишмә һ.б.) бәйлеләре шул авылларда яшәүче милләттәшләребезнең үз тарихларына битараф булмаганлыкларын раслый. Түбән Оры авылында «Түбән Орыны су басу», Шекә авылында «Яхъя хәзрәт» яисә «Шекә пәриләре» турындагы риваятьләр ха-

---

[1] Ташкич авылында Зарипов Зәбир Мөхәммәтзариф улыннан (1947 елгы) язып алынды.

[2] Байкал авылында Галәветдинов Баһаветдин Галәветдин улыннан (1930 елгы) язып алынды.

[3] Шура авылында Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль улыннан (1923 елгы) язып алынды.

[4] Пөшәңгәр авылында Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан (1930 елгы) язып алынды

[5] Акчишмә авылында Гарипов Заһир Гариф улыннан (1930 елгы) язып алынды.

лык күңелендә саклана һәм буыннан-буынга тапшырылып бара дигән нәтиҗә ясарга була.

Арча төбәгендә, нигездә, барлык татар халкы өчен хас уеннарның тасвирланмасы сакланган. Түгәрәк уеннан башлап, «Лапталы», «Ал тирәк, күк тирәк» белән беррәттән, аулак өйләрдә традицион уйналып килгән «Наза», «Йөзек салыш», «Йолдыз санашлар» да бар. Кич утыруларда, шулай ук, «Сакта», «Тыкрык» һ.б., ә балалар тарафыннан «Шакмак», «Туп», «Сызыкташ», «Кузна» уеннары аеруча яратып башкарылганнар.

Берничә ел элек туксанынчы дистәләрен вакласалар да, малай вакытларында уйнаган уеннарын Арча районы Шура авылында яшәүче Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль улы (1923) һәм Шекә авылыннан Кәримов Хәбир Кәрим улы (1925) бүген дә бик яхшы хәтерлиләр. Р. Исмәгыйлевтән «Шар», «Таштеки», «Күкәй», «Чокыр шар», ә Х. Кәримовтан «Каурый», «Городки», «Чебен», «Шар», «Кузна», «Кәҗә ябыш» уеннарының тасвирланмасы язып алынды. Чагыштырмача яшьрәк буын вәкилләре Арча районы Сәрдәбаш авылында гомер итүче Архипова Вера Васильевнадан (1953) «Шакмак», «Туп», «Тыкрык» һәм Кызыл Игенче авылында яшәүче Сәлахов Вил Бари улыннан (1938) «Ун агай», «Бура таягы», «Кәҗә мае чыгару», «Сызыкташ» уеннары язып алынды.

Әкиятләргә килгәндә, 1951 елда 6 әкият язып алынган һәм архивта саклана. «Татар халык иҗаты»ның әкият томнарында әлеге әкиятләрнең дүртесе («Фикерле кыз» әкиятенең варианты буларак, «Уңган кыз»; «Мулла белән мөэзин»нең варианты буларак, «Күрәзәче» һәм «Әкият»; «Мулла белән мужик»ның варианты буларак, «Ун сыер» әкияте) күрсәтелә[1]. 2016 елгы экспедициядә күләмнәре ягыннан зур булмаган «Кәҗә белән сарык»[2],

[1] Татар халык иҗаты. Көнкүреш әкиятләр. Өченче китап / томны төзүче искәрмәләр әзерләүче Л.Ш. Җамалетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 360 б.

[2] Кызылъяр авылында Шәрипҗанова Кадрия Сәлих кызыннан (1933) һәм Пөшәңгәр авылында Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан (1930) язып алынды.

«Шомбай»[1], хайваннар турындагы, «Бүре белән төлке» әкиятенең варианты буларак, «Абзый белән төлке»[2] әкиятләре язып алынды.

Балалар фольклорының «Багу поэзиясе» әсәрләреннән берничә бишек җыры, юаткыч, мавыктыргыч сөйләм такмагы, шулай ук «Күңел ачу» һәм «Уен фольклоры» үрнәкләре язып алынды.

Арча районында традицион рәвештә «Әлли бәлли бәү итә» һәм «Аллаһу-Аллаһу» бишек җырлары киң таралган. Аларның берничә вариантын теркәдек.

Мөнәҗәтләр белән бәетләр сирәк очрады. Халыкта киң таралган «Бердер илаһым бәнем» белән барлыгы ике мөнәҗәт һәм «Поши бәете» дип аталган сатирик бәетнең өзеге язып алынды. Бүгенге көндә әлеге бәет халык күңелендә тулысынча сакланмаган. 1956 елда «Поши бәете»н Пөшәңгәр авылында Нәгыймә Борһановадан (1884 елда туган) язучы Нурихан Фәттах язып ала һәм әлеге бәет «Татар халык иҗаты»ның «Бәетләр» томында басылып чыга:

Бисмиллаһи, без әйтик, кәкре әйтмик, төз әйтик,
Пөшәңгәрләр поши суйган, бәетен әйтеп йөдәтик.

Пөшәңгәрнең болынында йөрдем аяк чылатып,
Нәләт суккан Пөшәңгәрләр поши суйган җылатып.

Нәдершаның бакчасына быел карга төшмәгән,
Тәкә ите арасында поши ите пешмәгән.

Хәмидулла кар көридер, бик тар, диләр, көрәге,
Хәмидулла, чыкма урамга, килгән поши өрәге.

Поши япкан абзарыңны аждаһалар күтәрсен,
Хәмидулла, син суйгансың, җәһәннәмгә китәрсең.

---

[1] Шура авылында Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль улыннан (1923) язып алынды.

[2] Пөшәңгәр авылында Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан (1930) язып алынды.

Сикереп мендем тирәккә, яфраклары кирәккә.
Хәмидулла поши суйган җыенга ите кирәккә.

Пөшәңгәрнең күпере тимер түгел, җиз генә,
Пөшәңгәрнең урамына поши кермәс тиз генә. [1]

Әлеге бәетнең вариантларын 1954 елда Зәй районы Налим авылында Шәех Хәбриевтан (1889 елда туган) Х. Мәхмүтов, 1978 елда Арча районы Апаз авылында Гөлфирә Тимергалиевадан (1939 елда туган) Ф. Әхмәтова язып алган[2]. Алар Институтның Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Бәеткә охшатып язылган бер-ике шигырьне исәпкә алмасак, без өйрәнгән авылларда бәет чыгару традициясе югалып бара.

Табышмаклар һәм паремияләр үрнәкләре дә өлкән буын вәкилләре күңелендә генә саклана.

Йола фольклорына килгәндә, йолалар, гореф-гадәтләр турындагы мәгълүматларны җырлары, уеннары, махсус әйтелә торган сүзләре белән мөмкин кадәр бер күренеш буларак язып алырга тырыштык.

Татарстанның Арча районында яшәүче милләттәшләребедән язып алынган, халкыбызның буыннан буынга, телдән телгә күчеп килгән кайбер фольклор үрнәкләрен (язылып алыну тәртибендә тематик бүлекчәләргә урнаштырып) тәкъдим итәбез.

## Мифологик хикәятләр
## (ияләр, җеннәр турында)

Ашаган җиреннән (ат, сыер) почмакка карап тора ие. Абзар иясе булгандырмы.

*Арча районы Ташкич авылында*
*Рәхимуллин Шаһинур Шаһиҗиһан*
*улыннан (1936 елгы) язып алынды*

Елганың бу ягында Урыс Понигы бар ие. Шул Поникта колдун маржалар бар дип сөйли торганнар ие. Таралды ул авыл.

---

[1] Татар халык иҗаты. Бәетләр / томны төзүчеләр Ф.В. Әхмәтова, И.Н. Надиров, К.Б. Җамалетдинова. Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. Б. 179.

[2] Күрсәтелгән хезмәт. Б. 322.

Шул Поникка мендем дә кино куярга, Вәгыйзь абый өчен. Шуннан төшеп киләм, ай яктысы, малай, хәзер менә Насыйри абыйлар бакча башына җитәм инде почти. Карыйм каршыда этме, бүреме утыра. Колдуннар төрле кыяфәткә керә дип сөйлиләр ие. Шуннан хәзер сызгырып карыйм, кычкырып карыйм. Селкенми дә, утыра теге. Мин бит әле үсмер. Ул тегендәрәк әле ул. Монда кайтып җиткәнче. Хәзерге конюшни турасында. Хәзер йөгереп менеп киттем фермага таба, бәхеткә кар каты тегендә, батмый. Ярар, ферма ягына мендем, кайтам. Моннан әйләнеп төшәргә шикләнәм. Мирсәет абыйлар итәгенә бардым теге елгадан. Басманың бер як башында тагы утыра шул. Обыкновенный этме, бүреме шикелле. Сорырак. Шуннан хәзер, әй булса булды инде дип, йөгереп төшәдерием, теге дә басмадан юл биргән шикелле калды, мин басмадан ничек чыкканны сизми дә калдым.

* * *

Җен. Элек бөтен кешедә мунча юк иде. Сәхап абыйлар мунчасына кердек. Хәллерәк кешедә генә бар иде мунча. Мин кечкенә малай, әни белән кердек. Менә шунда түшәмнән әллә нинди туфраклар коела башлаган шикелле булды теге мунчада. Тәрәзәдән карыйбыз мунчадан өйләренә таба менә шундый клубок ут китте. Шуннан хәл китте минем. Әни әйтә:

– Улым, җен ул. Өйдә чыгабыз, – дип тиз генә өскә яртышар чиләк су сиптек тә, чыгып ычкындык без аннан.

*Арча районы Ташкич авылында*
*Зарипов Зәбир Мөхәммәтзариф*
*улыннан (1947 елгы) язып алынды*

### *Убыр уты*

Төннә йөргән кешегә – убыр уты, диләр. Убыр уты. Түгәрәк ут ди ул. Авыл башында су бар, әнә шул суга хәтле Лумба елгасы суы шунда килә. Безгә кушыла ул авыл башында. Әнә шунда хәтле килгән тәгәрәп. Шул судан чыкмый икән ул. Кире юкка чыга китә. Үзем күрмәдем, картларның сөйләгәне бик күп шундый.

* * *

Әти белән Габдрахман абый дигән, күршедә (күптән түгел үлде әле ул). Икесе ат белә урманга барганнар да агач урларга дип, шуннан кайткан вакытта авыл башына җиткәнченнән 10лап ат боларның каршына очраган. Болай итеп күренеп киләләр икән дә чыжж итеп узып китәләр икән. Туйданмы, кунактанмы кайтышы булган, җеннәрме, пәриләрме.

Болар урманнан кайта, теге каршыларына килгән. Сразу юк була. Җеннең бернәрсәсе инде, күзләре елкыр.

Аның атлары да менә узып киткәндә күренми дә шундый зәһәр инде.

* * *

Җеннәр-ниләр төбенә-тамырына төшеп булмый шул. Аның үргәнен дә күргәнем дә бар. Ат җиктем.

Аннан безнең Шекә (авыл исеме. – *И.Я.*) әби әйтә торган ие (әни Шекәнеке): «Менә шунда җен алдына килгән», дип. *Җенме, пичурамы* нәстә күргән кешеләр күп булган инде. Әнә шул бабайны әби сөйли торган ие. Бабаең шулай итеп күргән, фәләнтөгәл дип.

*Арча районы Байкал авылында*
*Галәветдинов Баһаветдин Галәветдин*
*улыннан (1930 елгы) язып алынды*

Мин гомумән ышана торган кеше түгел. Әниләр ышанды конешно. Әни сөйли, әти ышанмый торганые.

Бервакыт әвен безнең бакчаның теге башында. Әти:

– Тукта утны карап кайтыйк әле, – дип әни белән бара, әни артта, кыш көне һавада нәкъ кеше формасында бер нәрсә очып килә теге яктан. Убыр дигән нәрсә бар. Убыр бу. Каз бугазлы кешеләр бар. Ике ягы җуан булып кабарып тора. Шундый кешеләрне күмгәнче имән чөй какканнар, чыгып йөрмәсен, кабердән чыга икән бу, тишек ясый да үзенә. Шуннан чыгып ачулы кешеләрне авылда яндырып йөри. Яндыра. Берәүдә ачуы калган икән. Ул тегеннән кып-кызыл булып очып килә. Җир астыннан чыгып тегенең лапасына килеп төшә җә өенә дә, менә пожар. Әти белә әни барганда, очып бара, ди. Әни әйткән:

– Ай, әвенгә генә төшмәсә ярар иде.

Бу зиратка төшә.

Шуннан әни әйтә: чистый җиргә шәүләсе төшеп бара, ди. Һавадан кып-кызыл кеше оча. Кеше фурмылы, аяклары-куллары бар, дип сөйләде миңа әни. Узып киткән. Шуннан зиратка төшә дә, үзенең чокырына тагын кереп җата бу. Ул инде эшен эшләгән.

Берәүнең өенә ут төрткән, җә берәүнең өенә кереп әйберсен апчыгып киткән. Менә убыр дигән нәрсә монсы. Убыр кеше булып киенеп килә, чапаннар киеп. Ату болай ялангач килеш тотып алалар бит инде аны. Тегене берәү зиратта саклап торган курыкмаган кеше, кем каберенә керә икән дип. Әһә, тапкан, шушы кабернеке икән убыр, авылны җандыручы кереп киткәндә тегенең чапан итәген кискән дә алган. Шуннан кем икәнен белгәннәр. Әһә, шул кеше, вот казыйбыз да муенына имән чөй кагабыз, ату кагылмагандыр, чыгып җөри. Казыйлар да аннан кагалар. Авыл халкы хуҗа. Авыл халкына каршы торалмыйсың.

Менә шушы өйдә. Әти сугышта 1914 елны, әни дә, тагын бер килен бар. Ансының да ире кавалерист, ул да сугышта. Аның баласы юк, безнеке бар. Апай моның хәтле *(күрсәтә)* бәләкәй кыз булган. Хәзер 3 хатын-кыз гына инде бу өйдә. 2 хатын-кыз, 1 се бала. Апай үзе генә өйдә калмый икән. Без уракка китәбез, үзең кенә кал, йокла, ишегеңне бикләп китәбез. Тегендә басуда эссе дип аббармаска уйлыйлар, урак өстендә.

– Юк, дигән, анда, өйдә, мич арасыннан бер шакмаклы күлмәк кигән әби чыга да мине «тотам, тотам» дип йөри, мин һаман тоттырмыйм, җөгерәм. Өйдә шундый әби бар, дип җылый икән һаман калмыйм, калмыйм, басуга барам сезнең белән дип.

* * *

Минем әни Шурабашныкы. Әни килен булып килгәч тә, атка сулар эчертәсе бар. Шунда әтинең абыйсы да монда тора. Ике семья. Бу безнең төп йорт. Урам буйлап ие. Өч йорт салдым инде. Тегендә урам буйлап ие, хәзерге гараж урынында әтиләр-бабайлар урынына салам, бай булам дидем плотникларга, көләләр, әйдә бай булырсың.

Тегеңә этинең абыйсы әйткән:

– Килен, – дигән, – тамак кыргалап кер су аббарганда, атка су биргәндә.

Безнең җорт иясе карт инде, – дигән, – кеше килә башлагач ат янына чыга да, син ишекне әчештән чыгып китә, абзар өстенә менә дә китә, шунда җоклый, – дигән. Аннан кеше киткәч тагы ат җанына төшә. Ат иясе атны кашышлый ул, атны чип-чиста итеп куя, аннары җалын үрә. Аны әйтәләр инде, колхоз булгач колхозда да булды ул, кайбер атларның – җараткан атларның җалын хатын-кызлар чәче кебек итеп үрә абзар иясе. Әни шулай сөйли торган ие миңа.

Абзар иясе бар.

Йорт иясе дә бар. Әнә, апайга йорт иясе чыгып йөргән инде.

*Арча районы Шура авылында*
*Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль*
*улыннан (1923 елгы) язып алынды*

Армияга киткәнче ат караучы булдым.

Атның ялы үргән шикелле була ие, кай вакытта кисәкле-кисәкле булганы бар.

Өлкәннәрдә, шайтаннар һәм җеннәр үрә, дигән сүзләр бар ие.

Элек җенле, җен адаштырган тегенди-мондый дип күп сөйли торганнар ие. Күзгә күренә дип, күзгә күренде микән.

Ат белән барган вакытта атларны туктата торган ие дип әйтәләр ие.

Барасың – ат туктый, куасың – бармый, бер җиргә дә бармый дип сөйлиләр ие. Әзрәк бара, туктый, бара, туктый. Җен туктата аны. Шундый урыннар булган.

Зиратка төннә барсаң, утлар ялтырый, дип.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Семенов Михаил Васильевичтан*
*(1936 елгы) язып алынды*

Абзар иясен ишеткәләгән булды инде. Атларның ялларын үреп нитте, дип. Абзар ияләре булган инде ул. Ул әле дә бардыр инде. Матур булсын дип үргәндер инде.

* * *

Җеннәр-пәриләр дигәннәрне ишеткән булды инде ул.

Шушма якта ут булып тәгәрәп йөргәннәрен күргәләдек инде, басуда.

Аннан, шул пәриле урыннарда булып атлар белән чыкканда, чыгалмыйча, кешеләр адашып йөрүләр булган.

Кирәмәт дип йөртәләр шунда адашканнар.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримов Хәбир Кәрим улыннан*
*(1925 елгы) язып алынды*

Тота ат белән. Җибәрмиләр (җеннәр. – *И.Я.*) шунда урман буенда. Җибәрми, кая барырга белмичә, ничек итеп ычкынырга белмәгәннәр инде.

Әле анда менә бу Фаиллар кайдандыр кайтышлый, шунда адашып, шунда тик җатканнар беркая баралмыйча.

Шуннан соң ут төртеп җандырганнар, шуннан ычкынганнар, таң алдыннан кайтып кергәннәр тегеләр.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримова Бибирәшидә Гыйниятулла*
*кызыннан (1924 елгы) язып алынды*

Шайтан алыштырганга баш астына китап – дога китабы тыгасың. Аннан, бисмилла әйтеп, бөтен җирне сыпырасың. Тәрәз төпләренә ашый торган әйбер куярга ярамый.

Бисмилласыз әйбер торгызырга ярамый. Өсте әчек булырга ярамый. Бернәрсәнең дә. Алай булса, шайтан килми. Мин шушы гадәтләрне гомерем буе әни өйрәткәнчә тоттым. Әле дә тотам. Баш астына бала тугач та коръән куясың.

Кечкенә чакта аяклар, куллар селтәмәгән чакта бишеккә пычак куясың. Шайтан килми.

* * *

Бер җен күрдем. Әни безнең кәнсәләр карый. Әни өчен мин, әни курка безнең, төнге сәгать икеләрдә кәнсәләргә пичкә ягарга барам. Мин бернәрсәдән дә куркмыйдырыем. Шуннан

пичкә яктым, салам ягабыз, томаладым, идәннәрен себердем кәнсәләрнең. Шунда өстәл бар. Шундый җокы килә инде минем. Таң алды инде бу. Өстәлгә менеп яттым. Шуннан яткач та йоклап киткәнмендер инде. Ишек эчтән бикләнгән инде. Бер ир кеше (кәнсәләрнең ишек алдында зур салам эскерте бар икән дим) шуннан чыкты да кәнсәләргә килеп керде. Килеп керде дә минем җаңгакка китереп сукты бу. Шуннан мин сикереп төштем өстәлдән. Карыйм, җаңгак шундый каты авырта.

Шул арада персидәтел килеп чыкты. Шуннан Гыйльмулла абыйны ишек ачып керттем. Ник син кайтып китмәгәнсең.

– Менә, Гыйльмулла абый, шундый җокым килде дә, дим, бер ярты сәгать кенә ятып торыйм дип ятканыем, дим, өстәлдә шушылай җаңгакка суктылар минем, дим.

– Карыйм. Биш барнак эзе җаңгакта, – ди.

Менә шундый җен.

### *Җенле нарат*

Җенне әллә ничә күрдем. Безнең Атауда торганда бер җенне нарат бар ие юлда. Атау дигән урамда тордык без кыз вакытта. Шунда җулда нарат бар ие име. Шул җенне ие. Шунда шимбә көнне базар була торган вакытта бер чирмешне үтергәннәр, марины. Нарат төбендә. Шуннан наратка шимбә көнне 12 дә ут тәгәрәп килә дә болай итеп, шунда килеп шалт итеп сүнә. Атна саен бу. Без чыгып шуны карыйбыз. Аннан ул тәгәрәп төшеп үтергән кешенең тәрәзәсен шакылдатып йөри торган булган, борчып. Гел шулай шакылдаткан.

Шул наратны сугыш вакытында Апазның бер хатын ботакларын аптөшеп җаккан, корыган (ботакларын. – *И.Я.*). Ул хатын корышып үлде.

* * *

Нарат елгасы дигән ындыр барие безнең. Анда да шундый бер зур нарат. Ансы бар әл дә. Ул төше куркыныч итеп шаулап утыра.

Ындыр сугабыз. Безнең авылда бер телсез бар ие. Әйтсәң дә аңламый, нитсәң дә аңламый. Безне ындыр сугудан кайтарып

йөртмиләр инде. Шунда амбар өстендә йоклыйбыз инде. Амбар эчендә ир-атлар йоклый, өстә без – кыз-балалар йоклыйбыз. Телсез менде дә йокы бирми. Шуннан мин төштем дә телогрейканы бөркәнеп, каравылчы җылга кырыенда утыра, Гатият бабай инде ул. Шуның җанына чыгып утырдым шушылай итеп. Шунда гына ятып торыйм әле Гатият бабай, дип. Ярар, миңа да иптәш булырсың, ди, икебез дә шулай аш пешерә торган казан кырыенда утырабыз.

– Кызым, кызым, тор әле, – ди Гатият бабай. – Әнә, – ди, – район түрәсе бар иде ул вакытта районнан килеп җөри торган инде. Шул килә бугай, – ди.

Ул күн пәлтә киеп җөри торган ие. Өстендә күн пәлтә, ременьның каешлары да җалтырап тора. Кулына сумка тоткан, килә бу, без бер дә күзне алмыйча карап торабыз. Мин дә җоклаган булыр ием, ярый әле син төштең, ди. Каравылчы йоклаган дип гаепләрие, ди. Шул нарат төбенә килеп җитте дә, безнең күзалларын караңгы иттерде дә, сүнде. Кып-кызыл бүрек тикле ут булып. Икебез дә кереп киттек теге амбар эченә. Шул бабай очраган саен, үлгәнче әйтте, җаным:

– Кызый, без җен күрдек име, – диер иде. Әле дә җенне диләр аны, наратны.

Аның кайсы җен икәнен, кайсы шайтан икәнен кем белгән инде шунда. Бар да шул бер нәстәдер инде. Булган инде ул элек. Хәзер юк ул.

* * *

Җорт хуҗасы бардыр. Коръән укыйм белгән догаларым белән. Шул вакытта җорт өйрәннәре, җорт хуҗалары өчен дип дога кыласың. Аны беркайчан да калдырырга ярамый.

* * *

Абзар иясе дә бар. Абзар иясе сыерыңны яратмаса, сыер тирләп-пешеп шыбыр суга батып тора иртә белә. Аның өчен абзарга иске игәү кыстырып куясың, ярыкка. Безнең әл дә тора ул, сыер булмаса да. Аннан монандый таш элеп куясың, ташның тишеге булырга тиеш. Җылгада яткан таш инде. Шуннан тишек-

ле таш табасың да, җепне ташка бәйләп асасың. Ул абзар иясен тынычландыру өчен. Аннан абзарга кергән вакытта, хм-хм дип, һәрвакыт тамак кырып керәсең. Шулай язылган дин китабында. Мунчага да тамак кырып керәсе.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил*
*кызыннан (1930 елгы) язып алынды*

Безнең менә монда кибет яныннан чыгып китеп, менә бу урманнан чыгып Шушмабаш дигән авыл бар анда, ул безнең центр ие. Менә шунда Хуҗаңгыр дигән җылга бар. Шунда Шушмадан килгән бер апаең вак-төяк нәрсә сатып йөргән дә моның артыннан чыгып үтергәннәр, кабер бар анда, менә шунда чардуган тора. Шул төшкә эти белән (мин малай бит инде) мин этигә утырып бардым урманга, эти утынга барды, шуннан кайтырга чыктык. Юлда шәүлә, ну ут шәүләсе, яна инде. Әти, тиз генә атны туарып, яңадан җикте. Рәтен белгәндер инде, имеш, сбруйны кире якка җиксәң, ул тими. Шуннан эти мине утыртты да, шуннан узып киттек, бернәрсә юк, бернәрсә җанмый. Менә шундый адаштыра торган җирләр бар. Имеш, пәриләр теге нәрсәләр килми атка, килми. Пәри белән җен алар икесе бердер инде ул.

### ***Кутлый***

Аннан урманның теге ягында Кутлый дигән урын бар. Ул кайчандыр дилянкы булган, шунда авыллар ашлык чәчкәннәр инде. Шунда хәзер урман булып үсте инде ул. Менә шунда кеше адаша. Шундый җирләр бар. Шушмабаштан Акчишмәгә кайтканда ул Кутлый дигән җир.

Имеш, анда кеше үтергәннәр, кешенең җаны чыккан.

*Арча районы Акчишмә авылында*
*Гарипов Заһир Гариф улыннан*
*(1930 елгы) язып алынды.*

## Ышанулар, ырымнар, йолалар, гореф-гадәтләр

Берәр әйбер югалтабыз. Үлеп-бетеп эзлибез. Шуннан үземнең әни төшә дә кунакка:

– Ярар инде, табып бирегез инде, азапламагыз инде, – дип үзенчә шулай такылдый да, шунан теге әйбер табыла. Шундый ырым гына бар.

* * *

Абзар ияләре борчый, диләр. Бардыр. Бер дә юк түгелдер. Әбиләрнең абзарга, өйгә укый торган догалары бар. Укып, язып нишләтеп, шулай итеп язып бирде! Абзарда мин бик каты җыгылдым да, шуннан соң, шакшы җирдә җеннәр күп була, ди теге әби әйтте: Менә шушы язуны, абзарга кереп, сайгак астына тыгарга кушты инде.

* * *

Ничектер, балавызны эретеп, шуны төшертеп сурәт барлыкка килә бугай инде. Менә шулайрак иде бугай тәртибе. Савытка бугай. Оныттым инде.

* * *

Мин үзем өшкерәм. Башта 1–2 дога. Аннан соң әйтә торган сүзе: «Алтмыш ала күздән, мең кара күздән, куй күздән, күк күздән тигән булса, бер ирдән, бер хатыныннан, бер кыздан». Аннан тагы бер дога укыйм:

Вәл әззәли минәл афәти маваһы шифаһы вә рәхмәтен минәл мөэмининә илаһе сара.

Өф-өф-өф, дип өрәсең дә 3 тапкыр. Минем сылуым түгел, Гайшә Фатыйма сылуы, диелә.

Өф-өф-өф, дип бөтен гәүдәсенә, буе белә өрәсең башыннан башлап.

* * *

Бала йөрмәкче булып селкенеп-селкенеп тора бит инде. Шуннан соң пычакны апкиләләр дә. Имештер, анда тышаулаган дип ырымлыйлар инде. Менә мин улымның тышавын кисәм әле (дип

ырымлыйлар, пычак белән ике бот арасыннан, кискән шикелле рәвеш китерәләр, теге йөреп китсен өчен).

Безнең бер бала әбисенә менгән иде, баса да селкенеп тик тора, атларга курка, үзе басып тора. Каяле дип, я кайчы, я пычак апкилеп менә мин аның тышавын кисим әле дип, янәсе аны тышаулап куйганнар.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Хәкимова Әлфия Малик кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды*

Су анасы – Сылубикә,
Су атасы – Сөләйман.
Мине тотма, шуны тот, –

дип чишмәгә әйбер салулар. Шул әбиләрдән «суга сокланмагыз» дигән сүзләр калган.

Чишмә суларына төшкән вакытта суга сокланмаска кушалар ие инде. Янәсе, су алмасын дип, су тота ул, дип, аңа ышанабыз.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Гарифҗанова Флюра Галимҗан*
*кызыннан (1942 елгы) язып алынды*

**Яңгыр теләү.** Тәскирә апайлар боткалар пешереп шулай йөриләр иде инде. Менә монда, болында пешереп, кешеләргә сулар сибеп. Мин бала вакытта да шул. Ярмалар, кем нәрсә бирә инде, төрле ярмалар, шулардан ботка пешереп:

Арпадан, бодайдан,
Яңгыр телим Ходайдан, –

дип Ходайдан сорыйсың.

Әйберне җыйган вакытта да. Сабан туенда әйбер җыялар бит инде. Шуның шикелле бала-чагалар йөридерие. Капка төбендәге көлләгән-кортлаган су да калмый торган иде кешегә сибеп. Урманнан утын апкайтып барган шоферларга, бөтенесенә, туктаталар да, алдалап, су сибәләр. Кайсысы сүгә, кайсысы куанып көлә инде. Электән килгән йола бит инде ул. Йоланың начарлыгы юк бит инде ул.

Бик булмаган вакытта *(яңгыр)* булган корбан чалулар да.

* * *

Әүвәлге әбиләр: мөселман өендә 7 фил булырга тиеш, дигәннәр. Фил изге хайван бит инде, гарәп хайваны.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Гарифҗанова Флюра Галимҗан*
*кызыннан (1942 елгы) язып алынды*

Бер җирдә йокласаң, я дивана буласың, я авышып, я җүләргә әйләнәсең. Менә шундый җирләр дә бик күп. Менә шуның өчен басуда белмәгән җирдә йокларга ярамый.

Менә урман кырыенда гына тегермән, пиларамнар бар ие, күмер заводы. Шунда посадка утыртырга килгәч, сәрдәләр бер җирдә йоклаганнар, тегермән суы кырыенда гына. Бер хатын-кыз әзрәк кырыйгарак барып йоклаган. Әнә шуннан авышкан төсле торып, бальнисларда ятып, нитеп, үлеп китте. Чама белә 5 ме 10 мы метр читтәрәк йоклаган булган. Менә нәрсәдән икәнне белми, бальниста ятып-ятып үлде.

Ни дә булса дөрес урын түгел инде.

*Арча районы Байкал авылында*
*Галәветдинов Бәһаветдин Галәветдин*
*улыннан (1930 елгы) язып алынды*

Сабантуйлар буладырые. Бик әйбәт була Сабантуе. Кечкенә авылларда җук инде ничә җылдан бирле.

* * *

### ***Чүрмәнчек***

Менә чиләк белән су алып чыгалар да сиңа да сибәләр, миңа да сибәләр.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Петрова Анна Васильевнадан*
*(1928 елгы) язып алынды*

### ***Җыен***

Шекә җыены көнне тудым. Ул вакытта җыен ие. Сабантуй түгел ие, мин туганда.

Элек менә болай булды ул: сабанга чыгар алдыннан Сабантуе ясадылар. Ул вакытта аяк аслары әле чат кибеп бетмәгән дә була. Коры тау башларында ясый торганнар ие. Сабантуена балалар иртүк торып йомырка җыя торганнарые. Ул вакытта аяк аслары әле иртә белән катырган да була, көндез җебетә. Менә шундый вакытлар ие ул. Әле кар да эреп бетми чат итеп.

Мин күкәйләр җыеп йөрдем әле вчетки (все-таки. – *И.Я.*) 1–2 ел булса да. Аннан бетте ул. Аннан соң инде җәй көне печәннәргә төшәр алдыннан шушы июнь аенда җыен ясыйлар ие. Ул вакытта җыен. Ашыт җыены, Шекә җыены шул авыллар буенча җыен, бөтен авыл да бертөрле түгел бит.

Кунакка йөрешә торганыек, ә көннәре аерым иде ул җыенның. Ул җыенда яшьләр су буйларында уеннар уйнап, шулай иттереп үткәрә торганнар ие.

Сабантуе кар бетәр-бетмәс сукага-чәчүгә чыгар алдыннан була иде. Чәчүгә чыкканчы була ул сабантуй. Хәзер алышты бит.

Җыен бетте, ул җыен урынына сабантуй калды. Менә без икесен дә күрдек әле аның. Сабантуен да күрдек, җыенын да күрдек.

Бүләкне сабантуйга җыялар иде. Җыенда бүләк дигән нәрсә юк инде анда. Кунаклар чакырып, кунак булышып йөрдек.

Сабан туенда яшьләрнең уенын карарга олылар да төшә. Шундый күңелле итеп үткәрә торганнарие аны. Ул 1, 2, 3 көн була торганые. Төрле авылда төрлечә. Кунакка йөрерлек иттереп эшләгәннәр ие.

Авылларның үз җыены булган. Менә шундый ул җыен дигәне.

Без әле ул вакытта укырга да кермәгән малай. Малай чакта олыларга ияреп йөргән инде без.

### ***Карга/яңгыр боткасы***

Карга боткалары барые.

Аларны шул яңгырлар яумаганда, су буйларында пешереп, шулай иттереп җыйналып пешерә торганнар ие.

Халыктан җыясың әйберсен: ярмасын, маен, сөтен дигәндәй инде ул карга боткасына.

### *Яңгыр теләү*

Яңгыр, яу, яу
Тәмле ботка –
Казанда
Тәти кашык –
Базарда, –

дип җырлап җөриләр ие.

Сибешәләр ие. Бик каты сибешү.

Шул ботканы пешергәндә киткән дә инде ул су сибешү. Авыл тулып, кайсы урамга барсаң да суга коендыралар инде. Үзең дә сипкән булып йөрисең, без малайлар кечкенә чиләкләр белән. Әле ул соңгы вакытларга хәтле булды су сибешү. Берничә ел элек кенә бетте әле ул.

* * *

Чәчүгә чыккач йомырка ыргыту бар: Мул булсын, уңыш булсын! дип, хәзер юк инде ул, юк.

Җиргә ватмыйча ыргытып җибәрә иде. Пешкәндер ул, пешмәгән йомырка ватылып та китә ул, быялып бетә, пешкән йомырка булгандыр.

### *Курку куу*

Курккан балаларны таң сулары алып коендыралар ие. Таң атканчы чишмәдән су алып куя да, шул су белә баланы коендырганнар инде, курккан балаларны. Менә шунсын беләм. Калганын белмим, карчыклар, әниләр инде ул. Гыйлемне карчыклар коендырып йөрде инде, андый карчыклар бар ие, хәзер алар да юк мына, бетте бит, бар да бетте.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримов Хәбир Кәрим улыннан*
*(1925 елгы) язып алынды*

Чуаннар чыкса, кутырлар чыкса мин үзем дә имлим.

Бисмилланы әйтәсең дә, «бер берлексез булсын, ике-өч – очып китсен, дүрт-биш – бизеп китсен, алты-җиде – җиде

юлның чатына китсен, сигез-тугыз – тугыз юлның туфрагы булсын. Әфсен-төпсен, бетсен, китсен. Име-томы шул булсын. Минем имләгәнем килешсен. Минем кулым түгел – батман кулы, минем сүзем түгел – ишан сүзе», дип менә шулай итеп өшкерәм. Бөтенесе килешә.

Бер йорт өй аша күршеләр бар. Нигезеннәнме, һаман чуан чыга. Әле кечкенә 1 яшьлек балаларына да чыкты. Менә мин укып, имләп чыгарам. Чуан чыкса, кутыр чыкса, күзгә арпа чыкса. Аңгар инде кечкенә булса да, элек 15 тиен акча бирәләр ие, гүр сәдакасен бирергә кирәк имләгән кешегә.

* * *

Зәхмәт кагылса, имләп, әйбер ташлыйлар. Әйберне имлиләр дә җиде юл чатына ташлыйлар. Аңар үзең буе җеп, бер бөртек ашлык алалар, бер бөртек тоз алалар – җидегә тутырып имләп ташлыйлар. Җиде әйбер булырга тиеш.

Минем сеңнем җыгылган чатта. Шуннан күрше авылда багучы бар иде. Шул Н.гә бардым:

– Минем сеңлем шундый хәлдә, – дим.

– Бу, – ди, – чатта җыгылган ич, зәхмәт кагылган. Чатыгыз сезнең зәхмәтле бит, – ди, – җыгылырга ярамый, – ди.

Чыннан да шундый чат инде ул. Кайттым. 7 төрле әйбер җыйдым да имнәп ташладым. Ташлаганда бер сүз дә әйтмисең, кул артың белән атасың да бер борылып та карамыйча, өеңә хәтле бер кешегә эндәшмичә кайтасың. Күңелеңнән уйлыйсың инде:

– Шушыны аша, шушыны эч – дисең инде. Икенче көнне кайтты теге сеңлем. Бернәрсәм дә калмады, ди.

Зәхмәт кагылу бар, дөрес ул.

* * *

Кояш баегач су коенырга ярамый, коендык инде без аны. Эштән кайтышлый суга керәдериек инде. Бисмилланы әйтеп керәсең инде.

Бисмилла бик зур сүз ул.

Кояш баегач чишмәдән, коедан су алырга ярамаган. Миңа сорап керәләр икән, мин апчыктырырга тиеш түгел. Ярамаган эшләр шулар.

Тәрәзәдән тәрәзәнең эченә кереп карарга ярамый, гөнаһ була. Кеше тикшерергә ярамый.

* * *

Абзарга, бөтен җиргә миләш ботагы кирәк, артыш агачы кирәк. Менә балаларга, тугач, әзрәк кеше күзенә күренә башлагач та баш киемнәренә миләш агачы тыгарга, менә мондый *(күрсәтә)* күз тимәсен өчен. Обязательно кирәк миләш агачы. Бик кечкенә генә, шуны җуынасың да баш киеменә, кайда да булса алыштыра торган киемгә миләш агачы тыгасың. Менә монда беләгенә тыксаң да ярый. Шуның янына бер ике матур төймә куясың. Күз тими. Ничек тә ярый, түлке тыгарга. Менә бу былавкины менә болай итеп күренми торган җиргә казап куясың – монсы бозым кермәсен өчен, сихер кермәсен өчен.

Миләшнең ниндие – яңгыз миләш – бер үзе генә утыра торганы. Дәүләргә дә ярый. Мине әллә ничә тапкыр күз тидереп ектылар, кыз вакытта. Өстеңә әйтеп җыга торганнар ие.

«Әлхәмделиләһи вә биләһи... галиул газыйм», дип укып 3 тапкыр өшкерәсең.

«Лә хәүлә...газыйм» дигән дога бөтен күз тиюләрдән, бөтен афәтләрдән, бөтен нәрсәдән коткара торган дога.

* * *

Сөбханалла машалла
Күз тимәсен баш ала, –

дип әйтеп тотынасы баланы караганда.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил*
*кызыннан (1930 елгы) язып алынды*

Хәтнәгә барып-барып укып кайтадырыек инде. Анда нарат-лык бар. Шуннан чишмә чыгадырые. Шуннан хөкүмәт су алып сата. Ул изгеләр чишмәсе инде.

* * *

Йөзне үткәч – сабый балага әйләнәсең, гөнаһың бетә, синнән сорау алу юк, диләр инде. Теге якка чыккач, сабый буласың. Яңа теш чыга.

*Арча районы Мәмсә авылында*
*Касыймова Гарифә Гыйләҗетдин*
*кызыннан (1918 елгы) язып алынды*

## Риваятьләр-легендалар, сөйләкләр

Починок-Поник шуннан чыккандыр дип беләм, әткәй буенча гына. Менә кирәмәт дигән җиребез бар – наратлык. Әткәй шулай дип әйтер ие. Менә шунда Починок-Поник утынлык дигән сүз ди ул.

Бар ул урын – кирәмәт. Балалар анда җиләк ашарга йөри.

*Арча районы Пүчинкә-Поник авылында*
*Исхакова Мәдинә Ибраһим кызыннан*
*(1928 елгы) язып алынды*

* * *

Түбән Оры байларына кол булып яшәгәннәр шушы авыл. Шуңа монысы Иске Коллар дип аталган, тегендә Яңа Коллар бар ие тагы. Ансы Зирекле булды. Мәчетләр бар. Монда каршыда гына иде мәчет. Өчәү иде ул – 3 мәчет бар иде. Авыл зур, тау менгәч, Гүзәлияләр каршында мәчет ие. Аннан теге якта мәчет ие.

Совет власте урнашты. Мәчет манараларын кисеп. Ор белән ике арада яр бар. Әнә шуннан биргәннәр аны Кызылъяр дип.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Шакирова Кәүсәрия Габдуллаҗан*
*кызыннан (1927 елгы) язып алынды*

* * *

17 нче гасыр ахырларында нигез салына. Авылны елга ярына салырга уйлаганнар. Елганы борынгы бабаларыбыз Сөләнгер дип йөрткәннәр. Аның уң һәм сул ярларына өйләр салына башлаган. Ерак ягындагы өйләрне – Кечкенә Эш, ярның икенче

ягындагы өйләрне – Сөләнгәр дип атаганнар. Тора-бара йортлар күбәйгән. Иске Коллар дип кенә йөртә башлаганнар. Авыл халкының бер ишесе ярлы булган, хәерче яшәгән. Бер ишесе бай яшәгән. Ярлылар аларга ялланып эшләгән. Авылның Иске коллар исеме шуннан килеп чыккан дип саный авыл өлкәннәре. 5 урам, 3 мәчет-мәхәллә, 1935 елда авыл исемен Кызылъяр дип үзгәртәләр.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Шәрипова Гөлсия Фердинанд кызыннан*
*(1985 елгы) язып алынды*

### ***Кызылъяр***

Ә авыл элек Кызылъяр булмаган ул. Коллар булган. Мин бала вакытта әниләр әйткәнен хәтерлим әле:

– Аллага шөкер, без дә коллар түгел инде, Кызылъяр булдык без, дип куанышып җыелыштан кайттылар. Мин бәләкәй инде ул вакытта, сугыштан соң әле. Аңарчы гел Коллар булып җөргән ул.

Шуннан хәзер теге бай кызлары агып киткәннәр, өе белән бергә, су бирмәгәннәре. Бу турыда Шиһабетдин Мәрҗәни дә язган. Шул китапка. Өзекләп-өзекләп язып калдырган. Шул булгач алдым инде ул китапны. Битвәнуры дип язылган.

Аннан соң безнең әбиләр, әниләр эшкә барышлый әңгәмә куертып утыралар ич инде. Мин шунда гел тыңларга ярата торган идем. Әнигә ияреп бара торган идем. Хозур Ильяс дип әйтәләр андый кешене, Хозур Ильяс.

Безнең буын ышанмый ич инде. Уйлап чыгарылган дип уйлый. Уйлап чыгарылмаган ул. Менә шулай итеп Хозур Ильяс юлдаш булсын дип миңа әни дога өйрәтте:

Сөбханалла, сердәшем,
Хөзер Ильяс юлдашым
Әнтә хәйрел мөслимин, –

дип әйтегез, дип. Ие, мин шул доганы укымыйча чыкмыйм. Ул доганы укырга бик кирәк, һәркемгә дә.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Гарифҗанова Флюра Галимҗан*
*кызыннан (1942 елгы) язып алынды*

### *Байкал*

Бу Байкалга хәтле 3–4 исем булды икән инде ул. Иң элек Малый Петербург, икенчесе По речке Лумбы – Ломба елгачыгы авылы. Аннан 3нче исеме Яңа Тазлар (Иске Тазлар дигәне – Акчишмә, Әтнә районына керә).

Лумбы исеме инде, ул исем – мари исеме. Аннан әле Байкалы 1937 елда 40 кеше (39 дип тә ишеткәнем бар) монда урман кырыена яңа йорт салып чыкканнар. Менә шуннан авыл баеган дип Байкал шуннан калган сүз.

Моның тарихы 2 охотник мари карап йөргәннәрме, монда килеп чыкканнар да урман да бар, су да бар. Шуннан Казанга барып, авыл саен әйтеп йөргәннәр «менә шундый әйбәт урын бар, теләсәгез күчеп килегез» дип. Менә шуннан соң Казансуы буенндагы бер 10–15 авылдан кеше килгән. Монда җыен байлары килгән, хәерче килалмый. Тормышны корасы бар ич. Ат заманы.

Менә безнең авыл ана шул Иске Тазлардан. Бездән Хисами бабай дигәне монда 12 яшьлек булып килгән шул Иске Тазлардан. Аны әби бик күп сөйләде. Ул сату итеп йөргән ат белән. Кытайга хәтле барган ул 2–3 мәртәбә. Аргамак дигән аты булган әллә нинди бер аерым. Сату итеп йөргән авыл саен. Җәй көне квартирга кермәгән, кайда су булса шунда кунган, арбасында юньләре булган: түгәрәк самавыры, шуны тәртә башына куеп йөрткән. Минем хатын сдавать итте шуны акча җитмәгәч, әнә теге төп нигездәге Казан шикелле нәрсә. Шунда первые, второй дип ашарга пешергән. Тәртә башында самавыры кайнап барган. Аның күмере булган. Җәй көне квартирга кермәгән. Атны туарып җибәргән дә инде...

Туксан өч яшендә үлгән ул. 75 яшенә кадәр шулай итеп йөргән. Кытайга хәтле барганында (әби шуның килене булган, минем әтинең әнисе) 6 ай вакыт узган. Аннан башка чыккан. Аларның әле тегендә калган туганын бу Советлар Союзы вакытында сөргенгә куганнар. Болар монда китеп калган инде. Шуны бер кеше әйтте миңа. Әле шуларның балаларының балалары Троицкида бар дип. Шул безнең нәселнеке була инде.

Безнең авыл 1659 елны Казанга учетка кергән. Ике тимерче ачыгы, 4 тегермән булган, 2 су, 2 җил тегермәне. Мин белгәндә

җил тегермәннәрен бетергәннәр ие. Бик каты бай авыл булган ул. Бай булмаса 40 хуҗалык берҗулы салып чыкмый.

40 хуҗалык булгач, җанган авыл. Бер байда ут чыгып, җанып беткән дә бөтенесе. Шуннан хәллерәкләре киткәннәр моннан. Бик хәлсезләре калган да, шуннан соң тагын үскән. Чама белә 200 хуҗалык булган. Әле мин белгәндә 187 хуҗалык ие, сугыш башланганнан хәтердә.

*Арча районы Байкал авылында*
*Галәветдинов Баһаветдин Галәветдин*
*улыннан (1930 елгы) язып алынды*

Бу – патша заманында, моннан 100–150 ел элек.

Бу урманны чыккач Оры дигән авыл бар – Югары Оры, тегендәгесе Байлар Оры (элек шулай дип йөрделәр, хәзер Түбән Оры). Анда ситца фабрикалары булган, байлар яшәгән. Түбән Орыны Мәскәүдә дә белгәннәр, Кытайда да белгәннәр.

Безнең авылдан бер карак кеше сыерны чабата кидертеп урлап алып киткән. 4 аягына да чабата киерткән.

Абзарга керә, сыер юк. Кая киткән, сыер аягы эзе юк, кем алган, авылда эзләп карыйлар, җук. Чабата эзе генә бар. Орыга (Югары) алып киткән чабата киертеп. Алып кайткан да, авыл халкы да белмәсен өчен, бүлмәгә апкереп җабып куйган, ашарына куйган, чтобы кычкырмасын. Шул кешене тере килеш күмделәр. Шуннан соң халык әйткән инде (тирә юньдәге кешеләр авыллар, урлый ул кругом.): әгәр дә бу кешене үтермәсәгез авылыгызны җандырып бетерәбез, күрше авыллар шулай дигән. Югары Орылар тере килеш күмергә мәҗбүр булдылар. Малайны калдырыгыз, дигән, малаен-ниен күмгәннәр, ир малайны, хатынына тимәгәннәр. Таза кеше булган ул. Икесен бергә күмгәннәр. Каберне селкетте ди, балчыкны, һаман, ыргыталар балчыкны, чөеп ташлый, таза кеше, дәү. Халык күп монда, көрәк белә ыргыта. Шулай итеп күмгәннәр этиләр заманында.

### *Шура*

Элек мари халкы яшәгән. Менә мондый хәл. Безнең авыл монда хәзер, шунсына бер ярты чакрым киткәч Янсар дигән авыл булган. Охотник марилар торган монда. 5–6 йорт. Анда

чишмә дә бар, җылга да бар. Шунда яшәгәннәр. Бервакыт татарлар тегеннән килә башлаган, чукындыру башлангач, Волганың теге ягыннан. Мин авыл 3 исемдә булган дип әйттем. Криминский, Ташинюрский, Шуринский (Шура). Шуралар күпчелек килгән дә, әйдә Шура исемен кушабыз, дигәннәр. Шура дигән авыл Волганың теге ягында бар, бер 30 йортлы гына. Безнең авыллар булган анда.

Ташинюр – Ташлы басу (нюр – ачык җир). Авылны алай дип тә кушканнар. Юк, Шуралар күп килде. Шуннан соң – Шура. Бетте. Әле минем тууым турындагы язуларда Ташинюр ие.

Криминский – марилар яшәгән вакытта, шулай аталган.

Шура – Совет дигән сүз. Җыелышны да Шура дип атаганнар.

### *Янсар буе*

Янсарны сөйлим. Тегеннән кешеләр килә. Түбән Оры урманны биләп алган байлар, анда кереп урнаша алмыйсың кара балчыклы булса да. Безнең авыл тегеннән үк, комлы җирдән үк килгән. Олы юл дигән юл бар. Казаннан чыкканда ул Әтнәгә килә, аннан соң Бәрәңге дигән авыл, шунда бара, Түбән Оры аркылы уза. Олы юлдан килеп бер җиргә урнашып караганнар комлы, монда 20–30 йорт түгел инде, ат белә килгән берничә семья авыл оештырырга. Олы юл буе – талыйлар, караклар бар, юлбасарлар күп. Шуннан күчеп Бжа дигән җиргә килгән. Менә монда элек марилар яшәгән, шуның белә аңлатып була. Бжа – мари сүзе, Бжа елгасы бар. Без әле дә бжа дип йөрибез. Аннан Коткожа – елга. Марилар яшәгән, аларны куганнар.

Янсар буендагы мариларны: безнең басуда ашлык булмый, китегез, динсез халыклар сез, әнә Шурабашка китегез, дигәннәр. Шурабашта марилар бар. Бөтенесе күчеп беткәннәр, бер әби белән бабай калган, алар күчә алмый, карт беткән минем шикелле. Әбине җитәклә дә кит Шурабашка дип кыйный башлаганнар бабайны. Бабай үзенә кәҗә асраган, кечкенә генә чүмәләсе бар, печән – богау дип атыйк инде. Шуның өстенә менгән кыйнауга чыдый алмыйча мари бабай. Шуннан тотканнар да ут төрткәннәр печәнгә. Бабай шунда янган. Шуңа күрә Янсар буе – яндырылган урын дип атала. Әби үзе генә калган. Анда күммәгәннәр әбине.

Шурабашка апкиткәннәрдер инде. Татарлар мариларны бик каты җәберләгән. Бик каты куганнар. Авылларына ут төртеп вич.

*Арча районы Шура авылында*
*Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль*
*улыннан (1923 елгы) язып алынды*

### ***Яхъя хәзрәт***

Монда зиратта бер каберлек тә бар. Аны инде китапларда язалар, 1758 елгы булган. 1838 дә үлгән 80 яшендә. Бу Әтнә ягыннан килгән. Имам булып монда эшләгән. Әйтәләр, күз дә буалган дигән фикер дә бар. Изгеләр рәтенә керткәннәр. Инде аны әйтәләр, хаҗга барып кайткан дип, очып кынамы, ничекме анда.

Пәриләр дигән сүздән, Шекә бит элек урман эчендә булган. Халык, әлбәттә, яхшы тырышып эшләгәндер инде эшләвен дә, менә шушы кеше килгәч, кешеләрне ышандыра алган, миңа пәриләр булыша дип һәм, чыннан да, моңа ышаналар, без әле дә ышанабыз, булгандыр дигән фикер бар. Ул пәрине начар формада әйтмиләр инде. Яхшы булган болар, кешелекле булган дип әйтик инде һәм инде бу кеше бик гадел булган. Ахырдан хәтта пәриләрне тапшырырга уйлагач та аны кайберсе Тазлар мулласына, кайберсе кая тапшырырга дип әйтәләр. Шул кеше хәтта Тазлар мулласымы кайсыдыр әйткән:

– Мин, булмый, алмыйм пәриләрне, чөнки мин бу дөнья имамы, син теге дөньяныкы.

Пәриләр килеп әйтә торган булганнар:

– Давай, безгә эш куш, – дип.

Шуннан бу эш куша, моментально үтиләр. Нәрсә кушса да үтиләр, бик тиз үтиләр.

Шуннан аптырагач әйтә:

– Барыгыз (иләк биргән дә), су ташыгыз.

Тегеләр иләк белән дә су ташыйлар, ди.

Шуннан, бау ишегез, ди икән, комнан. Тегеләр ишәләр, ди, комны, тотып алып килгәндә җимерелә, ди, яңадан ишәләр, ди.

Халыкның әйтүе буенча ул үлер алдыннан (аның сәбәбен дә берәү бер төслерәк әйтә, икенчесе икенче төслерәк әйтә инде) килене әйткән (теге авырга узгач), җиләк ашыйсым килә, дип.

Кыш көне булган. Бу караган да әйткән: «Әнә, төш тә аша, идән астыннан», дип.

Теге хатын төшкән, идән астында җиләкләр үсеп утыра, ди. Ашаган, менгән.

– Бер кешегә дә әйтә күрмә, дигән.

Шуннан икенче риваять бар.

Ничектер аягы, нәрсәдер бармагы икенче төрлерәк булган. Шуннан ул хатынына әйткән булган. Күрсәтмәгән беркая да имеш-тер. Шуннан соң күргән хатыны, шуннан әйткән инде бу. Җиләк турында теге әйткән дип әйтәләр инде. Шуннан соң ул әйткән:

– Булды инде, мин яшәмәм инде озак, – дип. Шуннан үләр алдыннан әйткән инде:

– Менә, мине искә алыгыз, мине искә алсагыз мин сезне онытмам.

Шуннан авылда ул үлгәннән соң кемдер искә алган, кемдер алмаган. 40 елдан соң пожар чыккан, ут чыккан. Өйләр яна, ди, ут сикереп, бу өй кала, икенчесе яна, шулай итеп авылда хәйран өйләр янган. Гомумән, авылда искә алалар инде.

Аның чардуганын тимердән ясаганнар ие. Әле мин белгәндә чардуганы агачтан ие, чардуганда даими рәвештә җепләр торадырые. Ул кеше васыять итеп әйтә дә, чардуган тотырмын, дип, чардуган булгач җеп белән тота. Шуннан агач эчергәч, тимердән куйдылар. Бу Яхья хәзрәт. Бу авылга килгән, шушы авылда яшәгән, бу авылда үлгән. Моның нәселе дәвам итә, бар. Яхья хәзрәт Әтнә районы Бәрәкчә авылыннан килгән.

Аның пәриләре булган. Ул шундый ниләр күрсәткән инде.

Берәү килгәч, атын мендереп куйганнар лапас өстенә, атлар тора, ди, лапас өстендә.

Кайбер кеше әйтә инде искеләрне бу Яхья хәзрәт өчен дә әйтәләр.

Урманда яшәгән безнең бабайлар зур гәүдәле тазалар булгандыр инде, яхшы эшләгәннәрдер. Әле дә Шекәләр эшчән, кирәк инде менә. Пәри булыша торгандыр бу Шекәләргә, диләр.

Минем әби сөйләрие. Әбинең, ялгышмасам, әбисе бар ие, ди, ул аны Яхья хәзрәтнең кызымы диеп әйтәдерие бугай. Алар белеп сөйли иде.

Мәрҗанинең китапларында да бар бугай ул Яхья хәзрәт турында.

*Арча районы Шекә авылында*
*Вилданов Рәҗәп Гыйльман улыннан*
*(1957 елгы) язып алынды*

Яхья мулла булган инде шушы авылда, ул бик зур гыйлемле мулла булган. Менә шуны пәриләр асраган дип сөйләделәр инде.

Пәриләргә иләк белә су ташыткан, дип. Менә шундый комнан бау иштергән дип. Аның карчыгы шундый авырган, ди. Шундый вакытта иренә – мулла абзыйга: кура җиләге ашыйсым килә, дип әйткән булган. Мулла абзый кисәтеп кенә идән астына төш дип ниткән карчыгына, төшсә, шул кура җиләкләре пешеп утырган имеш. Менә шундый ниләре бар.

Аннан кунакка килгән кешеләрнең атларын абзар өстенә мендереп куйган, дигән ниләре дә булды.

Ишеттек инде шул пәри дигәнен, нәрсә булгандыр инде.

Менә ул Яхья хәзрәтнең кабере үзебезнең хәзерге зыяратта. Шунда тора. Аның нигезләре юк инде.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримов Хәбир Кәрим улыннан*
*(1925 елгы) язып алынды*

Аны шул бер кешегә әйтеп калдырган инде Яхья хәзрәт:

– Минем каберне карап-саклап торсагыз, мин сезнең авылга җил-давыл тидермәм, дип үлгән инде ул. Менә караучылар бар.

Тегенди-мондый давыл чыкканы юк, Аллага шөкер.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримова Бибирәшидә Гыйниятулла*
*кызыннан (1924 елгы) язып алынды*

### ***«Шекә пәриләре»***

Безнең әбиебез Шекәдә туып үскән булган инде, 1896 елгы ие, шул сөйли иде безгә Шекә турында. Шул пәриләре безнең күңелгә иң сеңеп калганы.

Пәриләре булган дип сөйләгәннәр инде. Бөтен эшне шул пәриләргә кушып эшләткән. Аннан һаман саен эш сорап торганнар: – Нинди эш эшлибез хәзер, – дип.

Кеше эшли алмаслык эшләр эшләгән инде алар. Боларга эш җиткерә алмагач, бу комнан бау ишергә кушкан бер көнендә, бу комнан бауны да ишкәннәр икән алар. И аннан соң иләк белән су ташырга кушкан, иләк белә су да ташый алганнар.

Шуннан соң авыл кешеләре, йөкле хатыннар сөйләшкәндә моның хатыны белән, минем җиләк ашыйсы килә бик каты дип.

Шуннан ул аны бер подвалга алып кереп свежий җиләкләр ашаткан икән, идән астынамы инде, шундый җиргә.

Ул кеше безнең авылга мулла итеп җибәрелгән кеше булган. Каян икәнен төгәл белмим. Әтнә районыннан.Ташчишмәме.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримова Ләйлүфәр Әфләтүн кызыннан*
*(1955 елгы) язып алынды*

## *Кызыл Игенче*

Бу Каргалы – кушамат ич. Кызыл Игенче авылы. 1929 елны шул 6 хуҗалык килгән монда Хәсәншәехтан.

Габдрахман исемле кешенең кушаматы – карга булган, карганыкылар дип. Иң беренче шул менгән. Шуннан шул кушамат. Ә безнең паспортларда Кызыл Игенче йөрибез.

1929 елның җәй көне килгәннәр арыш чәчүенә имана җиренә. Әле үзләренең иманалары булган бит инде. Хәзер аны пай җире диләр. Менә шуңа аерым-аерым чәчкәннәр. Үз иманаларына үзләре чәчкәннәр. 1930 ел башлану белән колхоз оешкан да сабан ашлыкны чәчкәннәр колхоз булып. Уңышны урганда үзләренекен үзләре урып алган, ә сабанны колхоз итеп общий чәчкәннәр һәм урып алганнар...

Мин белгән Балтач районы Бакча авылы бар ие – ул бетте, мин белгән авыл алар бездән зуррак та иде, ул җитәкчегә караган нәрсә бит, аннан Чулпан дигән авыл бар ие, тоже Балтач районы, ул авыл бетте. Иганат дигән керәшен авыл бетте.

Бездән зуррак авыллар да бетте.

Безне дә күчерергә үгетләп карадылар, бу бетәчәк авыл монда салмагыз, дип. Рөхсәт булмаса да салдык инде без аны.

Безнең Сәлах бабай наданнарны укыткан, абыйсы Хәсәншәехтә мулла булган, безнең бабай сәвит булгач мулла булмаган, эти тере кеше булган, халык алып калган бабайны.

Бу Кызыл Игенче Балтач районы идек без. 1950 елны Хәсәншәехка кушылдык, бөтен ферма бар ие: сарык, сыер, куян, тавык. 1957 елның мартында Кенәргә китереп куштылар безнең авылны, Кызыл Юл районына. Менә шуннан соң бездә бернинди ферма калдырмадылар. Бөтенесен Шушмага ташыдылар.

*Арча районы Кызыл Игенче авылында*
*Сәлахов Вил Бари улыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

### Тәңкәтау

Менә аны төрлечә сөйлиләр. Точно гына белмим, бер бай аны тәңкә акчасын күмгән икән дип тә сөйләделәр.

Ул шушындый түгәрәк тау, кырыендагы уртада моның печән чаба торган болыны.

Анда хәзер көтү йөри. Элек шәп печән үсте инде анда. Аны кругом чорнап алган тавы да булгач, тәңкә төсле булгач, Тәңкәтау дип әйткәннәр. Бу бик борынгыдан килгән. Аның өстен әбиләр тикшермәгәннәрдер.

### Пөшәңгәр

Авыл Биектау районыннан күчкән, Сасмак дигән авылдан, шуннан Пөшәңгәрне төзегәннәр. Монда су булган бит инде, тегермән сулары бит инде, монда зур сулар ие безнең. Тегермәннәр беткәч, сулар да бетте. Безнең Федор бабай инде тегермәнче булган.

Монда бөтен җир карурман булган. Берәм-берәм килгәннәр. Аңарчы монда марилар яшәгән.

### Әкәй тавы

Монда Әкәй тавы да бар. Әкәй тавында ике мари баласы (ике кыз бала) атынчык атынганда җыгылып үлгәннәр дә, күмгәннәр боларны.

Ансын Әкәй тавы дип йөртәбез.

Монда чирмешләр яшәгән. Шуннан элеккеге кеше кем кая үлә, юлдамы, шунда үлгән җирдә күмә торган булган, дин шулай булган.

Менә бу Әкәй тау башын синаж чыгарганда казыйбыз дип, казыганда шул балаларның сөякләре, баш сөякләре чыккан.

* * *

Әни кәдимчә белә иде. Ул безгә бәетләр әйтеп күрсәтә иде. Истә юк. Әни безнең калын китап укый иде (шунда киләчәк язылган иде, хәзер килеп җитте): «Һавада корыч кошлар очып йөрер, бөтен урамнарны тимерчыбыкка чорнап бетерерләр, бөтен җирдә баганалар булыр, катын-кызлар бүрек кияр, чалбар кияр ахырызаман алдыннан», дип язган китапта... аннан соң «дин бетәр (сәвиттә), бервакыттан дин кузгалыр, ләкин дөрес булмас... Дин бетәр дигән, аннан бик зур сугыш булыр, сугыштан соң кеше әз калыр дигән, бөтен дөньяга бер патша калыр дигән (менә моның буласы бар әле), шуннан соң ахырызаман булыр дигән, ахырызаманнан да әле кеше калыр әзрәк дигән. 40 җыл гомере булыр ул калган кешенең дигән. 40 җыл гомере бик тиз үтеп китәр» дигән. Менә шул китапны без әниләр авылына күчеп тордык 1 ел сугыш вакытында... «Кешеләр иңкетиңке кая керергә тишек тапмыйча җөрерләр дигән, илләреннән илләренә күчеп җөрерләр. Бөтен халык урамда булыр» дигән. Менә бөтенесе килде дип, карап ятам телевизордан. Ничек, кем язган аны, кем белгән аны, ул заманны, ул кайчан язылган ул китап – шул китапны безнең урладылар....

## ***Пөшәңгәр авылының януы***

Монда килгәч, бер Габит бабай дигән бабай бар ие. Әби үлде дә, шушында безнең җанга менеп җөрде. Мине килен булып килгәч шушы урамда бөтен кеше җаратты. Син монда килен булып килгәч, урамга җәм керде, ди торганнар ие. Шул бабай сөйләде:

Бу Пөшәнгәр авылы бер өй дә калмыйча җанып беткән, бу бабай 5 яшь вакытта. Кенәр җыенына киттек, ди. Элек җыеннар булган бит. Эш беткәч, ашлык чәчкәч бер авылдан бер авылга

җыенга йөргән булганнар. Бөтен авыл Кенәр җыенына киткән. Шушы авылда бер әби калган. Салам түбәле кечкенә генә өе булган моның. Шушы әбидән пожар чыгып бик җилле көн булган, без кайтып керсәк, ди, мин ат арбасына утырып бардым, ди, 5 яшьлек бала, ди. Бер өй дә юк, ди. Тегермән дә янган, ди. Тегермән икенче урамда булган. Шуннан беркем дә кире китмәде, ди. Ул вакытта урам тыкрыктан ие, ди. Шуннан соң урамны менә моннан салдылар, ди, иске урынга түгел, әзрәк читенеп салганнар инде. Яңадан шушы тау башы урман ие, ди. Шуннан урман кисеп, ди, кайсы землянка сала, кайсы кечкенә генә өй сала. Өй түбәләре салам булган, салам түбәле мунчалар да. Монда кияүгә чыкканда мунча түбәләре салам ие. Хәзер мунча ягарга куркам бит инде. Мунчасының пиче дә шушындый гына, идән уртасында бернәрсәсе юк, морҗасы да юк, шунда таш өйгән дә – шунда ягасың, менә шундый кара мунчага ягасың.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан*
*(1930 елгы) язып алынды*

### ***Апаз***

Монда бер кеше килгән дә, башка авылдан, читтән. Бик әз генә кеше булган бу авылда. Шулвакытта монда килгән кеше:

– Һай, әп-әз, дигән. Әппәз монда кеше икән дип. Кешеләр әз торганнар. Йортлар да күп булмаган.

*Арча районы Апаз авылында*
*Миңнебаев Гыйниятулла Миңнебай*
*улыннан (1924 елгы) язып алынды*

### ***Мәмсә***

Элек ике авыл булган ул. Елганың бер ягы Байчурин, икенче ягы Наукшы булган. Ансы мари авылы. Аннан берләшкәннәр дә, нәрсәгәдер, Мәмсә дип атала башлаган. Ансы, ничектер, шул берләштереп, нитеп йөрүче кешесе Мәмсә исемле кеше булган дип.

*Арча районы Мәмсә авылында*
*Сибгатуллин Мохтар Габделнур*
*улыннан (1948 елгы) язып алынды*

### *Хозур галиәссәләм*

Әни туже тракторист иде минем. Ул сукалап төшә икән басудан. Шуннан бер бабай чыккан да йодрык күрсәтеп тора икән моңа. Шып туктаган. Туктаса, җар кырыена килеп җиткән булган. Хозур галиәссәләм булгандыр ул дип сөйләгәне хәтеремдә. Шунда шул бабай йодрык күрсәтмәгән булса, җардан төшеп китәсе булган. Галәмәт биек җар ул.

*Арча районы Мәмсә авылында*
*Сибгатуллин Равил Габделнур улыннан*
*(1950 елгы) язып алынды.*

### *Акчишмә*

Татбоклавыч Почингир дигән авыл булган бу, мин бәбәй вакытта, элек заманда. Революциядән соң моны күчергәннәр, Акчишмә иттереп. Монда чишмәләр күп булган. Хәзер чишмәләр почти бетте. Монда күрше урыс авылы бар ие. Бәк зур авыл иде ул. Аны Хәтнә иттеләр. Ул деревня Русский Боклавыч аталган. Хәзер бетте ул авыл.

*Арча районы Акчишмә авылында*
*Гарипов Заһир Гариф улыннан*
*(1930 елгы) язып алынды*

### *Әүлия чишмәсе*

Күрше авылда, без туганчы инде ул, Рус. Буклавычы булган. Хәзер Хәтнә ул. Менә шунда әйтәләр инде Әүлия чишмәсе дип. Әбиләр шунда барып сәдакә бирә торганнарые, укып кайта торганнарые. Хәзер анда бик шәп итеп эшләделәр. Янәшә тирәләр шунда бараларые. Монда әйтәләр инде: бер семья яшәгән дә шул семья бер көнне үлгәннәр, әүлия булганнар, шуннан калган әүлия чишмәсе. Әмәләп куйган чардуганнар да бар, шунда күмгәннәр аларны. Чишмә чыккан. Теге хәвеф-хәтәр килә бит әле, давыллар, яшеннәр, мин бу авылда шундый хәтәрне ишеткәнем, күргәнем булмады. Менә шул саклый дип баралар. Бер семья ялланып эшләгән дә, шулар бер көнне үлгәннәр. Имеш, әүлияләр булганнар, изге кешеләр булганнар.

### ***Күз суы***

Хәтнәгә барганда, хәзер авылга килеп керәбез, анда өйләр юк. Уңга борылып китәсең дә (су заводына турыга менеп китәсең таудан). Теге уң якка борылып китәсең. Анда әз генә тау сымак җир бар, шуны менеп китәсең дә анда урам сымак, анда өйләр калмады инде, урам сымак җир бар анда. Күз суы диләр. Чүт кенә җылга төшкән җиргә төшәсең дә бик зур тупыл утыра, шул тупыл төбендә, вообшем әмәнләп куйганнар инде аны, чишмә, үзенең кружкасы бар. Халык шуннан су апкитә. Күзне җуалар да, күз рәтләнә икән. Җусаң күз яхшы була. Өч җуасың инде аны. Тәлгать әйтте: «Безнең авылда бер катын сукырайган иде, – ди. – Күзне прямо савытка тыгып торды, – ди. – Бер 5 мәртәбә шулай иткәндер, – ди. Хәзер менә дигән гәҗит укый. Менә шулай итеп файдасы бар диләр.

*Арча районы Акчишмә авылында*
*Гарипов Заһир Гариф улыннан*
*(1930 елгы) язып алынды*

Әби динне иде (әтинең әнисе инде). Ул бик укымышлы әби. Менә шунда бара җомга саен. Алар анда бер 5–6 кеше җыелалар, Хәтнәгә, изге чишмәгә. Шунда бара ул әби, шунда тезелеп утырып укыйлар алар, сәдакалар бирешәләр. Әби апкайта шуннан сулар, укыган. Шуннан шул суларны әби конфорага салып куя. Шул конфора суларын безгә эчерә иде әби. Шуннан әбигә гел сәдака китерәләр ие.

Аннан безнең әби тотлыкканны ясыйдырые. Данияр нык тотлыга иде, ясады ул аны.

Җимешләр өшкерәдерие ул, зәгъфрән чәчәкләрен өшкереп шуларны бирәдерие. Үзе укый да өшкерә. Аннан соң әбигә гел нәзерләр әйтәләр булган инде.

Әби, дөньялар ничек була, ничек бетә? Менә дип әйтә иде әби: «Ахырызаман җиткәч басуларда чәчәкләр бетәр, чәчәкләр кешеләр өстенә менеп утырырлар. Аннан кешеләр кырмыскалар кебек бер җирдән бер җиргә күчеп йөрерләр. Ана улны белми», – дип әйтәдерие. Әбинең сүзе бөтенесе килде. Без чалбар кимидериек. Чәчәкләр ирләр өстенә менеп утырыр.

Әбинең исеме – Сәгадәт иде. Абыстай булып йөрде. Без әбине озатып йөрдек ашка. Якынрак җиргә барабыз – 5 тиен бирә, ераграк җиргә барабыз – 10 тиен бирә. Теге башка менәбез икән 20 тиен бирә. Энекәш белән бергә: юк инде син бармыйсың, мин барам, ераккарак. Акча эшләргә инде. 5 тиен кино ие бит ул вакытта. Менә мине озатсагыз, нитәсез, мин сезгә акча бирәм.

*Арча районы Акчишмә авылында*
*Нуруллина Тәскирә Заһир кызыннан*
*(1955 елгы) язып алынды*

## Әкиятләр

### *Кәҗә белән сарык*

Борын заман бер ир белән хатын торган.

Тормышлары шактый гына фәкырь булган.

Асраганнар бер кәҗә белә бер сарык.

Болар булган берсеннән дә берсе арык.

Бер көн шулай өйгә кергән дә карчыкка әйткән, ди:

– Боларны, үз тамакларын үзләре туйдырсыннар, чыгарып җибәрик, – дип.

Абзарларны әчеп чыгарып җибәргәннәр.

Баралар икән кәҗә белә сарык, баралар икән, баралар икән. Шуннан бераз баргач, бүреләргә очраганнар. Бүреләр чыккан каршыларына, ди. Ул бүреләр. Болар барышлый юлда бер бүре тапканнар да үзләренең капчыкларына салганнар. Бүреләр янына барып җиткәч болар, бүреләр куанганнар:

– Безгә ит булды, ашарга ризык булды, – дип.

Шуннан кәҗә әйткән ди:

– Ми-ки-ки-ки, ми-ки-ки-ки капчыктагы бүре башы бит 12. Ах уңмаган юләр сарык, надан сарык китер моннан зуррак башны хәзер табып.

Шуннан бүреләр курыкканнар, качканнар, ди. Менә шулай дип сөйли торган идек.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Шәрипҗанова Кадрия Салих*
*кызыннан (1933 елгы) язып алынды*

### ***Шомбай***

Көтүче юк, диләр хәзер авылларда. Минәйтәм, элек тә булмаган көтүче. Бай, хатыны белән, көтүче эзләргә чыккан. Бер авылга кергәннәр. Башына эшләпә кигән, өстенә чикмән кигән бер кеше капка төбендә утыра икән. Шуның җанына бай белән хатыны килгәннәр.

– Әссәләмәгаләйкем

– Нишләп йөрисез бай абзый?

– Әй, көтүче кирәк ие. Сез белмисезме?

– Ой, тукта, исемегезне сорамаганмын, ни исемле буласыз сез?

– Шомбай булам мин, – дигән теге кеше, капка төбендә утырган.

– Миңа көтүче булып бармыйсыңмы? – дигән.

– Күпме соң хакы, бай абзый?

– 15 алтын.

– Ай, аз, – дигән. – Бармыйм.

Шуннан киткәннәр. Шомбай хәзер киемен, чикмәнне салып ташлаган, эшләпәне салган да, түбәтәй киеп, бакча артыннан гына җөгереп авылның икенче капка төбенә чыгып утырган.

Тагы байлар килеп туктаган.

– Нишләп йөрисез, бай абзый?

– Әй, көтүче кирәк ие менә, хайваннарыма көтүче эзлибез. Сез бармыйсызмы, иптәш?

Бай сорый:

– Исемегез ничек?

– Шомбай исемле мин, – ди.

Шуннан өченчегә киләләр. Монсында тагы чикмәнен киеп, эшләпәсен киеп утырган. Анда да Шомбай, ди.

Берсе дә күнмиләр көтүчелеккә. Бай әйтә:

– Бу авылда бөтен кеше Шомбай исемле икән, – дип.

Арча районы Шура авылында<br>Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль улыннан<br>(1923 елгы) язып алынды.

Бер әби белән бер бабай булган. Аларның балалары булмаган. Шуннан ул бабай белән әби камыр изгәннәр дә, камыр ка-

барган да кабарган, шуннан бер малай ясаганнар шул камырдан. Шул малай кабарып, үсеп-үсеп чыгып киткән.

### *Абзый белән төлке*

Бер кеше балык тотып утыра икән. Моның җанына төлке килгән:

– Абзый, миңа да биреп тор әле кармагыңны, балык тотарга, – дигән.

Теге абзый:

– Сиңа кармак кирәкми. (Ул бәке тишеп тотып утыра икән кыш көне, суыкта.) Менә шунда коерыгыңны тык та, – дигән, – шунда балык бик күп ябыша, – дигән. – Аннан балык җабышкач, коерыгыңны тартып алырсың, – дигән.

Шуннан төлке коерыгын тыгып, теге кеше кайтып киткән балык тотып. Теге утыра-утыра икән, төне буе утырган. Шуннан теге коерык бозга каткан. Тартып алып та булмый.

– Ах, бик күп балык эләкте инде эләгүен, ничек тартып алырга моны дип уйлый икән.

Шуннан тарткан-тарткан, коерык өзелеп калган. Шуннан бу коерыксыз кайткан. Шуннан соң бөтен төлке аптыраган икән моңар:

– Коерыгың кая?

Шуннан бу кешене очраткан әле ул:

– Син, абзый, нишләттең соң әле?

Абзый:

– Син күп нәрсәләрне нишләтеп йөрисең бит әле. Менә мин дә сине шулай эшләттем. Син кешеләрнең тавыкларын, казларын ашап йөрмә, –дигән.

### *Кәҗә белән сарык*

Бер әби белән бабай урман кырыенда торалар икән. Боларның ашарына беткән. Шуннан икесенә ике капчык тоттырган да бабай:

– Бар, ашарга табып кайтыгыз, – дип чыгарып җибәргән кәҗә белән сарыкны.

Шуннан баралар, баралар, баралар икән, бара торгач бер өзелеп яткан бүре башы тапканнар да инде, капчыкка салганнар.

Тагын баралар икән, бер җирдә ут күргәннәр. 5–6 бүре тезелешеп утырып учак якканнар икән, ботка пешерәләр, ди. Боларны күргәч, бүреләр бик сөенгәннәр, инде боткабызга ит булды, дип.

Шуннан курыкмагыз, бездә ит күп, дип, теге бүре башын алып күрсәткәннәр, ди, капчыктан. Шуннан бүреләр куркышканнар хәзер бүре башы алып күрсәткәч. Ботка да калган. Без су апкиләбез, дип , бүреләр сызып беткәннәр. Шуннан кәҗә белән сарык ботканы ашаганнар, ял иткәннәр рәхәтләнеп. Калган боткаларны тутырып бабайга өйгә алып киткәннәр.

Әле кәҗә әйткән әле, кәҗә бит акыллырак:

– Эй, аңгыра сарык, китер әле моннан дәверәк бүре башын табып, – дигән теге бер башны биргәч.

– Мики-ки, мики-ки. Капчыктагы бит бүре башы уники, дигән.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан*
*(1930 елгы) язып алынды*

## Бәетләр

### ***Поши бәете*** *(өзек)*

Пөшәнгәрләр Поши суйганнар. Шуның:

Пөшәнгәрләр поши суйган
Шул пошины елатып,
Пөшәнгәрнең урамында
Йөрдем аяк чылатып, –

дигән җыруы да бар.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил*
*кызыннан (1930) язып алынды*

## Мөнәҗәтләр

Көйле иман, әнидән калган:

***Бердер илаһым бәнем***

Инандым бер Аллага,
Алланың берлегенә,
Алланың барлыгына,
Бердер илаһым бәнем.

Барлыгы үзендәдер,
Һичкәмсәдән түгелдер.
Үзлегеннән булгандыр
Бердер илаһым бәнем.

Аллаһының барлыгына
Әвәл – ахыры юк аңа,
Бетмәки дәхи юк аңа
Бердер илаһым бәнем.

Һәркемгә ризык биргән
Бердер илаһым бәнем.

Бар нәрсәне белүрсәң,
Бар нәрсәне күрерсәң,
Тавышны ишетерсәң,
Бердер илаһым бәнем.

Син һәр эшне теләгән,
Һәр теләгәнең булган,
Теләмәсәң булмаган,
Бердер илаһым бәнем.

Ул илаһым терелтер,
Аңа үлмәк һич юктыр,
Көченең чиге юктыр
Бердер илаһым бәнем.

Илаһымның белүе,
Башка эшләр кыйлуы,
Бердер илаһым бәнем.

Безнең белүемебез,
Эшләр кыйлуымыбыз,
Һич ошамас бер ине
Бердер илаһым бәнем.

Алаһым, син ялгызың,
Юктыр уртагың сәнең,
Юктыр тиңдәшең сәнең,
Бердер илаһым бәнем.

Син һич кемдән тумаган,
Үзең дә тудырмаган,
Бу эштән бик пакь булган
Бердер илаһым бәнем.

Бу дөньяның һәр эшен:
Яхшысын һәм яманын
Алдан язылыш сән барын
Бердер илаһым бәнем.

Күндердең сән тугры юл,
Белдердең сән,
Үзеңә чакырдың сән
Бердер илаһым бәнем.

*Арча районы Сеҗе авылында*
*Әхтәмова Шәмсинур Шәрәфетдин*
*кызыннан (1925 елгы) язып алынды*

### *Мөнәҗәт*

Бисмиллаһ, дип башлыйм әле
Мөнәҗәтнең башларын,
Аллаһ сүзе изге сүз икәненә ышанам.

Утырдым да уйга калдым:
Дөнья куа, чаба кеше,
Як-ягына карамый да,
Ялны белми күптер эше.

Ашыга ул, кабалана,
Әйткәнеңне ишетми дә,
Таптап китә юлда торсаң
Бәреп китә ишекне дә.

И, Аллаһым, иман индер,
Коткаручы бары синдер,
Рәхим шәфкатең инде күндер,
Туры юлга инде күндер.

И, адәмнәр, туктагыз ла,
Җан авазын тыңлагыз ла,
Күңелләргә иман бир, дип
Бер Аллаһтан сорагыз ла

Ярдәм итү нәрсә инде
Көче ташып торган иргә.
Юлың өзмә һичбер вакыт
Мөселманнар торган җиргә.

Исән чакта алып кал син
Ата-ана фатихасын.
Ирештер син аларга да
Алаһының догаларын.

Яшьлектә Хәдичәбикә әбидән отып алган идем мин аны (мөнәҗәтне).

Аңарга хәзер 82 яшь. Ул да аны кабатлап бирергә može. Ул аны үзенең әнисеннән алган.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Фазылҗанова Тәнзилә Сабир кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды*

## Уеннар, аулак өйләр

**«Тәңкә салыш»** уйныйлар ие. Утыралар да җегете-кызы кулына тәңкә салып чыга. Тәңкә салыш – йөзек салыш икесе дә бер үк. Салып чыга да «тәңкә кемдә» дип чыга. Миндә дип, аннары җәза күрсәтәләр идеме шунда.

Кайсын җырлатканнардыр, кайсын җегет белән тышка чыгарып җибәрәләр ие.

**«Наза»** уеннары уйныйлар ие. Урамда круг итеп уйныйлар ие.

Менә керәшеннәр «яфрак бәйрәме» дип бик матур җирдә кесмәс дигән_ни бар урман түгел шул, хәзер урман булгандыр инде, минем дә күргәнем юк, вак агачлар ие. Шунда җыелалар ие дә, шунда татары-керәшене бергә уйныйлар ие, янәшә-тирә авыллар да киләсе килгәне килә ие.

*Арча районы Пүчинкә-Поник авылында*
*Исхакова Мәдинә Ибраһим кызыннан*
*(1928 елгы) язып алынды*

Безнең заманда аулагый дип, этиләр-әниләр юк вакытта егетләр-кызлар җыелышып утыра торган иек инде. Кул эшләре алып киләдер иек. Ул вакытта техника юк. Бөтенесе кулдан эшләнә. Бияләй бәйләү, куфайка, гамажлар шикелле.

Җәй көне клублар ачылмый торган ие безнең заманда. Елгаларда тигез матуррак уранnarга елга буйларына уйнарга чыга торганиек. Сәйфулла елгасы, Абдулла елгасы. Яшьләр җыела иде.

Сугыш башланды без 15 яшькә җиткәндә. Аннан соң бик уйнап йөрергә туры килмәде инде безгә. Күбрәк эш булды да эш булды.

**«Тәңкә салышлы»** бар ие. «Тәңкә кемдә, йөгереп чык» дип әйткәндә тиз-тиз генә чыгып ычкынып китә алса, ул кеше үзе тәңкә сала, теге кеше аның урынына утыра. Чыгып китә алмаса, аңа җәза бирәләр иде, я биергә, я җырларга шунда.

Берәү уртада утыра. Аңа җырлыйлар (түгәрәк уен):

Урталарга утыргансың
Урындыкта бер үзең.
Матур үзең, үтә сүзең
Авылларда бер үзең.

Арча яклары матур як,
Иркәм арча ягында.
Башларымны түбән иям
Бик сагынган чагымда.

Сания апа суга бара
Алсу-алсу чиләге,
Чиләгенә караганда,
Үзе кура җиләге.

Армияга китеп бетте егетләр. Без «Наза» уйнаганда кулларны тотып шып торасың инде. Берәү башта тора. Бер җыр җырлагач, шул кеше үзенә ошаган бер кешене алып чыгып китә.

**«Сакта»** уены. Берәү монда биеп тора инде. Тегесе биеп килеп тегенең парын алып китә. Аны «барыня» көенә бииләр иде.

*Арча районы Сежҗе авылында*
*Әхтәмова Шәмсинур Шәрәфетдин*
*кызыннан (1925 елгы) язып алынды*

Без дә уйный идек **«Наза»**ны. Су буенда уйный идек.
Шул «Наза» рәвешендә басып:

Бас, әйдә, станокка,
Ыстаннары ыстанда.
Синең өчен генә яшим
Безнең Татарстанда.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Асыя,
Синең кебек мактанчыклар
Шырпы кабына сыя.

Итәкне сырлатканчы,
Үзем җырлап чыгыйм әле
Дусларны җырлатканчы.
О, ли, машина, дип.

*Арча районы Сежҗе авылында*
*Әхәтова Миләүшә Фирдәвес кызыннан*
*(1969 елгы) язып алынды*

**«Тыкрык»** уены.
Тезелеп басалар да. Берәү бии, берәүне алып чыгып китә:

Бас әле станокка,
Станнары станда.
Синең өчен генә яшим
Шушы Татарстанда, –

дип җырлаганнарын беләм.

Бие әле, бие әле
Биюләрең американский икән.
Сикереп-сикереп биюләрең
Саесканский икән.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Шәрипҗанова Кадрия Салих кызыннан*
*(1933 елгы) язып алынды*

### *«Шар» уены*

Авылда элек «Шар уены» уйнадык без.

Кала шар, чокыр шар, тала шар.

Алар тамырдан ясалган, ул чагында туплар юк. Шушының йозрык хәтле тамыр. Бездә урман бит монда. Шул шарны берәү тегеннән ата да монда ике якка тезелгәннәр, хоккей шикелле инде. Кәкмәшә белән сугыптырып еббәрә. Кәкмәшә – кәкре таяк, урманнан малайлар һәрберсе ясыйсыйң үзең.

Ә уенда ике партия. Берсе бу якка таба куа шарны, икенче партия, кара каршы торалар бит инде, тезелгән, бу якка.

Көз көне уйнала. Әбиләр: «малайлар, тәрәзәне ватасыз», дип сүгә әле безне. Китегез моннан. Икенче ердә уйнагыз, дип.

### «Таштеки» уены

Аннан яз көне «Таштеки» уйныйбыз. Әзрәк кардан әрчелә башлый тау башлары. «Таштеки» уены уйныйбыз инде.

Ватык тәлинкәләрне, чынаяк ватыкларын. Һәрбер малайның өендә бар, бетми, апкилә. Шуннан үзенекен тезеп куя. Шуннан яңа такта ебәрәсең болай иттереп бер 10 метрдан (10 адымнан). Теге ничәне бәреп чыктың. Монда иптәшләрнеке дә тезелгән, синеке, ох җыеп алдың, Таштеки күбәя. Такта ебәрәбез. Менә

мондый шакмаклы такта белән тегендә тиергә кирәк. Ул такта 20 гә 20 (20×20 см).

Аны әле күп җыйган малайны мыскыл итәләр, маен чыгарырсың, дип.

Тезеп-тезеп китәбез.

Пока 3 малай уйныйбыз. 3 малай да таштекиләрне тезәләр. «Атырга чират ничек?» «Давай тотышабыз!» Бер таяктан тотышканда кем алга чыга. Әүвәлге заманда «тотышу» дигән нәрсә бар. Берәр әйберне бүлгәндә дә «тотышу». Беренче чыгасың икән – син беренче ала башлыйсың (уйный башлыйсың. – *И.Я.*).

Мин отып бетерсәм, калганнар уеннан чыга, төште. Ул катнаша алмый. Бер 10 метр җирдән ыргытасың инде. Әле тактаны тидерә алсаң ярый. Берәүнеке уза да китә тагы.

### *«Күкәй «уены*

«Күкәй» уены «Таштеки» кебек. Әти әйтте, элегрәк болай уйнаганнар. Түбән очка төшеп бер кешенең болынында уйный торганыйк, ди. Например, өйдә 5 тавык йомыркасы пешереп бирә әни. [Ул чагында андый кош-кортны күп асрыйлар. Ул хәзер генә юк ул. Урам тулы тавык, үрдәк, каз болын буе, су буе тамаша.] Шуннан болай итә торганыек, ди (әтисе. – *И.Я.*): Менә шушындый (күрсәтә үзенең түбәтәен. – *И.Я.*) ике түбәтәйгә чүпрәк тутыралар да, туп булмау аркасында, инде түбәтәйнең эченә чүпрәкләр тутыралар да, бәйлиләр. Күкәйләрне бастырып мин 5 не куям. Тезеп киттем. Мин уенда катнаша алам. Күкәем бар бит, аптөштем, әни бирде.

Шуннан соң тагы кем малайныкы бар. Өчебезнеке бар. Әйдә уйнарга. Вот күкәйне 3 не дә бишәрне тездек, ди, әлеге шул «Таштеки» формасында. Шуннан нишлисең. Пешкән күкәй ул. Ватылмый. Түбәтәйдән эшләнгән тупны тәгәрәтеп еббәрәбез – күкәйгә тисә – синеке. Аннан икенче иптәшкә бирәсең. Син оттың инде. Әле откач, син уеннан чыкмыйсың. Тидермичә, тубың читтән генә тәгәрәп китсә – уеннан чыгасың – пока син атламыйсың, икенче малай ташлый, шулай итеп әти, күкәй уены уйный торганаек, диде. Андый уен да булган ул чагында.

### *«Чокыр шар» уены*

Уртада табак кадәр, моның кадәр чокыр казыла. Шуннан җак-җакка малайлар тезелеп, һәрберсе тоже чокыр казыган моның хәтле генә (кечкенә. – *И.Я.*). Кәкмәшә бөтенесе кулында, теге кәкре кәкмәшә. Кәкмәшә белә чокырына тыгып тора, әзер, үзләренең. Түгәрәкләнеп малайлар. Уртада зур чокыр табак хәтле. Хәзер берәү көтүче. Аның шары бар. Ул малайларның арасыннан уздырып шарны төшерергә уйлый, тамыр шарны. Менә шунда төшерсә, теге малай көтүчелектән котыла, хәзер икенче малай тотына.

Уртага кертмәскә тезелгән малайлар суга да ебәрә, бу малайлар керттерми. Менә шулардан уздырып монда (уртага) кертергә кирәк. Аннары көтүчелектән котыласың. Шар йөртүче көтүче дип атала. Син уздырдың тегенең тәгәрәткән шарын – хәзер көтүчелек сиңа. Чокыр белән малайлар арасы кәкмәшә буе түгәрәк сызык бар. Монда эчкә кердеме әле, чокырга төшмәгән икән, сугып еббәрәләр көтүчегә. Монда малайлар күп. Әле бу яктан да кертеп карый, әле теге яктан да. 8 кеше уйный, 1 се көтүче. Ул шарны керткәннән соң, хәзер кем арасыннан кереп киткән, кем тоташмаган – көтүче шул була. (Һәрбер малай янында кечкенә генә чокыр, шуның эченә малайлар кәкмәшәләрен тыгып тора. Көтүче шарны бәреп кертергә тиеш зур чокырга.)

### *Уен*

Төрле фигуралар ясый, например, тезеп китә шакмакны бастырып. Шуннан соң квадрат ясый, пушка ясый. Болай итеп дүртне куя да уртасына тагын берне куеп пушка ясый. Монда тәпәч ыргытып инде, чтобы тезеп куйганнармы. Иң беренче җырактан атасың икән – бәреп җыктың мондый тезгән фигураларны, аркылыга тезәләр. Шуннан хәзер ярты юлга килеп атасың инде берне җыкканнан соң. Тегеләрне бөтенесен түнтәреп бетерсәң, ват, син җиңдең. Хәзер икенче малай тотына инде.

* * *

Аулагыйлар. Менә безгә кадәр бик каты аулагыйлар гөрләде инде ул. Безнең заманга килеп җиткәч, кая аулак

өйгә йөрер идең, хәзер башланды сугыш. 18 дә, җегет булып җиткәч кенә.

Аулак өй ул әти-әни кунакка китсә, өйдә кыз булса, авылдагы кызларны чакыра:

Әтиләр 2 көнгә кунакка киттеләр. 2 көнсез кайтмый элек. Шуннан иптәш кызларны җыя. Кызлар җыйналгач, моны белеп ала җегетләр, менә шунда җыйналалар. Авылда гармунчы булса, гармун тотып килә. Шулай итеп җырларга өйрәнгән инде алар кәнишне, биергә өйрәнгәннәр алар шунда халык, яшьләр. Клуб юк ич ул чагында. Әз генә күңел ачасы килә яшь кешенең. Анда кара-каршы җырлашу да бар. Җегетләрне җаманлап:

Ат туарып җигә белми,
Кызлар сайлаган була.

Ат җигә белү үзе җегетлек санала. Әле аулагыйга килгән җегетләрнең өсте-башы начар булса, аны тәнкытьләп кызлар җырлап еббәрә тагын:

Абыеңның бәз бишмәтен
Киеп монда килдеңме?

Үзенеке юк инде теге малайның. Биләмгә чыгасы килә, абыйсыныкын булса да киеп чыккан.

*Арча районы Шура авылында*
*Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль*
*улыннан (1923 елгы) язып алынды*

Элек гөслә белә кич утыру күп булган, аулак өйләрдә. Безнең әнине йөрткәннәр аулак өйгә шул гөслә уйный белгәч.

«Түгәрәк уены», Сигезле биюләр, җырлап уйный идек. Өчле биюләр, парлы биюләр.

* * *

Качышлы кич уйныйдырыек. Күзләрне бәйләп.

* * *

Кыш көне ындыр табагыннан чаналарны урлап тау шуарга китә идек.

### *«Туп» уены*

Чүпрәктән туплар тегеп, түбәдә туп уйный торганыек. Башта берне җибәрәсең, аннан ике белән, аннан өч белән .... Бер төшергәнче уйныйсың, җитешеп барырга кирәк, 1 туптан башлап, 5 тупка кадәр җиткереп уйный идек. Чиратлап туйганчы, арыганчы уйныйсың. Аннары икенче кеше ала.

Хәзер кызык түгел. Уен белмиләр балалар.

### *«Тыкрык» уены*

Җиргә сызып шакмак-шакмак итеп сикереп-сикереп тәтәй атып уйный торганыек, пыяла ватыкларын, тәлинкәләрнең кисәкләрен атып. Шул тәтәй. 9 шакмак – берсе парсыз. Аннары парлы, аннан берәү, аннан тагы парлы.

Сызыгына эләксә, чыгасың, икенче кеше уйный.

### «Шакмак» уены

Парлы шакмаклар сызасың. Сикереп барасың инде. Ул «шакмак» уены ди торганыек.

* * *

Уенга тезелеп басабыз. Каждый кешегә җыры бар ие. Җырлый торганыек. Исеме дә килә торган ие, йөзе дә, җөргән җегетләре, кызларына, ну, хәзер белмим берсен дә.

Парлап басалар. Анда җырлыйсың да, биеп чыгып китәсең.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Архипова Вера Васильевнадан*
*(1953 елгы) язып алынды*

Аулагыйлар буладырые. Җыелып кызлар, җырлашып утыра торганыек, гөсләләр уйнап, ул вакытта әйбәт ие безнең замана.

Җырла-җырла дип әйтәсез,
Сезгә нинди җыр кирәк?
Сезнең алда җыр җырларга
Сандугач теле кирәк.

Чыбык сала идек. Шул чыбык чыкса, җә этәч булып кычкырталар. Түгәрәкләр уйный торганыек, җырлашып.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Петрова Анна Васильевнадан*
*(1928 елгы) язып алынды*

Кыш көннәрендә, укыган вакытта инде ул чана, коньки урамда инде. Боз өсләре юк.

### *«Кузый» уены*

Без урамда кыш көнендә «кузый» ди торгаек. Хайванның тез башларында сөякләр була бит әле, менә мондый-мондый. Менә шушы җөри торган җулга тезеп куябыз да име, 4 әүме 5 әүме бер зурын панок дисең инде менә. Тегендә ничә метр китәсең дә шуны атасың. Менә шушындый (≈ 1 м. – *И.Я.*) агач белән сугып еббәрәсең панокны. Теге тезеп куйган кузыйларга тидерергә кирәк, җыеп санап барасың, тисә.

**«Панок»** уныйбыз ди торганыек сыерларныкы зур була, сарык-бозауларныкы кечерәк, ваграк малларныкы ваграк була инде. Таякны үзеңә ничек кирәк, точно размеры юк инде аның.

### *Чана шуу*

Конюшнадан чана, кошовка урлап, шуңа салам салыр идек тә шунда утырып чана шуа идек. Белсәләр, орышалар. Каравылчы да куеп торалар, алып китмәсен, дип. Аларның тәртәләрен өзеп калдыра идек, нишләтәсең, шуып булмый ич, кадала ич. Я күтәртеп кашовканың башына бау белән бәйләп куя торган идек.

**Качыш**ып уйный торганыек.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Семенов Михаил Васильевичтан*
*(1936 елгы) язып алынды*

Уен күп булды инде. «Ат юлы», «Туфрак», «Каурый».

**_«Каурый» уены_**

Тезеп «Каурый» уйный торганыек. Тәпәч белән, кулда тәпәч. Туфракка тезелеп куела да каурыйлар, шуннан, шул тәпәчне җибәреп, каурыйларны җыгасың инде. Үзең җыкканны җыеп аласың. Менә шундый каурый уены.

**«Городки»**

Шакмаклар тезеп, аны да шул тәпәч белә атып, җимереп бетә торган. Татарча исемен хәтерләмим дә инде.

**_«Чебен» уены_**

Менә җиргә казык кагасың да шуңа шушындыйрак киртекләп шуның башына кертеп куясың. Чебен була инде ул. Шул тәпәч җибәртеп очыртасың. Тәпәч казыкка килеп бәрелә дә чебен очып чыгып китә. Агач ботагын әзрәк киртекләп казык башына утыртып куя торганыек. Киртек казыкның өстендә тора, шуның башына куясың чебенне. Казыкка тәпәч килеп бәрелгәч, чебен очып китә.

**_«Шар» уены_**

Кәшәкә – хәзерге хоккей шикелле, ул вакытта хоккей дигән нәрсә юк, белмәдек тә, без малайлар шул шар уйный торганыек инде. Агач тамырыннан кәшәкә ясый торганыек инде, шары да шул агач йомрысыннан була инде аның, шул шар итеп ясап. Бер чокыр казыла торганые инде. Чокырга төшерү тиеш була торганые, шарны алып килеп. Шул төшсә, кемнеке төшә. Карап тормый инде, алар да сугарга тырыша барыбер.

Сугып кына нитми, кайчакта китереп бирәсе ич аны.

**_«Кузна»_**

Хайванның аягында була инде ул кузна. Кузнаны тезеп куясың да шул кузна белә җибәреп җыгасы теге тезеп куелган нине. Мал сөягеннән бүтән уен юк. Менә шул кузна уены бар ие бездә. Әнә шул малны суйганда кузнаны җыя торганыек.

Бала чакта инде, без олыгая башлагач бетте ул безгә уеннар. Эшкә тотындык аннан.

* * *

Йөргәләдек инде, бик күп йөреп булмады. Аулак өйдә, шул әти-әниләре кунакка киткән йортта була торганые инде ул авылда. Билгеле йорт була торганые шунда яшьләр җыйнала торганые инде. Анда кызлар, яшьләр шунда төрле уеннар, «Кәҗә ябыш»лар, шундый төрле «Шырпы салыш»лар, хатын-кызлар чигүләр белән маташып нитә торганнар ие. Аулагыйда шундый уеннар була торганые.

Бер кеше шырпы сала. Шул шырпыны кемгәдер салып куя. Кемдәдер. Шуннан әйләнеп бетергәч кругом: – Шырпы кемдә, йөгереп чык, – дип кычкыра. Шуннан теге шырпылы кеше сикереп тора. Җәза бирелә.

### *«Кәҗә ябыш»*

Тышка чыгып. Бер алып чыгып китәсең инде, үзеңә ошаган, менә шунда сөйләшеп керәсең инде, үбешеп. Шул биргән җәза була инде ул.

Яшьләр җырлап утыралар иде инде.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримов Хәбир Кәрим улыннан*
*(1925 елгы) язып алынды*

### *«Чүрәкәй калак»*

Шакмакны бер башын болай иттереп, икенче башы моннан була. Шуңа калак шикелле әйбер ясыйсың да, менә мондый шакмакка куясың да, 1, 2, 3, пары бар ие, 4 яклы ич инде шакмак.

Шундый шакмакка бер ягына – 1, икенче ягына – 2 ... куясың да калак белән китереп бәрәсең – очып китә. Төшә. Ыргыталмаса, теге калак белә тагы бәрә ала. Пәпәри ала, пәпәри дип атый идек, очко җыя.

Калагы тактадан, менә болай итеп ручка ясыйсың да, аны түгәрәк башлы да итеп ясыйлар ие, озынча иттереп, ә чүрәкәе – шакмаклы, бәреп җибәрә торган бер башы, очы очлана.

Ботка ашатканда, кем ахырдан җиңелә: 2 төшсә – ике тапкыр нитә, 3 төшсә – 3 тапкыр ашата.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримова Зөлфия Хәбир кызыннан*
*(1963 елгы) язып алынды*

### *«Бура таягы»*

Яшь чыршыны әйбәтләп, каезлап шомартып суга манчып бозга катырасың да, менә болай иттереп җибәрәсең кар эченнән бара ул, карны тишеп бара ул үзе. Яман каты җырак китә ул. Кемнеке ерак китәр инде.

### *«Кәҗә мае чыгару»*

Әнә почмакка, стенага берәү баса, шуңар тезелеп кыса, шунда кем бүселеп чыга инде.

Кәҗә мае чыгару – бер кеше стенага терәлеп тора, икенче, өченче, дүртенче кешеләр белән торып, беләге белән этә, бөтен кеше этә, 10–15 кеше җыеламы, теге кешене кысасың.

Менә шуннан теге чыдый алмыйча бүселеп чыга, кем чыдый алмый, уртаданрак бүселә башлый ул.

### *«Ун агай»*

«Ун агай» уены уйный торган идек. Атлар күп. Кыш көне бит инде ул «Ун агай» уены. Ансы өчен әниләр дә орыша торганые әле аның. Ат бугы ката бит име, йозрык булып, менә шуны тибеп тегенең аягына тидерергә кирәк бергә катнашкан кешенең.

10–15 малай керә уенга ул вакытта.

Ул я читкә тайпыла, я сикереп кала. Тидермәсә шул вакытта аркаңа сугалар, тидерә алмасаң. Ул бит кругка алган, тибүче уртада, син әллә монда җибәрәсең, әллә уң аяк белән, әллә сул. Аркага шул кругтагы кешеләр суга, йозрык белән.

Әгәр тидерә икән – чыгып китә. Аягына тигән кеше кереп баса уртага – тибүче була.

### *«Сызыкташ»*

Җәйгә чыккач «Сызыкташ» дигән нәрсә уйный идек.

Менә шулай шакмаклар сызасың да.

Болай иттереп (сикереп. – *И.Я.*) барасың – сызыкка басмаска тиеш. Сызыкта бер ташы бар бит инде, шул ташны (аяк очы белән. – *И.Я.*) болай итеп чиертеп җибәрә, күчереп барасың

шакмактан – шакмакка. Чиратлашып уйныйсың, ничә кеше бар. Күпчелек ике кеше уйный идек. Сызыкка тисә, икенче кеше уйный. 6 шакмак. Монда (өстә. – *И.Я.*) бер дугасы була. Шул дугага чыгара алса, сызыкка тидермичә, бу җиңгән кеше була инде. Таш беренче шакмакка төшкәч, ул аны турыга күчерә, тегендә чыгарырга тиеш. Беренче шакмакка ыргытып, тегендә чыгаргач, аннан 2 нче шакмакка ыргыта. Барлыгы 12 шакмак була инде ул. Шул уникесен дә чыгаргач дугага – җиңүче була. Бер сызыкка да тидермичә. Бер тидерсә бөтен уены юкка чыга, яңадан 1нче шакмакка ыргытып башлый. Тасмаграк кирәк. Күпчелек теге чынаяк тәлинкәсе бармый, әнә шуның ватыгын сала торганыек, ул шома бит. Ул төшеп кала икән – син башлыйсың. Чиратлап уйный идек. Хәзер уйнамыйлар. Гел кампитрда.

*Арча районы Кызыл Игенче авылында*
*Сәлахов Вил Бари улыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

### *«Кузна»*

«Кузна» уйныйдырыек. Менә утырабыз да кузналарны алып (сарыкның аяк-тәпиләрендәге, барнак башларында кузна булып чыккан инде ул). Хәзер ике кеше булабыз инде. Хәзер ыргытабыз. Кем ата башта, кем атырга тиеш? 1, 2, 3 дигәндә кем башта әйтә ала, шул ата ала, шул уенны башлый.

Читкә карый да: «Бу кемнеке?» дип кычкыралар да.

Әйтәсең исемен-ниен. Әйтәсе кешенең исемен теге кеше дә беләә. Шуннан ул кеше күрми. Кем икәнен дөрес әйтсә, теге кеше башлый уенны.

Кузнага ыргытырга я таштан ясыйлар шомартып, я менә атның тәпиендә кузнасы була, шуңа кургаш коялар да артына, кургаш койгач авыр була бу. Пагун була бу атарга, ата торган ни була инде.

*Арча районы Апаз авылында*
*Миңнебаев Гыйниятулла Миңнебай*
*улыннан (1924 елгы) язып алынды*

«Кузна» дип уйный торганнарые. Безгә бик эләкмәде ул.

### *«Әкәй»*

«Әкәй» уены уйныйбыз, ди торганнарые. Бер казык кагып куясың да шуңа кармаклы итеп ясаган бер агач элеп куясың. Ничә адымнан шуңа тидерә алсаң – ничә адымга оча теге. Әнә шул элеп куйган агачына тидерәсең, теге очып китә, эләгеп кенә тора ул. Чама белән бәрә торган таяк 1 метр. Элеп куйган әйбер – әкәй.

*Арча районы Мәмсә авылында*
*Сибгатуллин Равил Габделнур улыннан*
*(1950 елгы) язып алынды*

Малайлар белән шул инде, агачтан коньки ясап, конькига калай тегеннән-моннан табып, монда кечкенә генә су ката торганые, уйнадык инде.

### *«Чүрәки»*

Менә болай итеп агачны очлыйсың да инде, калаксыман ясыйсың да, сугасың да тегендә. Кая хәтле бара. Шулай итеп уйнадык инде. Бу чүрәки таяк өстендә ятып тора, таяк җирдә ята. Бу башына сугасың да, теге китә еракка. Ике башы да очлы була аның. Күтәрелеп торган җиренә – башына сугасың. Кемнеке күпме хәтле җир бара инде.

* * *

Аулагыйдә (ул чакта клуб булмаганмы инде ул) өелешеп, кызлар белән яшьләр белән өелешеп утырыр идек тә атасы-анасы каядыр киткәч.

Шуннан тәңкә салалар да инде анда нәрсә туры килеп инде, тышка чыгып керәсең инде.

Бер шар сымак була инде ул. Аның клубы да юк ие элек. Җыеп иске-москы киемнәр булыр ие, беркем гаеп итмәс ие.

*Арча районы Акчишмә авылында*
*Гарипов Заһир Гариф улыннан*
*(1930 елгы) язып алынды.*

## Җырлар

Беркем ерламый, борынгы җыр, ди:

***Яшел тугай буйлары***

Исеңдәме, (кара) урман буйларында
Бергә-бергә җиләк җыйганың?
Сандугачка кушылып мин җырладым,
Ә син өзелеп-өзелеп тыңладың.

Кушымта:

Эх, ямьле яшел тугай буйлары,
Матур иде яшьлегемнең уйлары.

Исеңдәме, яшел болыннарда
Бергә-бергә чәчәк өзгәнең?
Аерылганда соңгы бүләгем дип,
Миңа ландыш өзеп биргәнең.

* * *

Көлдерә торган җырлар күп иде. Бер Мулланур дигән малай бар ие. Алар тау кырыенда яталар. Кызлар уйный инде. Без инде янәсе фронттагы егетләребезне сагынып җырлыйбыз:

Одеал ябынасыңмы,
Юрган ябынасыңмы?
Мин сагынам өзелеп-өзелеп,
Син дә сагынасыңмы, дип.

Безнең җырлаганны тыңлап яткан да теге тау кырыендагы җегет:

Одеал да ябынмыйм,
Юрганын да ябынмыйм,
400 грамм бике *(вика)* ашап
Ничурта да сагынмыйм.

*Арча районы Сежçе авылында*
*Әхтәмова Шәмсинур Шәрәфетдин*
*кызыннан (1925 елгы) язып алынды*

* * *

Олы юлдан атлар килә,
Безгә кала тузаны.
Алда гомер бардыр барын,
Сагындыра узганы.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Фазылҗанова Тәнзилә Сабир кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды*

* * *

Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам.
Иркәм китте еракларга
Сагыну утында янам, –

дип вечер уйнаганда җырлыйлар иде аны, егетләр армияга киткәч, кызлар сагынып җырлый иде.

* * *

Сандугачлар оялаган
Алмагач ботагына.
Бер ярны ике сөймәгез
Гомерегез эчендә.

* * *

Эх, яшь чагым, яшь чагым,
Яшь чагым юләр чагым.
Шул яшь чагым, юләр чагым
Әйләнер микән тагын...

* * *

Яшь чагымда күкрәгемә
Чәчәкләр кадамадым.
Чөнки яшьлек үзе чәчәк,
Кирәк, дип санамадым

* * *

Минем чәчем озын түгел,
Төшеп тормый билләргә.
Яратып йөргән ярым юк,
Тора алмам бу илләрдә.

* * *

Алларым да син идең,
Гөлләрем дә син идең,
Утларын да син кабыздың,
Суларын да сип инде, –

дип тә ерлый торган идек.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Шәрипҗанова Кадрия Салих кызыннан*
*(1933) язып алынды*

* * *

Ак Иделнең параходы
Җитә алмый Кызылъярга;
Җитә алмый, дуслар, җитә алмый
Яратып сөйгән ярга.
Ак Иделнең параходы
Җитә алмый Кызылъярга,
Җитә алмый Кызылъярга;
Сине уйламый үтәр микән,
Сәгатьнең бер минуты,
Сәгатьнең бер минуты?
Җитә алмый, дуслар, җитә алмый,
Яратып сөйгән ярга.
Ак Иделнең суларына
Уралып агар идем;
Яңгыр тамчылары булсам,
Алдыңа тамар идем, –

дип, әти Нуриев Гәбделфәрт Нурмөхәммәт улы (1927–2012) җырлый иде.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Лотфуллина Ания Гәбделфәрт кызыннан*
*(1957 елгы) язып алынды*

* * *

Мәҗлесләрдә генә кара-каршы җырлыйбыз. Кара-каршы җырлар, такмаклар бар:

Ничек килдегез сез безгә
Батмыенча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә
Ни хөрмәт итик сезгә!

Менә мин баяниска бик күп җырладым инде:

Безнең Фаил гармун уйный
Ике җиңен сызганып.
Гармуның бик авыр
Үләм инде кызганып.

* * *

Биек тауны менгән чакта
Тая минем галушым;
Тагын берне җырла әле
Матур икән тавышың, –
диләр инде. Шуннан каршысына:

Бишмәтемдә биш төймә бар,
Алтынчысы каптырма;
Бер дә җырлар чамам юк бит,
Миннән җырлар таптырма, –

дип җырлыйм инде.

* * *

Каршы уен уйнаганда җырлана:

Өстәлләрдә алсу алма
Алып ашарсың микән?
Мин сагынып хатлар язам,
Сез дә язарсыз микән?

Нигә кыек торасың,
Нигә кыек торасың?

Кыек торуларың белә
Безне боектырасың.

Озын кеше чыкса:

Озып булып үскәнсең,
Озып булып үскәнсең дә
Кәкерәеп төшкәнсең.

Һәр кешенең фасонына карап җырлыйлар:

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре Наташа.
Ташла-башла, башла-ташла,
Шулай башларын аша.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Хәкимова Әлфия Малик кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды*

* * *

Безнең авылда бер җырчы гармунчыга болай дигән:

– Шураның бөтен 120 йортын әйләнеп чыгабыз. Бер йорт турасыннан узганда бер җыр җырлыйм, – дигән. 120 йорт – 120 җыр җырлыйм, – дигән, гармунны гына уйна, – дигән. Бик шәп җырлаган кеше булган ул.

Иң ахырдан, җыры беткәч менә нәрсә җырлаган:

Без үзебез бик бай түгел,
Безнең өйләр чарлаклы;
Кайда эшләсәк, шунда ашап,
Туйдырабыз тамакны, – дип.

Җырны любой көйгә җырлап була. Сания көенә дә җырлап була. «Баламишкин»га да җырлап була.

Сания көенә уйныйм:

Сания апа суга бара,
Алма-алма чиләге.
Алма чиләгенә караганда,
Үзе кура җиләге.

Гармуннарыңны уйныйсың,
Сания көен уйнама.
Нурлы йөзләрең саргаер,
Баскан саен уйлама.

«Сания»да, «Баламишкин»
Минем сөйгән көйләрем;
Бергә булган вакытларны
Сагынып-сагынып сөйләрмен.

Нигә үлән баса икән
Сания каберләрен?
Яшь гомерләр ике килми,
Белегез кадерләрен.

Сания апай суга бара,
Алмалы көянтәсе.
Алмалы көянтәсенә
Таянган сөяркәсе.

* * *

Колхоз тарала башлады,
Вәкилне кыйнап ташлады
Усал агайлар, –

дип җырлыйлар иде.

Хатын-кызларның чәчен кисәләр,
Маңгаегызга «колхоз» дип пичәт басалар, –

дип байлар шундый коткы тараткannар, колхозга керсәгез, дип.

Олы Әтнәдән агитбригада килде, шулар җырлады (әни апменде мине, мин мондый кечкенә генә):

Хатын-кыз чәчен кисүне,
Маңлайга пичәт басуны
Кемнәр чыгарган аны?

Андый-мондый хәбәрләргә,
Кулак кызы Камәрләргә
Сез ышанмагыз аңа! – ди агитбригада.

Сыер, сарык, кәҗә, атларны алдылар. Колхозга керсәгез, табыгызны да алалар, бернәрсәгез калмый. Шундый коткы тараталар. Аңа болай дип җырлый:

Сыер, сарык, кәҗәләрне,
Каз-үрдәк һәм күркәләрне
Берләштермибез инде!

Димәк кулда кала бар да,
Катык, сөт, йомырка, май да
Аша яратсаң инде!

* * *

Җырларны кругта да җырлыйлар, болай дип:

Мылтык атарга оста мин,
Бик күп тордым постта мин.
Юлбашчыбыз – Компартия
Җитәкчебез – Сталин, –

вот шулай дип җырлыйсың мактап Сталинны.

* * *

Әйдә, туры ат, мине озат,
Мин киткәч симерерсең;
Мин киткәч солы бетәр,
Тагарак кимерерсең.

Әчлек башланган ич инде.

* * *

Басу капкасын чыкканда,
Карадым бер борылып,
Туганнарым, сөйгән ярым,
Каласыз ич аерылып, –

җырлыйсың урам көенә.

* * *

Туйларда җырлыйлар ич:

Абзый, атларың юргамы?
Башын чайкап җуыртамы?
Сөйгән ярым куштан дисең,
Үпкәч авызын сөртәме?

* * *

Әвендә (ашлык киптерә торган урын) ашлык сугалар чабагач белән. Мин беләм аларны. Агач сукадан алып, тимер тракторга кадәр. Агач сука иде мин малай вакытта. Әтиләр этеп йөри, ат тарта. Элек әйткәннәр бит:

Көне буе интегәм,
Бер түтәрәм җир сөрәм.
Арык атым тарталмагач,
Бер кизәнәм, бер сугам.

*Арча районы Шура авылында*
*Исмәгыйлев Ризван Исмәгыйль улыннан*
*(1923 елгы) язып алынды*

Гәрәбәләрем чәчелде
Таллык араларында.
Нурлы йөзегез балкысын
Халык араларында!

Ак өемә чаршау кордым
Итәкләрен таратып;
Үзем бер җыр җырлыйм әле
Сез кунакларны җаратып.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Петрова Анна Васильевнадан*
*(1928 елгы) язып алынды*

Дошманга каршы сугышка
Ленин чакыргач безне,
Татбригада атка менде
Сакларга илебезне.
Фирганә, Бохара –
Без үткән ара
Эх!
Фрунзе безнең командарм,
Дошманнарны җиңдек барын
Данлы елларда, данлы елларда, –

дип җырлый идек.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримова Ләйлүфәр Әфләтүн кызыннан*
*(1955 елгы) язып алынды*

Мәрҗәннән бер җегет менеп йөри иде, бер күрше кызы янына. Моның кызын анасы чыгып, апкереп киткән. Сәлахетдин исемле ие ул.

Анасы чыгып мине пыран туздырып, кызын орышып апкереп китте.

Мин:

Самаварны тиз кайната
Кызыл агач күмере;
Кыз саклаган карчыкларның
Кыска булсын гомере, –

дип җырлап уздым Сәлахетдин белә.

* * *

Стаканнарның төбендә
Бөтерелә яшь үлән,
Сез кунаклар хөрмәтенә
Бер тереләм, бер үләм, –

шундый җырлар күп ие, хәзер онытабыз.

* * *

Камбайннар уралмый,  
Кызлар калган малайларга,  
Малайлар булдыралмый.

*Арча районы Кызыл Игенче авылында*  
*Сәлахов Вил Бари улыннан (1938 елгы)*  
*язып алынды*

Озын булып үскәнсең,  
Озын булып үскәнсең,  
Озын булып үскәнсең дә  
Бөкерәеп төшкәнсең.

Тау башында урак урабыз инде. Бер сложный молотилка дигән машина китереп куйдылар. Бу тора да тора. Урмый да бу, сукмый да бу. Хәзер без моңа ничә төрле җыру чыгардык:

Комбайн урыр әле,  
Урмаса торыр әле,  
Ул да урмаса, без дә урмасак,  
Бик кызык булыр әле.  
Комбайннар уралмый,  
Кызлар калган малайларга,  
Малайлар булдыралмый.  
Комбайн урыр әле  
Урмаса торыр әле,  
Урмаса урмасын әле  
Күләгәсе зур әле, –

дип җырлап күләгәдә ял итәбез.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*  
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан*  
*(1930 елгы) язып алынды*

Машинада барабыз
Туктар микән Мәмсәдә?
Нигә кулым салдым микән
Күрми күргән нәрсәгә?

*Арча районы Апаз авылында*
*Миңнебаев Гыйниятулла Миңнебай*
*улыннан (1924 елгы) язып алынды*

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде каласың;
Үзем киткәч, кем карар
Син сандугач баласын...

*Арча районы Мәмсә авылында*
*Касыймова Гарифә Гыйләҗетдин*
*кызыннан (1918 елгы) язып алынды*

Тракторлар эскерт сөйри,
Түбәсе көрәлмәгән.
Көрәлсә, көрәлмәсә,
Эш анда терәлмәгән.

*Арча районы Мәмсә авылында*
*Сибгатуллин Равил Габделнур*
*улыннан (1950 елгы) язып алынды*

Ал минем түбәтәем,
Гөл минем түбәтәем;
Хөкүмәткә файда булсын,
Бер сумны түләтәем.

*Арча районы Акчишмә авылында*
*Гарипова Әнисә Миңнеәхмәт кызыннан*
*(1933 елгы) язып алынды*

## Балалар фольклоры

### *Бишек җыры*

Әлли бәлли итәр бу,
Үсеп буйга җитәр бу,
Үсеп буйга җиткәченән
Галим булып китәр бу.

*Арча районы Пүчинкә-Поник авылында*
*Исхакова Мәдинә Ибраһим кызыннан*
*(1928 елгы) язып алынды*

* * *

Әлли бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Энем йокыга киткәч,
Әнкәй мине пәп итә.

Кошлар кунган тирәккә
Аларны җил тирбәтә.

Йоклый бала, төш күрә,
Көлә, күккә сөенә,
Имеш, аны әбисе
Үчти-үчти иттерә.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Фазылҗанова Тәнзилә Сабир кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды.*

* * *

Аллаһу, валлаһу,
Кәҗәләрне тауга ку;
Кәҗә тауны ашасын,
Илфат йоклый башласын, –

дип җырлый торган идек.

* * *

Бер дидем – бермәк,
Ике дидем – икмәк,
Өч дидем – өчмәк,
Дүрт дидем – дүртмәк,
Биш дидем – бишмәк,
Алты дидем – ахмак,
Җиде дидем – җитмәк,
Сигез дидем – сикмәк,
Тугыз дидем – тукмак,
Ун дидем – уймак,
Ул уймакны казга бирдем,
Каз миңа күкәй бирде,
Ул күкәйне мичкә куйдым,
Дөбер-шатыр кайный калды.
Үзем киттем Әтнәгә,
Ян тәрәзә какмага,
Кактым, суктым,
Тәңкәләре чәчелде,
Ул тәңкәне җыя-җыя
Биш бармагым җәнчелде.
Эте чыкты өрмәгә,
Кызы чыкты көлмәгә,
Этен алдым пычакка,
Кызын алдым кочакка,
Әби белән бабайны –
Төртеп ектым почмакка.

* * *

***Һап та һоп***

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.
Базга төштек май ашадык.

Бер тактага тезелдек,
Келәткә кердек бал ашадык
Һап-та-һоп.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Шәрипҗанова Кадрия Сәлих кызыннан*
*(1933 елгы) язып алынды*

Әлли-бәлли итәр бу,
Үсеп буйга җитәр бу;
Үсеп буйга җиткәчтен
Галим булып китәр бу, –

шул әбиләрдән калган сүзләр инде.

* * *

Мунчада коендырып алгач әйтә торган сүзләре бар, әбиләрдән калган, борынгы инде:

– Суы сарыксын,
Улым калыксын,
Тәрбияле, тәүфикълы, миһерле,
Шәфкатьле, озын гомерле булсын!
Сузылсын-сузылсын, су буе булсын *(сыпырасың)*
Киерелсен-киерелсен –
Киртә буе буйлы булсын, –

дип сыпырасың баланы, су коендыргач.

* * *

Күчтеки-күчтеки,
Үсмәгәнгә – кечтеки.
Үсәр әле зур булыр,
Менә дигән егет булыр! –

дип чөеп җибәрәсең. Аннары сикереп синә ябыша инде.

*Арча районы Түбән Оры авылында*
*Хәкимова Әлфия Малик кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды*

Әке-бәке, кыек сәке, эремчек
Син калып тор, энем – чык.

* * *

Өеңә кайт,
Капка астыннан карап ят.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Архипова Вера Васильевнадан*
*(1953 елгы) язып алынды*

Әке-бәке, кыек сәке,
Син – кал, син – чык.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Семенов Михаил Васильевичтан*
*(1936 елгы) язып алынды.*

Әке-бәке, кыек сәке,
Чәүкә-чыпчык,
Син – кал,
Син – чык.

*Арча районы Сәрдәбаш авылында*
*Семенова Александра Николаевнадан*
*(1940 елгы) язып алынды.*

Әлли итәр бу бала,
Бәлли итәр бу бала,
Атасына-анасына
Хезмәт итәр бу бала.

*Арча районы Шекә авылында*
*Кәримова Бибирәшидә Гыйниятулла*
*кызыннан (1924 елгы) язып алынды*

Әй, кәҗәкәй-кәҗәкәй,
Расхотың бәләкәй.
Бер кашык та сөт бирми
Нәләт төшкән нәмәкәй.

* * *

Әнчек-мәнчек, монда торма тиз чык.

* * *

Әнчек-мәнчек борының янчык,
Авызың чалыш, күзең зур.

* * *

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Бозга төштек май ашадык,
Келәткә кердек бал каптык,
Яп та хоп, авызыңны җап.

Берсе көлеп җибәрә дә, аңа:

– Кем өй түбәсенә тычтың, – дип маңгайга чиертәләр ие. Бер өйне әйтәләр дә. Шунда ничә кеше бар, маңгайга чиертәсең, шул кеше санынча.

* * *

Мияу-мияу, пескәем,
Хыянәтче икәнсең,
Саклый торган маеңны
Үзең ашап киткәнсең, –

дип җырлый торганыек.

* * *

Барып кердем мунчага,
Мунча ишеген ачып куйсаң,
Ике пәри кул чаба, –

дигәннәре барые аның.

* * *

Балаларга болай итеп (кулын сыпырып тора. – *И.Я.*): Песи, песи, песи.... дисең дә, перәс дип (кул аркасына суга. – *И.Я.*) җибәрәсең.

* * *

Кәҗә менгән печәннеккә  
Сәбәп белән.  
Гали аның артына төрткән  
Сәнәк белән.  
Кәҗә әйтә:  
Алла, артым тишелде, ди.  
Гали әйтә:  
Кычкырма, бөтен авылга ишетелде, ди.

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*  
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан*  
*(1930 елгы) язып алынды*

## Халык сүзләре, паремияләр

Ананы олылау иң зур савап,  
Икенче – ипине олылау савап.

*Арча районы Пүчинкә-Поник авылында*  
*Павлова Лиза Василий кызыннан*  
*(1935 елгы) язып алынды*

Кузгатмагыз –  
Иске яраларны,  
Яралырга тора яңалары.

* * *

Ялгыз картлык, – вакыт җитми үлүгә тиң.

* * *

Кеше гомерен чир генә түгел, моң-сагыш та кыскарта (канатлы сүз, паремия).

* * *

Кояш – чыгышта, кош – очышта,  
Кеше – юмартлыкта матур.

* * *

Кайнана – тормыш агачының иң кирәксез ботагы.

* * *

Яхшы белән юлдаш булсаң,
Малга юлыгырсың.
Яман белән юлдаш булсаң,
Ярдан егылырсың.

*Арча районы Кызылъяр авылында*
*Фазылҗанова Тәнзилә Сабир кызыннан*
*(1952 елгы) язып алынды.*

**Табышмаклар**

Кат-кат тунны,
Карыш буйлы (кәбестә).

Әтисе аяк киенгәнче
Малае урманга җитә (ут янып беткәнче төтен).

*Арча районы Сеҗе авылында*
*Әхтәмова Шәмсинур Шәрәфетдин*
*кызыннан (1925 елгы) язып алынды*

Бу дөньяда нәрсә озын? (юл)

*Арча районы Пөшәңгәр авылында*
*Сәйфуллина Энгельсинә Васил кызыннан*
*(1930 елгы) язып алынды*

# ШҮРӘЛЕ ТУГАН ҖИРДӘ

*Гөлнара Яхшисарова*

Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре, йолалары, кабатланмас гореф-гадәтләре бар. Алар халыкта милли горурлык, милли хисләр тәрбияләргә ярдәм итә. Татар халкының бик күп йолалары халык хәтерендә, өлкән буын кешеләренең истәлекләрендә сакланып килә. Аларның бик күп өлеше инде, кызганыч, бүгенге көндә кулланылмый.

Халык иҗаты белгечләр тарафыннан төрле экспедицияләр барышында халыкның үзеннән өйрәнеп, тел осталары яки авыл хәтерен саклаган абруйлы кешеләрдән сөйләтеп теркәлә, фәнни әйләнешкә кертелә. Менә шул максат белән төрле төбәкләрдә яшәүче татар халкыннан халык йолалары турында мәгълүматлар җыйнала. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Арча районына оештырылган комплекслы экспедициянең максаты да әнә шул иде.

Экспедиция барышында халык иҗаты материаллары Арча районының Пүчинкә-Поник (Починок-Поник), Ташкич, Ташкичү, Сеҗе (Сезе), Кызыл Яр (Кзыл-Яр), Түбән Оры (Нижняя Ура), Байкал, Шурабаш, Сәрдәбаш (Сердебаш), Шура, Шекә (Шека), Кече Әтнә (Малая Атня), Апаз (Апазово), Пөшәңгәр (Пшенгер), Хәтнә (Хотня), Ашытбаш (Ашитбаш), Носы (Нуса) һәм башка авылларында җыелды. Информантлардан язып алынган материаллардан тыш, мәктәп, авыл музейларында сакланган рухи хәзинәләр дә файдаланылды. Халкыбызның рухи мирасын саклап калуда һәм аларны яңадан халыкка кайтаруда

зур эш башкарган татар теле һәм әдәбияты укытучыларына рәхмәтебез зур.

Татар традицион мәдәниятын саклау, халыкка фольклорны, рухи мирасны ирештерү, онытыла барган милли йолаларны, халык җырларын саклап калу һәм киләчәк буыннарга җиткерү максатыннан авылларда фольклор коллективлары оештырылган. Мәсәлән, Урта Сәрдә авылында – «Нур», Шура авылында – «Чордашлар», Ташкичү авылында «Өммегөлсем» фольклор коллективлары бүгенге көндә дә бик актив яшиләр. Алар, татарларның халык иҗаты белән кызыксынудан тыш, аларны җыю, саклап калу белән дә шөгыльләнә.

Экспедиция вакытында шактый гына риваятьләр һәм легендалар язып алынды. Риваятьләрдә авыллар тарихы, кемнең дә булса язмышы бәян ителә. Һәрбер информант ата-бабаларының кайдан килеп урнашуын, алар тормышына бәйле төрле вакыйгаларны белә.

Мифология халык иҗатының иң борынгы катламын тәшкил итә. Күп гасырлар элек кешенең әйләнә-тирә дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары нигезендә күпсанлы ышанулар, йола-ритуаллар туган. Җир иясе, су иясе, тау иясе, хайваннар иясе, йорт иясе, урман иясе бар дип ышану бүгенге көндә дә халык арасында яши. Арчада киң таралыш тапкан персонажларның берсе – йорт иясе (җорт иясе, өй иясе, нигез иясе). Ул я мич башында, я идән астында яши һәм кешеләргә ярдәм итә. Йорт иясе төрле кешегә төрлечә күренә, әмма күпчелек очракта актан киенгән олы яшьтәге хатын-кыз яисә ир-ат кыяфәтендә очрый. Йорт иясе өйне бәла-казадан саклый, төннәрен чыгып ихатаны карап йөри, йоклап калган хуҗаларны уята, кайгы-хәсрәт киләсе булса, алдан хәбәр бирә.

Шулай ук җеннәрне, ияләрне күрүчеләр дә бар. Мифологик хикәяләрдә вакыйга, чынбарлыктан никадәр ерак булмасын, һәрвакыт реалистик тонда сурәтләнә һәм сөйләүче тарафыннан да, тыңлаучы тарафыннан да булган хәл дип кабул ителә.

Төрле вариантларда аталып йөртелә торган Хозер Ильяс (Хызыр, Хозер, Хозер бабай, Хызыр Ильяс һ.б.) персонажы турында риваятьләр дә язып алынды. Татар халкының ышануларын-

да Хозер Ильяс юлчылырга юлдаш, адашкан кешеләргә ярдәм итә торган ак сакаллы карт буларак ачыклана. Күп очракта аны халык юл иясе дип атый. Ул хәер, су сорап йөргән булган. Бу риваятьләр исә хәер, су сорап килгән картларга мәрхәмәтле булырга өнди.

Биредә татар фольклорының күпчелек жанрларына караган әсәрләр бар. Әлбәттә, әкиятләр, дастаннар кебек күләмле әсәрләрне тулысынча хәтерләгән информантлар очрамады. Шулай да, кайбер өзекләр язып алдык.

Йомгак ясап өәйткәндә, арчалылардан халык иҗатының бик матур үрнәкләрен язып алып кайттык. Материалларның төп өлешен такмаклар, җырлар, бәетләр, ышанулар, риваять-легендалар, әкиятләр, бәйрәмнәр тасвирламасы, авыллар тарихына кагылышлы мәгълүматлар һ.б. тәшкил итә.

Язып алынган фольклор үрнәкләрен сезгә дә тәкъдим итәбез.

## Бәйрәмнәр, йолалар

### *Симек бәйрәме*

Марилар белән татарлар борынгы заманнардан бирле янәшә, тату яшиләр. Бу ике халык бергәләп эшләгән, бергәләп ял иткән.

Алар районыбызның чигендә – Шурабаш авылында яши, барысы 209 кеше. Марилар татарча аңлый һәм әйбәт сөйләшәләр.

Һәр халыкның үзенә генә хас милли традицияләре, гореф-гадәтләре бар, мари халкында да шулай. Мәсәлән, җәй аенда (июль башында) алар традицион күңел ачу чараларын «Симек» бәйрәме белән башлап җибәрәләр. Бу вакытта бер-берсенә кунакка йөриләр, җырлар җырлыйлар. Яшьләр төрле уеннар оештыра. Туйлар уздыру да шушы чорга туры килгән. Бу гореф-гадәтләр балаларда хезмәткә, табигатькә мәхәббәт, өлкәннәрне ихтирам итү кебек сыйфатларны тәрбияләргә ярдәм иткән. Симек – чәчәк бәйрәме дигәнне аңлата.

Бәйрәм табигатьнең иң матур урынында – болынлыкта уздырыла иде. Мари халкының милли уеннары: галош киеп йөгерү, чаңгы ярышлары, тоннельдән үтү, бау аркылы сикерү һ.б.

*Шурабаш авылында*
*Антипов Федор Антиповичтан*
*(1937 елгы) язып алынды*

Якында гына Зәрә тавы бар. Ташу вакытында ул тауга менеп салам яндырып, ташу суы белән күпергә таба агызып җибәргәннәр. Янганын карап торганнар. Аннары тау башына менеп уен уйнаганнар.

Яңгыр яумаганда, урамга чыгып «чүлмәнчек» уены уйнаганнар. Бер-берсенә чиләк белән су сибешкәннәр.

*Ташкичү авылында*
*Нәҗипова Илсөярдән*
*(1943 елгы) язып алынды*

Олы көн (пасха) – һавадагы ай белән килә. Ул көнне таба исе чыгарганнар. Берәр төрле иман укыганнар.

* * *

Питрау (12 июльдә). Обедка кадәр бәйрәм иткәннәр дә, обедтан соң печән чабарга чыгып киткәннәр. Пичкә чүлмәккә тутырып сыра куйганнар. Шул сыраны обедка кадәр эчеп бәйрәм иткәннәр.

* * *

Нардуган. Ул көнне я аю булып, я бүре булып киенгәннәр, төрләнеп йөргәннәр. Я бөтенләй оятсыз булып киенә инде. Киенә дә өйдән өйгә йөри. Өйгә кергәч аны биеткәннәр, җырлатканнар, я берәр кызык-мызык сөйләгән.

*Пүчинкә-Поник авылында*
*Павлова Елизавета Васильевнадан*
*(1935 елгы) язып алынды*

## *Нәүруз әйтү йоласы*

1815 елларның март башларында Нәүрүз әйтеп йөрү булган. Анда тирән чана әзерләгәннәр, аның уртасына мулла утырган. Аны 40–50 кеше җигелеп тартканнар. Шуны авылның бер башыннан икенче башына Нәүрүз әйтеп Мулла файдасына ашлык җыеп йөргәннәр. Мәмсә авылында бу эш киң таралган һәм көчле булган. Башка авылларда йөргәннәр, ә килешле итеп әйтеп йөргән сүзләре шундый булган:

Нәүрүз әйтәбез килдек,
Котлык җәмәлеңне күрдек.
Нәүрүз мөбәрәк бат
Батман бирсәң – күп булыр,
Подауга бирсәң – аз булыр,
Шадибат, шадибат, –

дип әйтеп йөрегәннәр.

* * *

Авылда әйберләрне күчереп кую булган. Авыл яшьләре урам буйлап йөреп, кешеләрнең капкаларын, скамьяларны күчереп йөрегәннәр, я күрше капкалары белән алыштырып куйганнар. Иртән торуга әни әйтә торган иде: – Кешеләр күргәләгәнче, әйберләрне җыеп урынына куегыз, – дип.

*Яңа Оры авылында*
*Сәетова Суфия Мәхмүт кызыннан (1961 елгы)*
*һәм Нуриева Нәфига ападан (1927 елгы)*
*язып алынды*

## *Таң суы алу*

Таң суының файдасы тисен өчен чәршәмбе генә алырга яраган. Фәлән кешенең улы/кызы, мин шуның өчен таң суы алам, шифасы тисен дип. Төнлә сәгать бердә генә алырга яраган. Шуның белән халык эчә, юына, коена иде.

Чирем-чорым каян килдең, шунда кач,
Миндә булма, җиргә кач, – дип әйтәләр.

*Ташкичү авылында*
*Нәҗипова Илсөярдән (1943 елгы)*
*язып алынды*

**Өмәләр**

Ноябрь аен – сугым ае дип йөретәләр. Аның билгеле бер көне булмаса да, тәртибе, кагыйдәләре төгәл үтәлә: суелган казларны каз йолкырга җыелган кызларга, чираттан кертеп, биреп торалар. Аны ялгыш идәнгә төшереп җибәрергә ярамый, кул арты була имеш. Бәлки ул чисталыкны саклау нияте белән чыгарылган ырымдыр, андый вакытта идәннәр бик пычрана. Казны йолкып бетергәч, ботларына бәйләнгән баудан көянтәгә асып, инешкә барып, инеш суында чистартып юалар. Инеш суы никадәр салкын булса, каз түшкәсе дә шулкадәр чиста, матур була, йомшарган каз мае катып китә.

Өмәнең икенче этабы – каурый сыдыру. Аның мамыгы кызларга бирнәгә мендәр әзерләргә җыела, ә каурыйлары, киләсе елга бәбкәләр күп чыксын дип юлга сибелә. Күтиген – койрык өстендәге май бизендә үскән мамыгын киптереп, кызлар элек аның белән кершән ягынган.

Өмәнең өченче этабы – иң шәбе. Идән-сәке юылган, хуҗа өстәлгә тәмле ризыклар чыгарып өйгән, шау-шу килеп чәй эчелә, кичке ял турында план корыла. Бер заман өй бүрәнәләре дөберти, тәрәзә пыялалары чыртлый башлый. Чыгып карыйсың – тып-тын, җил әсәре дә юк. Егетләр бүрәнә ярыкларына, тәрәзә рамнарына кадак белән җеп беркетеп әйбер асалар да, шуңа тоташкан озын җептән тартып, кадакларны, сәдәпләрне хәрәкәткә китерәләр – чирттерәләр, суктыралар. Бигрәк тә куркыныч тавыш чыгарып, асылган бәрәңге дөберти. Менә китә чыр-чу, бөтен өй кубып аякка баса. Шаянлыкта, тапкырлыкта авыл егетләренә тиңнәр юк. Шунсыз кызларны ничек дәртләндерәсең, ди.

*Сеҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

## Аулак өйләр

Кышкы озын кичләрдә чыра яктысында яшьләр бергә җыелышып кич утырган. Анда төрле кул эше тотканнар, бәетләр, мөнәҗәтләр әйткәннәр. Әгәр дә инде олылар берәр авылга кунакка китсә, ул өйдә яшьләр аулак өйгә җыелышып оекбаш, бияләй бәйләгән, җырлаган, биегән. Бераз кыюлана төшкәч, тәрәзә артында йөргән егетләргә дә аулак өй ишеге ачылган. Аннан соң төрле уеннар, җыр-биюләр киткән, таң атканчы шулай итеп яшьләр күңел ачкан. Аулак өй буласы алдан ук билгеле булып, яшьләр арасында бу хәбәр тиз таралган, аңа әзерләнгәннәр, хәтта күрше авылда яшәүче яшь туганнар да килә торган булган. Иң яратып уйналган уен – *«почта»* уены булган. Анда хәбәр биреп, берсен-берсе чоланга сөйләшергә чакырып чыгарган. Шунда беренче танышулар, серләшүләр, аңлашулар барган. Чоланда озаграк торган егетләрнең кайберләренә *такмак* чыгарып та өлгергәннәр:

Гали ачып керә микән
Аулак өйләр ишеген,
Гали үзе дә белми ул
Фикеренең ничеген.

Алмагачы төпләренә
Яулыгың төшеп калган.
Аулак өйләргә еш йөреп,
Дәрәҗәң төшеп калган.

* * *

*Аулак өй* турында Сәкинә апа сөйли иде: «Хәзер Кәшиф торган йортта элек әтиемнең туганы – Миңниса апа яшәде. Ул бик эшчән кыз гына булып калмый, күңел ача да белә. Туган булгач, мине дә аулак өйгә алып төшә. Алар очында Кәрам дигән тиле малай бар иде, аны бәйләп тоттылар, ычкынса, балаларны кыйный иде. Мин шуннан бик курка идем. Аулак өйгә алдан ук әзерләнәләр, коймак, пәрәмәч пешерәләр, самовар куялар. Боларда: Кәримә апа белән йөргән егете – Гыйлаҗ Барые, Сәләхи

Нәсимәсе, Фатыйх Шәмсие, апайның йөргән егете Бикми. Бикми оста гармунчы. Шәмси Гарифуллин Нигъмәт белән йөри, Нигъмәт бик шаян. Ашап-эчкәч, аулак өй дәвам итә – уеннар, җыр-биюләр, «почта» уены башлана – барысы чиратлашып-парлашып чоланга чыгып керә. Мин 8–9 яшьлек кыз, мич артыннан посып кына карап утырам. Бер заман мине күреп алдылар да, «монда чибәр кыз икән, имиләре бар микән» дип капшый башладылар. Мамык шәл, бишмәт, итек кигән килеш ничек мич башына менеп киткәнемне сизми дә калдым. Андагы эсселек, сумса пешерергә дип яккан мич сүрелмәгән. Апай үгетләп чак төшерде. Уеннар, тәңкә салышлар беткәч, тагы чәй эчәләр, аннары йокларга әзерләнәләр – урын җәеп, кочаклашып-парлашып, йокларга яталар».

*Сеҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

**Мәкальләр**

Яхшы сүз җанга рәхәт,
Яман сүз җанга җәрәхәт.

* * *

Кеше акылын ишет,
Үзеңнеке белән эш ит.

* * *

Ашның тәме тоз белән,
Кешенең кадере сүз белән.

* * *

Ата-ананы тыңлаган – адәм булган,
Ата-ананы тыңламаган – әрәм булган.

* * *

Оста барда – кулың тый,
Белгән барда – телең тый.

* * *

Ашаганда колагың селкенеп торсын,
Эшләгәндә йөрәгең җилкенеп торсын...

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән*
*язып алынды*

**Тыю, ышанулар**

Йокларга ятканда безгә әни өйрәтә иде:

И Ходаем, безгә рәхәт тыныч йокы бирсәң иде
Һәр төнге усал нәрсәдән зәвык сакларга фәрештәләрне җибәр.

* * *

Пасха вакытында мунчадан соңгы кеше чыкканда чүмечкә су, чиста су белән чайкатып сабын, себеркене калдырып чыкканнар. Аны үлеләрне искә алыр өчен куйганнар.

Үлеләр хәер догасы белән тереләр торыр,
Тереләр хәер догасы беләр үлеләр торыр,

дип әйткәннәр.

*Пүчинкә-Поник авылында*
*Павлова Елизавета Васильевнадан*
*(1935 елгы) язып алынды*

* * *

Балык ашарга ярый, ә менә ислам дине кануннары нигезендә, имеш, йортта асраган куян итен намаз укыган кешегә ашарга ярамый. Куян караучы Бәян апага карата хәтта җырлар да чыгарыла:

Бәян апа куян карый,
Бер анадан кырык бала.

Мәскәүләрдә орден алып,
Көннән-көн алга бара.

*Сежҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

* * *

Элек әни әйтер иде:

Кызым, карга букка төшсен, таң тишегеннән җырлама инде, – дип. Иртән җырларга ярамаган.

* * *

Авыл урамнары да элек яшел болыннардан калышмый – ямь-яшел үлән, эш арасында рәхәтләнеп ятып ял итә аласың. Әбиләрнең «ахыр заман алдыннан җәҗүҗ-мәҗүҗ килер, җирне кызыл балчыкка кадәр ашап бетерер», дигән сүзләре хәзерге техника турында булгандыр – ятып тору түгел, басып торырлык та яшел җир калдырмады ул.

*Сежҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

## Авыллар тарихыннан

### *Шурабаш авылы тарихы*

Хәзерге Шурабаш авылыннан 2 километр ераклыкта «Ташлынур» дигән авыл булган. Бу авылда марилар яшәгән. Шушы марилар күчеп китеп, сазлыклы җирне әйләндергәннәр, йортлар салганнар, хайваннар үрчеткәннәр. Шушы яңа авылга алар Шора-баш дигән исем биргәннәр. Хәзерге вакытта Шора-баш исеме Шурабашка әйләнә. Шора-баш авылында Морки районына кергән «чиста» марилар яшәгән. Бервакыт шушы авылга Мәңгәрдән ярлы татар ялланып көтүче булып килә, мари кызына өйләнә. Балалары үсеп җитәләр, башка чыгалар. Шулай итеп, татар нәселе барлыкка килә. Шора-баш авылында халык игенчелек белән шөгыльләнә, югары уңыш үстереп, күп табыш алганнар.

Марилар һәм татарлар арасында аерма булмаган. Совет власте барлыкка килгәч, аларга җирне тигез бүлеп биргәннәр.

Татарлар – көньякка, марилар төньякка урнашканнар һәм ике авыл исеме барлыкка килә. Марилар ягы Шишор, татарлар ягы Шурабаш исемен алган. Йортларны тәртипле итеп урнаштырганнар. Ике зур урам һәм дүрт кечкенә урам булган.

1930–1931 елларда колхозлаштыру чоры башлана. Марилар үзләренең колхозына – «Палантай», ә татарлар «Шурабаш» дигән исем бирәләр.

Революциягә кадәр авыл идарәсе, почта Шура авылында була. Аннан соң Шурабашка күчә. 1927 елда авылның беренче активисты, үзара ярдәмләшү җәмгыяте җитәкчесе Алексеев Ведаска булган. Ул үзенең аты белән, кешеләрне яллап, башлангыч милли мәктәп салдыра. Мәктәп булмаган чорда аерым кешеләрнең йортларында җыйналышып укытып йөргәннәр. Өйләрен биреп торганнары өчен акча түләгәннәр.

Сугыш башлангач күп кеше фронтка китә. Шишор авылына Литва, Латвия, Эстония ягыннан күчеп килгәннәр һәм башлангыч мәктәптә фин укытучысы Ванханнен Хелви укыта башлый. Аның белән бергә Андоп Ямнеевич, Семен Николаевич, Иван Хмелев укыталар. 1927 елда Шурабаш авылында ике катлы мәчет булган. 1933 елда мәчетне ябып, икенче катын, сүтеп, клубка әйләндерәләр.

1963–66 елларда «Палантай» һәм «Шурабаш» колхозлары берләшәләр. Колхоз «Большевик» исемен йөртә башлый һәм Тукай районына керә. Колхозга 7 авыл кушыла. Колхоз идарәсе Шура авылында урнашкан була. Партиянең XX съездын үткәргәч, «Большевик» колхозы Карл Маркс исемен йөртә башлый. Колхоз Арча районына күчә.

1945 елда Шурабаш авылында «Шишор» фольклор ансамбле барлыкка килә. Аның җитәкчесе итеп Туйбатров Тукташ билгеләнә. Бу ансамбль бүгенге көнгә кадәр авыл халкын куандырып тора.

*Шурабаш авылында*
*Антипов Федор Антиповичтан*
*(1937 елгы) язып алынды*

### *«Сеҗе» авылы исеменең килеп чыгышы*

Күп тапкырлар кабатланган «Мурья Мусич» атамасының «Мусич» сүзе Муса исеменнән русчалатып үзгәртелгән. Авылның исеме турында берничә юрама бар. Берсе буенча ул иске Му авылыннан килгән һәм Мусич фамилиясе алдыннан аның чыккан урыны әйтелгән – Му, ягъни Мурия. Икенче төрле караш та бар. Мусич Мөрәле авылыннан, ягъни Муриядән килгән, бирегә килеп тегермән салган, аңарчы анда удмуртлар (арлар) солы иккән. «Сеҗе» сүзе удмуртча «Солы» дигәнне белдерә, удмуртча ул «Сезьы» дип языла, ә татарча «Сеҗе» дип язылып киткән булырга тиеш.

### *Су тегермәне*

Мәктәп астыннан агым буйлый Мөрәлегә табарак су тегермәне була. Аның урыны хәзергә кадәр сакланган, ләкин Кәсмәснең сул яры бик текә, уң ярында керә алмаслык куе зиреклек, якын килеп булмый. Бер заман анда бөя[1] дә ясаганнар иде, аны су ерып китте. «Тегермәнне яшен сугып яндырган», – дип сөйләгән Гыйльмулла абый Гатин. Ул тегермән Муса бабайныкы булганмы, әллә башка кешенекеме – билгесез, әмма ләкин урыны бик дөрес, чишмә-инешләр Кесмәсне суга баета торган җирдә сайланган. Күрше-тирә халкы су тегермәне булмаган яклардан бирегә килгән.

*Сеҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

### *Шура авылы тарихына багышланган риваять*

Элекке заманда безнең авылда марилар яшәгән. Бер як урамда, елганың бер ягында – марилар булган, икенче як урамда, елганың икенче ягында – татарлар яшәгән. Мариларның зираты әлеге көндә юк. Аларның зираты әнә, ферма буенда. Анда

[1] Бөя – буа

мариларның кирәмәте була. Анда аларның хайваннар алып барып, суеп ашап, дога укый торган урыннары була. Безнең әти сөйли торган иде: «Кызым, ул кирәмәткә барып утыра күрмәгез, анда утырырга ярамый». Шулай марилар белән яшәп ятканда, ниндидер низагы чыккандыр, анысын белмим, безнең авыл халкы мариларны куа. Мариларның өйләрен дә яндыралар, кайберләрен үзләрен дә яндыралар. Ул вакытта безнең авыл Ташлынур исемле була. Әти, Сабиров Салих (1900 елгы), гражданнар сугышы булганда адресны Мемсенский волость, село Ташлинур дип язалар иде, дип сөйләде. Совет власте урнашкач кына Шурага әйләнә. Ә марилар яшәгән авыл Кременский исемле була. Шулай булса да, татарлар марилар белән аралаша.

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән*
*язып алынды*

### *Мәмсә авылының килеп чыгышы тарихы*

Мәмсә авылының килеп чыгышы 1650 елларга килеп тоташа. Тугыз уллы Исәнкол дигән кеше буш урын эзләп бу якларга килеп чыга. Бу урын тоташы белән урман булган. Башта ул иске Кенәр дигән авылга килеп төшә. Яши бара улларын җир эзләргә җибәрә. Һәм алар менә елга буендагы бер аланлыкка килеп урнашалар. Һәм беренче булып Нәүкше һәм Байчура дигән кеше була. Нәүкше елганың бер ягына, Байчура дигән кеше елганың икенче ягына урнаша. Өй салып яши башлыйлар. Нәүкшеләрне марилар дип атыйлар. Нәүкшене башта «Үкше» дип атаганнар, русча «Починок Окше» дигәннәр. Байчуралар татарлар булган, һәм аларны русча «Байчуринский Починок» дип йөрткәннәр. Шулай итеп мари белән татар бергә яши башлаганнар. Ә инде XVII гасыр ахырында Мәмсә елгасының исеме белән безнең авыл атала башлый. Мариларда да «мәмсә» исемле елга бар икән.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

### *Байкал авылының килеп чыгышы тарихы*

Моннан күп еллар элек безнең авыл урнашкан урын тоташ урман белән уратып алынган булган. Иске Тазлар авылыннан (хәзерге Ташчишмә авылы) 4 хуҗалык, су чыганагы эзләп Шурабаш авылы башыннан ага торган Ломба елгасы буйлап киләләр һәм суның авылга борылган җирендә, урманны кисеп, йорт салалар һәм шунда яши башлыйлар. Бу урманда аюлар бик күп булган. Кешеләргә гел җәбер салып торганнар. Менә шушы Ломба елгасының борылышына салынган авыл Ломба куагы авылы дип атала башлый. Авылда 40 лап йорт булгач, янгын чыгып, барлык йортлар янып бетә. Шул вакытта урман да яна. Ул вакыттан соң яңа йортлар салынган 2 урам хасыйл була. Һәм Яңа Тазлар дип атала башлый. Авылның ике урамы уртасында елга ага. Бу су, авылны чыккач болыннарга җәелеп, урман кырыена кадәр барып җитә. Суга ике тегермән салына. Югарының тегермәне – Бәдри, баш тегермәне (түбәндәгесе) – Габделвәли тегермәне дип атала. Бу суга ел саен яз көне аккошлар килә торган булган. Җәй көне бала чыгарып көз көне китә торган булганнар. Балык та бик күп булган бу суда. 1921 ачлык елда балык авыл кешеләренең төп туклану азыгы булып саналган. Бу су искиткеч матур булган. Анда кешеләр көймәләр белән йөргәннәр. Аны Себердәге Байкал күленә ошатып авылны да Байкал дип атыйлар.

*Байкал авылында Гыйниятуллина Мәдинә*
*Вафа кызыннан (1940 елгы) һәм Гыйниятуллин*
*Сөнгатулла Гыйниятулла улыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

## Бәетләр

### *Орый кызлары бәете*

1817 елны безнең авылны су баскан.

Орый шәһәрен су алды унҗиденче елларда,
Маллар да агып китте рас икенде[1] вакытында
Орый шәһәрен су алды унҗиденче елларда.

[1] Икенде – намаз вакыты

Габдулхаик мулланың маллары һич калмады,
Мулла хатыны абыстай үлек булып та табылмады...

*Яңа Оры авылында*
*Мөхәммәтшин Бари Фәзи улыннан*
*(1938 елгы) язып алынды*

### ***Сөембикә манарасына багышланган бәет***

*(«Бардым күлгә, салдым кармак» көенә җырлана)*

Чын хурлыкта торсаң да син,
Мең ел буена Казан,
Нурлы бәйрәмнең көнендә
Хан мәчете төбендә.
Шанлы татар ханнарының
Сөякләре өстендә.

Сөембикә, ач пәрдәңне,
Кара монда бер балкып.
Дошманнарның кулларыннан
Алдык сине без тартып.
Шанлы татар ханнарының
Сөякләре өстендә.

Сөембикә, манараңда
Әйт әле бүген азан.
Нурлы бәйрәм көннәрендә
Хан мәчете төбендә.
Шанлы татар ханнарының,
Сөякләре өстендә.

Һәр бинада биек булып,
Күкләргә җитсен башың.
Әй, манара, кайтты бүген,
Иске нәүбәтең кире.
Нурлы бәйрәм көннәрендә
Хан мәчете төбендә.
Шанлы татар ханнарың
Сөякләре өстендә.

Әй, манара, шатлан бүген,
Шатлана торган көнең.
Нурлы бәйрәм көннәрендә
Хан мәчете төбендә.
Шанлы татар ханнарың
Сөякләре өстендә.

***Дога кылам .....***

Иртән чыккан кояшка,
Барысына дога кылам
Алдагы сандугачка.
Дога кылам мин балама,
Оныкларга, туганга.
Рәхмәт әйтәм Ходаема,
Рәхмәт җиргә туганга.
Дога кылам бар җиһанга
Дуслар, күрше, күргәнгә.
Дога кылам ятимнәргә,
Зур хәсрәтләр күргәнгә.
Догам барып ирешсен дип,
Телим барлык кешегә.
Аерылганнан сына кеше
Хакыннардан эченә.
Күңелләр китек булмасын,
Ходай бирсен бәрәкәт,
Юлларда исән йөрсеннәр,
Күрмәсеннәр хәрәкәт.

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән*
*язып алынды*

**Чишмәләр, әүлия чишмәләре**

Юл кырыенда Нигъмәтҗан чишмәсе бар. Тау башында бик бай сәүдәгәр булган. Анда аның пекарнясы булган, ди. Шул пекарня янында аның коесы булган. Ул коедан кешеләргә су алырга

рөхсәт итмәгәннәр. Шул тауның астыннан чишмә челтерәп чыга башлагач, халык шуны казып, чистартып, шуннан су ала башлаганнар. Нигъмәтҗат исемле бер кеше шунда килеп төпләнгән. Һәм аңа атап ошбу чишмәне атаганнар.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

* * *

Безнең авылыбызда әүлия чишмәсе белән әүлия кабере бар. Кабере югары тау башында урнашкан. Анысында агач утыртылган. Ә чишмәсе түбәндәрәк. Анысына зәңгәрдән буялган рәшәткә куелган. Әүлия каберенә изге кеше күмелгән. Ул күмелгәннән соң бераздан әүлия чишмәсе чыккан. Ул изге суны эчсәң, тазарасың, файдасы була.

* * *

Авылның арткы ягында Зәрә тавы бар. Анда изгеләр чишмәсе бар. Анда акча салып, дәваларга таң суы алганнар. Шул тау астында болында яфрак бәйрәме уздырганнар.

*Пүчинкә-Поник авылында*
*Әпсәләмов Шәриф Шәйхулла*
*улыннан (1938 елгы) язып алынды*

## Кирәмәт

Кирәмәт бар. Аннан болыт чыкса хәвефле була ул. Карале, кирәмәт ягыннан болыт чыкты, дип әйткәннәр. Безне үзебезне шул кирәмәттән чыгып яшен сукты. Бер нәрсәбез калмады. Шул вакыттан хәерчеләндек без. Ул көнне өч йорт янды. Ана, карале, кирәмәттән болыт чыкты, хәвеф-хәтәр китермәсен, – дип әйтәләр иде.

Кирәмәттән чыккан болыт – хәтәр болыт дигәннәр.

*Ташкичү авылында*
*Нәҗипова Илсөярдән (1943 елгы)*
*язып алынды*

## Зират рәнҗеше

Элек авылда арлар (удмуртлар) гына түгел, чирмешләр (марилар) да яшәгән. Моны табигать объекты булып калган Кирәмәт елгасы гына түгел, ә бәлки Мөрәле як зират турысында, юлның икенче ягында безнең заманга кадәр сакланган чирмеш зираты калдыклары да дәлилли. 1942 елда зират агачларын кистереп Озын Сәлахи Мөреледә күпер салдыра. Шул вакытта субай сукканда бер кеше егылып төшеп үлә. Зират рәнҗеше, дигән халык (Хаҗирә апа сөйләгәннәрдән).

*Сеҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

## Җеннәр, ияләр турында

Мин 7 нче класста укыйдыр идем. Безнең авыл башында бер әби тора иде. Аның кызы, кызының кызы бар иде. Ул минем иптәп кызым, тугызда укый иде. Аның апасы Арчага китте дә, бу кыз мине кунарга чакырды. Минем әни андыйга бик коры иде. Мин әнигә – бер кыз, биш балага бер кыз идем. Әни мине меңгезмәде. Ялына, ялына, тик соңгысы булыр дип җибәрде мине. Баштарак капка төбендә утырдык. Өйләрендә мич арасы, морҗа, бер сәке дә бер өстәләре бар иде. Башка әйбер юк. Бик ярлы кешеләр иде алар, әтиләре сугышта үлгән. Ул көнне яңгыр килде. Әнисе урын җәеп, безне йокларга салды. Миңа мич арасы күренеп тора иде. Мин иң кырыйда, уртада иптәш кызым, аның янында әнисе ятты. Берзаман дөбердәгән, яшен яшьнәгән тавышка уянып киттем. Күзем мич арасына төште. Мич арасында 3 хатын басып тора. Кап-кара күлмәкләр кигәннәр, кулларын чорып, аннан ут янып тора. Мин бик каты курыктым. Миңа гына тимәсәләр ярар иде дип, иптәш кызыма да кагылырга куркып ятам. Шуннан курка-курка юрган астына кереп яттым. Куркып йокыга киткәнмен. Йокыдан торгач теге әби миннән сорады: «Кызым, әйбәт кенә йокладыңмы?» дип. Мин: «Бик куркыныч әйбәр күрдем сездә. Нинди кешеләр бар соң сездә?» – дидем. Әби: «Кемнәрне күрдең соң син?» – ди. Мин: «Озын кара

күлмәкләр кигән, өчесенең кулында әллә нинди ут та бар иде», – дидем. Шуннан теге әби әйтә: «Эх, – диде, – чит кеше килгәч килмәсләр дип уйлаган идем, тәки килгәннәр икән», – диде. Шуннан соң теге кыз авырый башлады. Башта бер кулы калтырап йөри башлады, аннан ике кулы калтырый башлады, аннары аяклары, бөтен гәүдәсе калтырый башлады. Авыл халкы: «Кызга җен суккан, җен ияләшкән», дип йөри иделәр.

* * *

1970 елларда Ташкичү дигән авылга кунакка бардык. Ул авылга бара торган тегермән аркылы туры юл бар. Төнге 12 нче яртыларда кайтырга чыктык. Әйдә, мин әйтәм, кыска юлдан, тегермән аркылы кайтыйк дидем. Килеп җиттек. Анда елга аркылы чыгарга баскыч бар, шул баскычтан чыгарга кирәк. Килеп җиттек, бернинди баскыч та юк. Сплошной яр гына. Болайга барабыз – биек яр, икенче якка барабыз – биек яр. Бисмиллаларны әйтеп карыйбыз, Ходайга ялварып карыйбыз: «Ходаем, чыгар безне», дип. Шул тирәдә төнге берләргә кадәр йөредек чыга алмыйча. Җәй көне кояш иртә чыга бит инде. Әтәчләр кычкыра башлагач, теге мираж югалды. Олыларга сөйләгән идек. Алар безгә: «И, адаштыра торган җир бит ул. Анда кыш көннәрендә дә кешеләр адашып үлгән булды», – диделәр.

* * *

Бездән бер йорт аркылы Капитан исемле ялгыз гына бер карт яшәгән. Әти әйтә иде, Капитанга җен ияләнгән, дип. Без авыл халкы җыелышып шунда барабыз, ди. Бардык та, кереп утырдык, ди. Шуннан бу карт тора-тора да, безгә мич артыннан таш ыргыта башлады, ди. Шуннан, без дә шул ташны төенчеккә төядек тә, шул мич арасына ыргыттык, ди. Барып карыйбыз, мич арасында бер нәрсә дә юк, ди. Бераздан, кулъяулыкка төргән ташны атты, ди безгә. Әти әйтә торган иде безгә: «Уйнамагыз ул тирәдә, җенле, саташтыра торган җир ул» дип.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

### *Кара мунча*

Элек мунчалар бик сирәк булган. Бөтен авылга берничә генә кара мунча. Бет белән дә көрәшергә мунча кирәк. Ул сирәк кенә булган кара мунчаларны, безгә дә эләгер дигән өметтән, күршеколан яга торган була. Элеккесенә, әлбәттә, хуҗалар үзләре керә, ә калган мунчага – ягучы, аның балалары керә. Ул кара мунчага керә дә, яга да белү кирәк була әле. Бари абыйларның мунчасына күрше Рузикамал тәтә карчык анасын – Хубҗамал әбине кертә дә, син юына тор, үзем кереп алырмын, – дип чыгып китә. Рузикамал апа бер кереп карый, ике кереп карый – карчык һаман бер урында тик утыра. «Тизрәк юын инде», – дип ул тагы чыгып китә. Баксаң, әби үлгән. Ул турыда авылда ниләр генә сөйләмәделәр инде – ләүкә астына төшеп киткән булган, аннан үзен мунча пәриләре тартып чыгарганнар да, скәмьягә утыртып куйганнар имеш.

*Сежәе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

* * *

Бер кыз белән Хәтнә авылына ике ат белән кишер илтергә бардык. Аннан соң кишерне төяп, сдавать иткәнче төн булды. Төнлә булса, шул уникеләр булган иде. Безнең ат артыннан ут янып килде. Зират янына җиткәч, беребез алга, беребез артка чыгып шулай кайттык. Аннан зират янындагы елгага җиткәч, теге шар югалды. Безгә әйтәләр иде, шул шар арбага утырса, үтерә иде сезне, дип. Аны олылар «җен» диләр иде.

*Сәрдәбаш авылында*
*Рябинина Елизавета Осиповнадан*
*(1926 елгы) язып алынды*

* * *

Җиде ел элек шундый кызык хәл булды. Без, урам яшьләре кич белән клубка чыга идек. Бик соң түгел иде, 11 тирәсе, ул вакыт әле караңгы булмый. Апаз авылының зираты өстендә бик зуур тәлинкә формасында яктыртып оча торган бер объект

күрдек. НЛО булгандырмы, нәрсә булгандыр, шул әйбер, зират ерак булса да, бик якын күренде безгә. Аның тәрәзәләре бик күп иде. Бер биш-алты минут булгандыр. Нәкъ сөйләгәндәге шикелле күрдек без аны. Бер 5 минут ул шулай һавада очып торды. Аннан утлары кисәк кенә сүнеп юкка чыкты.

* * *

Көз көне без бер төркем студентларны Иске Ашыт авылына бәрәңге җыярга җибәрделәр. Кичке сәгать тугыз белән ун арасында, безне – ике кызны капчыклар җыярга чыгардылар. Ерак түгел генә аланда бер күренеш күрдек. Анда без сугышка тап булдык. Кызыл ут белән гаскәрләр сугышкан эпизодын күреп алдык. Ул күренеш тиз генә булып алды. Ничек барлыкка килде, шулай юкка да чыкты.

*Синичкина Ирина*
*Марсель кызыннан (1989 елгы)*
*язып алынды*

### ***Хозер Ильяс***

Ак сакаллы карт йортка су сорап кергән. Тегеләр су бирмәгән. Аннан карт: «Туйганчы суга газап булыгыз», дип чыгып киткән. Чыгып китүгә болыт чыгып, бик көчле яңгыр явып, алар торган урамны агыза. Мулланың йорты су буенда урнашкан. Габделхаик дигән мулланың өч кызы булган. Хатыны, кызлары, маллары агып киткән. Биек тау буенда мәчет урнашкан була. Мулла үзе шунда була. Мәетләрне табып, Кызыл Яр авылын чыккач, бер тау кырыенда күмгәннәр. Шуларны зират итеп ясадылар һәм бүгенге көндә дә урыны сакланган.

*Яңа Оры авылында*
*Мөхәммәтшин Бари Фәзи улыннан*
*(1938 елгы) язып алынды*

* * *

Без гаиләдә алты бала үстек. 5 малай, 1 кыз. 1963 елның ахыры иде. Ул көнне эти малайлар белән су буенча чыбык-чабык

җыярга, ә әни, бакчада эшлисе эшләрем бар, дип, мәктәпкә китеп барды. Өйдә мин үзем генә калдым. Кеше юклыгына файдаланып, тиз-тиз генә идән-сәкеләрне юып чыгардым. 6 классны тәмамлагач әнинең бердәнбер булышчысы буларак өй эшләрен бик яратып башкара идем. Ишек алдына тамчы суына куелган мичкәдән бер чиләк су алып, идән юа торган мунчалачүпрәкләрне кагып бетердем. Өс-башымны алыштырдым. Күлмәк итәкләрен ыштан балагына кыстырып, эшкә керештем. Тезләнеп мунчала белән идәнне яхшылап ышкыйм, аннан соң чүпрәк белән хәсиятләп сөртәм. Ишек төбенә җитәргә 2 генә сайгак калды. Кинәт ишек ачылып китте. Аннан ап-ак күлмәкыштан кигән, иңбашына ак киндердән юл букчасы аскан, башына ак түбәтәй кигән ап-ак сакаллы бер бабай килеп керде. Һәм, Әссәләмәгаләйкүм, дип, сәлам бирде. Мин кулыма идән чүпрәге тоткан көе тораташтай катып басып торам. Көч-хәл белән генә телемне әйләндереп авыз эченнән: Сәлам, бабай, дип эндәштем. Нигәдер, шүрләп калдым. Өйдә беркем дә юк бит. Алай куркак түгел дә инде мин, 5 малай арасында үскәч. Кызым, йортыгызга дога укып чыгарга буламы, диде бабай. Мин, дога сүзе ишеткәч, кыюланып киттем. Укы бабай, укы, дип, кулымдагы чүпрәкне ташлап, күлмәк-итәкләремне төзәтеп, бабайга утырырга урындык китереп бирдем. Ул керпәсез иде. Тиз генә урындыкка керпә киез яптым. Рәхмәт кызым, дип, бабай укырга тотынды. Ул укыган чакта, күзләрем белән бабайны күзәтәм. Аның карашын тотарга тырышам. Ләкин ул әллә нинди серле, күзләре йомык, авызы гына ачылып ала да тагын йомып куя. Аннары әби-бабайларга дога кыла башлады. Тик дога укыганнан соң, хәергә нәрсә бирергә соң. Акча да юк. Шул чак әнинең кичә генә пешкән икмәге искә төште. Бабай, бездә акча юк, ипи бирсәм ярыймы? дип сорадым. Тиз генә икмәкнең яртысын сындырып бирдем. Бабай: – И, кызым, бу дөньяда икмәктән дә зур нигъмәт юк, бу иң зур, иң кыйммәтле бүләк, – диде. Бик рәхмәт, бәхетле бала булырсың, гомерең буе муллыкта, байлыкта яшәрсең. Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген онытма! Син Аллаһының бу йортка сөелеп яшәүче бердәнбер кызы. Әтиәниеңә, туганнарыңа, кешеләргә игелекле булырсың Аллаһа

боерса, диде дә ишеккә юнәлде. Рәхмәтемне әйтеп өлгермәдем, ничек тиз керде, шулай тиз чыгып китте. Артыннан чыктым, ләкин бабай юк иде инде. Менә әни эштән кайтып җитте. Аңа бу вакыйганы бәйнә-бәйнә сөйләдем. Әни куркып: «Кызым, андый-мондый начар сүзләр әйтмәдеңме», – дип сорады. Юк инде, юк, дога кылгач, әнә, икмәгеңне кисеп бирдем. Әни мине кочып алды. «Рәхмәт кызым, бу сәер кеше – Хөзыр Ильяс булгандыр. Абыстай әбиең сөйләве буенча, ул шулай өйләргә кереп йөри икән. Ләкин бик сирәк кешегә генә күренә», – ди.

* * *

Бер хатын сөйләде. Урманга гөмбәгә баргач мин адаштым,. ди. Йөрим, йөрим, елап беттем, ди. Шуннан бер агач артыннан миңа бер бабай карап тора ди. Ап-ак киемнән, ди, түбәтәе дә ак, ди. Мин курыктым, ди. Нәрсә икән дип, ди. Янымарак килде дә, ди. «Кызым, елама, мин сиңа кайтыр юлыңны күрсәтәм», – диде, ди. Һәм миңа, бу якка бар дип, юл күрсәтте, ди.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

## Әкиятләр

### *Әкиятче Вәли бабайдан ишетелгән әкият*

### *Козгын*

Урманда бер усал, явыз хатын балалары белән яшәгән, ди. Төн җиткәч бу хатын козгынга әйләнә икән. Төнлә бу козгын кош-кортларны, куяннарны, төлкеләрне тотып, балаларына ашарга алып кайта икән. Аннан кире кешегә әйләнгән.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

* * *

Бер матур кыз булган. Бер егет моңа бик кызыккан. Бу кызга көнләшүчеләр күп булган. Шуннан соң, егет белән кыз бергә

кавышмасын дип, кызга сихерле ризык ашаталар. Кыз үлә, егет бик кайгыра. Ничек кенә коткарыйм икән, ничек кенә терелтим икән дип, егет уйлана. Аннан егет, ерак авылда торган бер әбигә бара. «Әби, җаным, минем яраткан кызым үлде бит, ничек кенә мин аны терелтим, мин бит аннан башка тора алмыйм», ди. Шуннан әби егеткә шифалы су әзерләп бирә. Шул суны кызның битенә өч тапкыр дога әйтеп сип, ди. Әби егеткә дога өйрәтә. Шулай егет эшли дә. Кызның битенә сибә. Кыз күзен ачып җибәрә. Шуннан соң бу кыз терелә. Әлегә кадәр егет белән кыз шул авылда бер-берсен яратып торалар, ди.

* * *

Җиде бертуган ир егет булган, ди. Бер кыз җиләккә урманга барган була. Җыйган-җыйган да, арып, урман эчендә булган бер йортка керергә була. Өй бик пычрак була. Кыз өйне җыештыра, чәй куя. Шуннан соң йоклап алыйм дип, йокыга китә. Шул вакыт җиде ага кайтып керә бу йортка. Аптырыйлар өйнең пөхтәлегенә. Кыздан сорыйлар, син кем буласың, дип. Кыз: «Минем исемем Зөһрә була, – ди. – Мин адашып бу йортка кердем, – ди. – Сез мине гафу итегез, ачуланмагыз», ди. Егетләр: «Син безгә сеңел булырсың», – диләр. Шулай итеп, кыз бу егетләр белән тора башлый.

*Гыйләҗетдинова Махру (1916 елгы) сөйләгән әкият.*
*Гайфуллина Рәмзия Гыйльмулла*
*кызыннан (1968 елгы) язып алынды*

## Такмаклар

Җәйге кичләрдә клубка керергә «яше җитмәгән» яшь-җилбәзәк уенга төшә. Алар кичке уенда бер-берсенә шаян такмаклар әйтешә, беренче мәхәббәт чаткылары уяна, беренче «свиданиеләр» башлана. Шул такмакларның берничәсе:

Җәйнең эссе көннәрендә
Печән таратасыңмы?
Фәлән сине бик ярата,
Син дә яратасыңмы?

* * *

Капка астыннан таяк тыгып,
Этемне ырылдатмагыз,
Юклы-барлы җырлар белән
Күңелемне болгатмагыз.

* * *

Кызыл алма, теш камаша,
Кызыл алма ашама.
Бөтен авыл кызларыннан
Винегрет ясама.

*Сеҗе авылында*
*Камалиева Ләлә Разак кызыннан*
*(1941 елгы) язып алынды*

* * *

Киттем бардым Әтнәгә,
Җан тәрәзә какмага.
Кактым, суктым,
Тәңкәләре чәчелде.

Эте чыкты өрмәгә,
Кызы чыкты күрмәгә.
Этен алдым пычакка,
Кызын алдым кочакка.

* * *

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,
Боты озынга күрә.
Без кызларны яратабыз,
Бите кызылга күрә.

* * *

Йөгерә үрдәк, йөгерә каз,
Кала эзеннән тамга.
Үтә матурларны сайлап,
Урта матурдан калма.

* * *

Яз да була, көз дә була,
Су өсләре боз була.
Ике егет бергә килсә,
Сөйләшкәне кыз була.

* * *

Яз да була, көз дә була,
Җил дә, буран да була.
Яшь вакытта кемне сөйсәң,
Күңелең шуңарда була.

* * *

Ах, миленький,
Кызларның душасы,
Яучыларга кемне кушасы...

* * *

Чылтырап аккан ай чишмәнең
Аслары ла дәрья булмасын.
Сөям-сөям, диеп син әйтәсең,
Сөюләрең хәйлә булмасын.

* * *

Бөгелә каен, бөгелә каен,
Матур бөгелмәсә дә,
Синең өчен өзеләм, бәгърем,
Сиңа сизелмәсә дә.

* * *

Су буена төшкән идем,
Су өсте күбек кенә;
Син бит минем якын дустым,
Күз нурым кебек кенә.

* * *

Агып китте, агып китте
Яулыгым кар суына шул,
Ах, җаныем, чыдый алмыйм
Йөрәгем ярсуына.

* * *

Атларыбыз, атларыбыз,
Канатлы чакларыбыз.
Безнең дә бер булыр микән
Киленле чакларыбыз.

* * *

Яшь киленнәр судан кайта
Чулпыларын чыңлатып;
Яшь егетләр карап кала
Ут күзләрен уйнатып.

* * *

Кулымдагы балдагымның
Исеме Габделбарый.
Уйнамагач та, көлмәгәч
Бу дөнья нигә ярый.

* * *

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр чикләвек;
Сөйли безне сөймәгәннәр,
Үзенә тимәгәннәр.

* * *

Каз канатларын җыярга
Төштем су буйларына;
Су буйларында йөргәндә
Син генә уйларымда.

* * *

Ах, душа мой, душа мой,
Билдә каеш бушамый.
Иртүк торып суга барам,
Камыр басам, икмәк салам
Кай җирләрем ошамый.

### *Түгәрәк уенында әйтелә торган такмаклар*

Суга салсаң су күтәрелми
Бер мискал тимерләрне;
Эзләсәк тә табалмабыз
Узган яшь гомерләрне

*Кушымта:*

Үзләренең коесы бар,
Безгә килеп су ала;
Безгә килеп су ала да
Көлә-көлә югала.

Әй, йолдызым, йолдызым,
Гармуныңны тартып уйна
Җиңел булсын җырларга;
Безнең җырлар таралсыннар
Арчаларга, кырларга.

*Кушымта:* шул ук.

Тәрәз ачып җимнәр сиптем,
Ашагыз кошкайларым,
Кайгы-хәсрәтләр күрмичә
Яшәгез, дускайларым!

*Кушымта*: шул ук.

Әй, яшь чагым, яшь чагым,
Яшь чагым, җүләр чагым;
Шул яшь чагым, җүләр чагым
Әйләнсә икән тагын.

*Кушымта*: шул ук.

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән*
*язып алынды*

* * *

Аклы ситца күлмәгеңне
Әллә сабынладыңмы?
Карашың салкын тоела,
Әллә сагынмадыңмы?

* * *

Аклы ситца күлмәк тектем,
Әнә булмады ише.
Көнчелек башка җитә ул,
Көнче булмасын кеше.

* * *

Аклы күлмәгең кигәнсең,
Билләреңне бугансың.
Бигрәк моңсу күренәсең,
Ай туганда тугансың.

* * *

Ике түгел, өч кенә,
Сандугач дип хурламагыз,
Сандугач та кечкенә.

* * *

Милиция мени ул,
Сине сөя, мине сөя,
Белеп сөя мени ул.

* * *

Чәчең озын билеңнән,
Чәчләре озын биленнән,
Чыгармаслар илеңнән.

* * *

Нигә кыек торасың,
Кыек торуларың белән
Безне боектырасың.
Аллария, лария,
Lариялә, лария.

* * *

Тәрәзә наличнигы,
Менә шушы була инде,
Кунак кыз барышнигы.

* * *

Уйнат, уйнат гармуныңны,
Биесеннәр егетләр.
Безнең илнең егетләре,
Бар да бөркет кебекләр.
Эх, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

* * *

Зәлилә булсаң иде,
Әйләнеп торсаң иде;
Зәлилә кебек уртада
Әйләнеп торсаң иде.

* * *

Зәлилә булып була,
Әйләнеп торып була;
Ярны сөйсәң, сөеп туйма,
Сөйми дә торып була.

* * *

Әйләнә лә Зәлилә,
Гөлләләрем Зәлилә,
Миләүшәләр серләшәләр,
Серләшик әле бездә.

*Яңа Оры авылында*
*Мөхәммәтшин Бари Фәзи улыннан*
*(1938 елгы) язып алынды*

## ***Туй барганда әйтелә торган такмаклар***

Туганнарым, сезгәниләр бирим,
Бөхәрләрдән килгән малым юк.
Җаным җарып бирер идем,
Җаннан башка торыр хәлем юк.

* * *

Туганнарым, килдегез,
Исәнләшә белдегез.
Мәкнең алсу чәчәге кебек,
Күзләргә күрендегез.

* * *

Туганнарым, сезгә теләгем шул,
Башыгыз михнәт күрмәсен.
Йөзегездә таң кояшы,
Балкып торсын, сүнмәсен.

* * *

Ничек килдегез сез безгә,
Төшмәенчә диңгезгә.
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт итим сезгә.

* * *

Әй туганнар, туганнар,
Туганнар бездән туйганнар.
Туганнар бездән туйсалар да,
Бик зур өлеш куйганнар.

* * *

Дускаем, матур буласың
Чәчеңне тарыйсың да.
Беренче булып яшисең,
СССР тарихында.

* * *

Виноград пешкән диләр,
Җыеп өләшер идем.
Бик сагынган көннәремдә
Күреп кочаклар идем.

* * *

Автомобиль урман чыга,
Төн караңгы булса да.
Аерылганда еламадым,
Күңелләрем тулса да.

*Сәрдәбаш авылында*
*Рябинина Елизавета Осиповнадан*
*(1926 елгы) язып алынды.*

## Җырлар

### *Герман көенә җырлана торган җырлар*

Айлар биек, айлар биек,
Айга менәсем килә;
Айга менеп түбән карап
Сезне күрәсем килә.
Айга менеп түбән карап
Сезне күрәсем килә.

* * *

Әйтим әле, әйтим әле
Әйтим әле икене;
Ник әйтмәскә мин икене,
Сез, дусларым, сөйкемле.
Ник әйтмәскә мин икене,
Сез, дусларым, сөйкемле.

* * *

Әйтим әле, әйтим әле,
Әйтим әле, өч булсын,
Өч тә булсын, дүрт тә булсын,
Сезнең күңелләр булсын.
Өч тә булсын, дүрт тә булсын,
Сезнең күңелләр булсын.

* * *

Әйтим әле, әйтим әле,
Әйтим әле уннарны;
Сахраларга чыгып чәчәм,
Башымдагы моңнарны.
Сахраларга чыгып чәчәм,
Башымдагы моңнарны.

* * *

Агыйдел буйлары ямьле,
Балыклар уйнаганга.
Нурлы йөзләрем саргайды,
Гел сезне уйлаганга.
Нурлы йөзләрем саргайды,
Гел сезне уйлаганга.

* * *

Гармуннар уйный белмибез,
Өйрәнербез уйнасак.

Мал тапмаслык егет түгел,
Яр табарбыз уйласак.
Мал тапмаслык егет түгел,
Яр табарбыз уйласак.

* * *

Тальянында якты йолдыз,
Айга сөйли серләрен.
Ул айга сөйли серләрен,
Мин кемнәргә сөйләем.
Ул айга сөйли серләрен,
Мин кемнәргә сөйләем.

* * *

Ай янында якты йолдыз,
Минем йолдызым гына.
Таң алдыннан ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.
Таң алдыннан ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.

* * *

Тальянский гармуннарның
Басмый телләр ачылмый.
Безнең йөрәкләр яшерәк,
Бер җырламый басылмый.
Безнең йөрәкләр яшерәк,
Бер җырламый басылмый.

* * *

Әйтим әле, әйтим әле,
Әйтим әле алтыны.
Ник әйтмәскә мин алтыны,
Безгә бүген ял көне.
Ник әйтмәскә мин алтыны,
Безгә бүген ял көне.

* * *

Китәм, бәгърем, китәм, бәгърем
Китәм, бәгърем, үзбәккә.
Китәм мин, бәгърем, үзбәккә,
Табалмассыз эзләп тә.
Китәм мин, бәгърем, үзбәккә,
Табалмассыз эзләп тә.

### ***Чыпта сугу җыры***

Сук, сук, ныграк сук,
Идәннәргә җәярбез.
Кибетләргә сатин килгән
Сатин күлмәк киярбез.

Сук, сук, ныграк сук,
Кылычыңны жәлләмә!
Кайсыбыз алдан туйларбыз –
Синме әллә, мин мәллә?

Суз, суз, тизрәк суз,
Аркавын да, буен да.
Читлеген дә бөтер тизрәк –
Чыгасы бар уенга!

Сук, сук, ныграк сук
Калагыңны жәлләмә
Кайсыбыз алдан туйларбыз
Синме әллә, минме әллә?

### ***Наза җырлары***

Аклы бәйлә, аклыны ки,
Аклы яулык килешә.
Аклы яулык бәйләгән кыз
Теләгенә ирешә.

*Кушымта:*
Алсу алма, кура җиләк, чияләр
Синең өчен яналар да көяләр.

Бигрәк матур була икән
Аклы яулык бәйләсәң.
Сокланмаган кеше калмый
Чыгып урам әйләнсәң.

*Кушымта:* шул ук

Башымдагы яулыгымның
Түбәләре түгәрәк
Син икәнсең бакчаларда
Гөлгә кунган күбәләк.

*Кушымта:* шул ук

Билең нечкә, буең зифа
Тал кебек бөгеләсең;
Таллар кебек бөгеләсең
Кем өчен өзеләсең?

*Кушымта:* шул ук

### *Бишек җыры*

Улым (кызым) мендәрдә ята,
Сине әнкәң йоклата...
Синең белән без икәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү!...

Йокла, балам, йом күзең
Син күз нурым, йолдызым!
Йоклый кошлар – арыганнар,
Йоклый кырлар, урманнар ...

Тизрәк үсеп каласы –
Йоклый куян баласы,
Йоклый бүре баласы,
Йоклый аю баласы,
Йоклый үрдәк бәбкәсе,
Йоклый әнкә-эткәсе...

Йокласын дип песиләр
Йоклый тычкан, күселәр...
Балыкларны тирбәтеп,
Әкрен генә су ага...
Тәрәзәгә җил кага.
Улым (кызым) йокыга тала...

### *Ямьле Шурам җыры*

Чишмәләре чылтырап ага,
Безнең ямьле Шураның,
Авылымны яратам мин,
Кышкы салкын буранын.

*Кушымта:*
Бигрәк ямьле безнең Шура,
Матур җәйге кичләре;
Бик яратам авылымны,
Саф сулы һәм чишмәле.

Бөтен җирдә урман, кырлар,
Һавалары ни тора.
Шәһәр кешеләре хәтта,
Шурада гаилә кора.

*Кушымта:* шул ук

Шурамны сагынып кайтам,
Кая гына барсам да.
Туган җирем онытылмый,
Ни рәхәттә торсаң да.

*Кушымта:* шул ук

### *Гомерләр шулай үтә*

Язы үтте, җәе үтте,
Көзе дә килеп җитте.
Кышы да озак көттерми,
Ап-ак карларын сипте.

Гомерләр уза су кебек,
Һаман без картаябыз.
Үткән гомерне сагынып,
Әкренләп саргаябыз.

Һаман яшьлеккә бармыйбыз.
Без картая барабыз.
Үләр вакыт та җитә дип,
Без кайгырып торабыз.

Үтте дә китте бит гомер,
Яшәмәгән дә кебек.
Без дә ятырбыз берзаман,
Җир асларына кереп.

Нәрсәләр җавап берербез,
Кеше гөнаһсыз түгел.
Кадерен белик яшәүнең,
Яшибез әле бүген.

Һаман нидер җитми безгә,
Һаман дөнья куабыз.
Бер рәхәт тә күрмибез без,
Ни өчен без туабыз.

Үлгәндә иман яңартып,
Үләргә язсын безгә.
Үлмәгез әле, яшәгез,
Тик бәхет телим сезгә!

### *Су юлын күрсәтү*

*(«Эх, җаныем, су юлы, бик сагындым бу юлы» көенә җырлана)*

Яшь киленнәргә су юлын
Күрсәтү изге бурыч,
Туры, дөрес юлдан гына,
Килен, йөрергә тырыш!

Ай бизәкле чиләкләрең
Таң суында йөзсеннәр,
Сандугачлар сайрый-сайрый
Уңган килен, дисеннәр.

Мөлдерәмә, тулы булсын,
Һәрвакытта чиләгең.
Зур бәхеткә ирешерсең
Кабул булыр теләгең.

### *Без Шура әбиләре*

Без – әбиләр биибез дә, җырлыйбыз!
Безнең кебекләр бар соң кайда?
Без – әбиләр барын булдырабыз,
Безнең кебекләр юк бер кайда.

Без җырласак, кошлар тынып тора,
Без биесәк, бар да бии!
Җырлап-биеп яшәгәнгә күрә
Йөрибез картаю белми.

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән*
*язып алынды*

### Табышмаклар

Башы бар, мие юк
Корсагы бар, эчәгесе юк.
Койрыгы бар, җоны юк *(чабата).*

* * *

Дүрт терәвеч, бер болгавыч,
Кәкре кубыз, якты йолдыз *(сыер).*

*Пүчинкә-Поник авылында*
*Әпсәләмова Нурия Тимерхан кызыннан (1940 елгы)*
*һәм Әпсәләмов Шәриф Шәйхулла улыннан (1938 елгы)*
*язып алынды*

Аягы юк – йөри,
Теле юк – сөйли *(хат язу).*

* * *

Ике апай су коена:
Берсе чума, берсе күтеп тора
*(чиләк белән су алу).*

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән
язып алынды*

Ыж, ыж аждаһа,
Йөрәгендә уты бар,
Корсагында суы бар,
Түбәсендә күзе бар,
Ярый әле үзе бар *(самовар).*

* * *

Таяк, таяк өстендә табак,
Табак эчендә кибет.
Кибет эчендә мең егет *(көнбагыш).*

*Ташкичү авылында
Насыйбуллина Рузалия Ибраһим кызыннан
(1949 елгы) язып алынды*

## Уеннар

### *Каеш салыш уены*

Егетләрнең каешын аласың да, кызның исемен әйтеп (мәсәлән, Бибинур идәндә ята, дип), теге егеткә сала. Әгәр дә инде Бибинурны яраткан егет булса, шул егет теге каешны ала. Кызлар салганда, егетнең исемен әйтеп сала: мәсәлән: «Сабир идәндә ята», дип. Әгәр дә яратмаган егет булса, теге кыз ята да ята, каешны алучы булмый. Аннан беләсең инде, кем кемне ярата.

### *Шырпы салыш (йөзек салыш) уены*

Тезелешеп утырасын, бер алып баручы була. Ул шулай һәрберсенең кулына кулын тидереп, берсенең кулына шырпы сала. Аннан: «Кемдә шырпы, йөгереп чык», ди. Тегене тотып калырга тырышалар. Тотып кала алмаса, чыга. Аннан чыккан кеше алып баручы була. Чыгып китә алмаса җәза бирәләр.

### *Кәҗә ябыш уены*

Егет белән кызны урындыкка утырталар. Аркаларын берберсенә терәп. Аннан бер, ике, өч дип санагач алар бер-берсенә башларын борырга тиеш. Әгәр икесе дә бер якка караса, болар инде урамга чыгып китеп «кәҗә ябалар», ягъни сөйләшеп, я кочаклашып керәләр. Әгәр дә инде кәҗә ябышта икесе ике якка караса боларга җәза бирелә.

*«Чордашлар» фольклор ансамбленнән*
*язып алынды*

### Мәзәк

Минем кодагыем күрше авылда яши. Исеме Түнти әби була. Кодагые Түнтигә кунакка бара. Ара ерак була. Шуннан әби барып җиткәнче бик сусый инде. Көчкә барып җиткәч инде, чәй эчәргә утыра. Түнти әби самаварын кайнатып, парларын чыгарып, чәй ясап, рәхәтләнеп чәй эчәләр. Түнти әби кодагыен сыйлый инде. Шикәр, бал куя моның алдына. Кодагыйның сусаган булуыннан, Түнти әби чәй ясап тора, кодагый эчә бара икән. Аннан соң кодагый: «Эч инде, кодагый, эч, – ди. – Тагын берне генә эч, менә шикәрен, балын да капкалап утыр. Бал дисәң бер кими, бармак тидерсәң – икенче кими, дип әйткәннәр элеккеләр. Әйдә эч, эч», – дип Түнти әби кодагыйны сыйлый. Хәзер кодагый эчә: «Әй кодагый, бик күпне эчтем бугай, рәхмәт инде. Юк, кодагый, инде өчне эчтем, рәхмәтләр яусын», – ди. Түнти әби: «Пычагым, өчне түгел, бишне эчтең инде, кодагый», – дигән.

*Ташкичү авылында*
*Насыйбуллина Рузалия Ибраһим*
*кызыннан (1949 елгы) язып алынды*

# ЖИВОЙ РОДНИК ТАЛАНТОВ

## Декоративно-прикладное искусство, народные промыслы и материальная культура Арского района

*Марина Газизова*

Целью данной статьи является анализ традиционных видов искусства татар Арского района таких, как: деревянная резьба, вышивка, архитектура, костюм и материальная культура. Были изучены частные коллекции и фонды музеев, проводилось интервью с респондентами.

С давних времен Арский район славится своими мастерами и промыслами. Этот регион был достаточно хорошо исследован в трудах Н.И. Воробьева, Е.П. Бусыгина, Ф.Х. Валеева, П.М. Дульского. Ученые подробно изучили все виды декоративно-прикладного искусства, которые развиты в регионе, а также основные промыслы, которыми традиционно занималось население. На современном этапе обширных исследований не было. Поэтому предоставленный материал – первая попытка изучения данного региона на современном этапе.

Своего пика развитие ремесел в Арске достигло в конце XIX столетия. Еще Н. Воробьев отмечал, что умельцы Арского района проявляют большую искусность и умение при строительстве и украшении домов. «Трудно сказать о причинах появления большого количества орнаментальных деталей именно в Арском кантоне. Есть ли это результат большей зажиточности населения, или это дело вкуса, сказать трудно, хотя татары любого района считают украшения и особенно

окраску домов Арского кантона идеалом, к которому необходимо стремиться»[1].

Здесь были развитые следующие ремесла: обработка дерева и волокна, выделка кожи, производство керамических изделий, мастерицы славились своей вышивкой. Самый известный промысел данного региона – знаменитые татарские сапожки – ичиги, качество и красота которых была известна далеко за пределами Арска. Не случайно, именно здесь в 1970-е годы открыли фабрику по производству национальной обуви.

Как отметил Ф.Х. Валеев: «В сложении и развитии архитектурно-художественного облика жилых домов Заказанья основную роль сыграли традиционные приемы древнего народного зодчества, отдельные проявления татарской городской архитектуры Казани первой половины XVI века и русской архитектуры конца XVIII – начала XIX веков. В облике сельских построек Заказанья устойчиво сохраняются многие архитектурные формы прошлого. Большое значение в художественно-образном решении деревянного жилищ, кроме архитектурных форм и цветовой раскраски, придавалось резному декору»[2]. Сегодня, типичная застройка Арского района – это одно-двух этажные дома, чаще всего деревянные с декорированными наличниками и воротами. Окрас самого фасада, как правило, полихромный: синий, зеленый, желтый. Кирпичных домов тоже достаточно много, украшены они также ярко, присутствует резьба на наличниках, фасадах крыш, некоторые хозяева домов выкладывают узоры из разноцветных кирпичей. В своих исследованиях Н.И. Воробьев отмечал, что в Арском районе дома украшаются бревенчатой разноцветной обшивкой. К сожалению, в наши дни больше владельцев обшивают дома сэндвич панелями, заменяют деревянные окна на пластмассовые. Из-за большей долговечности и дешевизны меняют деревянную резьбу на резьбу из металла, которая все больше и больше пользуется спросом.

---

[1] *Воробьев Н.И.* Материальная культура казанских татар. Казань: Изд-во Дома Татарской культуры и Академического центра, 1930. С. 216.

[2] *Валеев Ф.Х.* Народное декоративно-прикладное искусство Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. С. 108.

Если говорить о времени постройки домов, то большую часть составляют жилища, построенные в советский период – 1950–1960-х годов, реже встречаются 1940-х. Образцом, сохранившегося дома 20–30-х годов XX века можно назвать двухэтажную усадьбу, которая находится в деревне Байкал (местные называют его дом Джамалы). Некогда здесь жил зажиточный человек, затем был раскулачен и лишен имущества. Дом отдали властям, в разное время он был жилой, но сейчас заброшен. Наличники выполнены в технике пропильной резьбы, украшены ромбовидным орнаментом. Внутри дома имеется деревянная лестница, украшенная резными колонами, над которыми располагаются перила. Купеческих, искусно орнаментированных зданий конца XIX века осталось немного, самая известная постройка расположена в самом Арске. Это дом по ул. Интернациональная, дом 12, где находится Музей литературы и искусств.

На сегодняшний день также идет активная застройка. Умельцы, украшающие свои дома резьбой, используют как традиционные мотивы в орнаменте, так привносят и свое особое творческое видение и фантазию. Наличник на окнах – это своеобразное условное изображение дома. Верхняя его часть, как правило, самая нарядная, имитирует крышу дома, она богато орнаментирована. Весь периметр наличника также обрамляет ажурная обкладка. По технике изготовления различают два вида резьбы: рельефную, которая является наиболее древней и пропильную или сквозную. Основной мотив рельефной резьбы – это узоры в виде листьев, цветов, изображение птиц, самый распространенный – змееобразные завитки. Пропильная резьба требует меньше время на изготовление узоров. Основы пропильной резьбы составляют геометрические узоры – ромбы, треугольники, сердечкообразные мотивы, круги и полукружия.

Наиболее распространенные орнаменты этого района традиционные: разнообразные цветочные мотивы, зооморфные, стилизованные изображения трилистников, геометрические формы, солярные знаки и др.

Из зооморфных мотивов встречается изображение птицы. В деревне Байкал (дом по ул. Тукая, 29), вертикальное

изображение птицы с распростертыми крыльями, с устремленной головой вверх. В деревне Шура и в селе Пшенгер (Нагорная, 13), образ голубя помещен прямо на верхнюю часть наличника. В селе Сердабаш (ул. Г. Жукова, 10) знаковая трактовка такого изображения совсем иная, причудливые завитки напоминают изогнутые головы, а хвосты сделаны в виде трилистников.

Геометрические орнаменты: ромбы, узоры в форме сердечек весьма распространены на данной территории, они украшают окна домов, выполненные в технике пропильной резьбы. Ромбовидный узор располагается по центру наличника. Этот орнамент трактовался в трудах ученых по-разному, чаще всего его относят к знакам связанным с сельскохозяйственной деятельностью, как изображение поля. В домах, построенных в 1950–1960-х годов можно встретить советскую символику – изображение звезд или серпа с молотом, расположенных по центру наличника.

В цветочно-растительном орнаменте мастера проявляют больше фантазии. Например, в деревне Сердабаш (ул. Г. Жукова, 10) ажурные кружева, обрамляют весь наличник, присутствует и изображение трилистников, вписанных в сам рисунок. Есть солярные знаки расположенные симметрично сверху и снизу, по углам окна. Сочетание белого кружева и заключенных в него синих орнаментов, придают нарядный и торжественный облик всему ансамблю.

Солярные знаки и изображения солнца, наверное, самый узнаваемый узор, который отличает дома татар. Он обрамляет не только наличники окон и ворота, но и ниши фронтонов, которые часто встречаются в жилых застройках. Такие ниши, располагаются под крышей (чердачная часть), в ней находится окно, которое тоже украшается резьбой, поверх него может располагаться знак – сияние, украшенный полихромно. Иногда такая ниша имеет небольшой балкон. Яркий тому пример дом в деревне Кзыл Яр, по ул. Советская, построенный в 1975 году А.Г. Габдулхаевым (1933 г.р.). Сам умелец проработал всю жизнь врачом. Балкон, который он смастерил сам, украшен восточной аркой, внутри находится окно, поверх него полукружие – символ восходящего солнца, композицию дополняют две деревянные

колонны и нарядные перила. Трактовка знака солнца тоже разная, традиционная в виде круга или цветка. Но есть нетипичные изображения в деревне Байкал. Солнце здесь представлено, как ни странно, в виде прямоугольника с отходящими от него тремя лучами, в другом доме – символическое изображение трех лучей, исходящих от одной линии горизонта.

Ворота в районе, как правило, с двухскатной крышей, с яркой полихромной окраской, редко можно встретить раскрашенные в один цвет. Украшения разнообразные: цветочные орнаменты, рогообразные завитки, солярные знаки, сердечкообразные мотивы. В деревне Каргалы по улице Дальняя, 15, владелец дома Ф.К. Котдусов помимо орнаментов, нанесенных на ворота, украсил резными узорами и лицевую часть дома. Плотник нанес цветочные украшения, в технике пропильной резьбы – полевые цветы по двум верхним углам, ряд внизу дома, в середине расположен солярный знак.

К сожалению, на сегодняшний день, мастеров-плотников, которые продолжают заниматься деревообработкой осталось немного, все они уже пенсионного возраста и не имеют учеников. Сразу требуется уточнение, что плотничеством занимаются почти все мужское население и весьма искусные умельцы самостоятельно строят дома и украшают наличники резьбой. Но большинство обслуживает нужды только своих собственных домов, поэтому под резчиками-мастерами, в данном случае, я подразумеваю тех, у кого это производство поставлено на поток, тех кто строит и создает узоры не только для своего жилища, но и выполняет под заказ для других людей. В деревне Новая Ора плотник Г.Н. Нуриев (1927–2012) занимался строительством домов и изготавливал наличники, многие жилища этого поселения украшены именно им. Его дочь А.Г. Лотфуллина в мастерской своего отца организовала небольшой музей. Здесь собраны предметы, которыми пользовался умелец, заготовки резьбы и некоторые вещи которые он мастерил. Профессионального образования не имел, резьбе обучался сам, в общей сложности построил 33 дома, эскизы орнаментов придумывал самостоятельно. Дом плотника по ул. Кирова, 7 отличается от других построек своей

нарядностью. По периметру постройки, под крышей, идет ажурная резьба, в ней угадываются цветочные орнаменты и четко можно выделить сердечкообразные мотивы. В верхней части дома имеется ниша, сделанная из разноцветных брусьев, посередине окно, узоры резьбы на наличниках имеют змееобразные орнаменты. Еще одна приметная деталь постройки – шпиль над крышей здания, воспроизводящий образ мечети. Умелец смастерил деревянный дом с ярким солярным знаком посередине, во втором ярусе ниша с небольшим балкончиком, сбоку по краям также имеется имитация балконов, а сверху идет минарет с мусульманским полумесяцем. Стоит отметить, что за все время экспедиции, это был единственный дом, который украшает такое интересное сооружение.

В деревне Шура плотник Т.Г. Зинатуллин (1952 г.р.) мастерству резьбы по дереву обучался самостоятельно, проявил к этому виду искусства интерес в шестнадцатилетнем возрасте. В своей небольшой мастерской изготавливает наличники в технике рельефной резьбы. Орнаменты использует традиционные: змееобразные мотивы, цветочные, геометрические. Последние 4 года работает с металлом, т.к. этот материал сейчас более востребован. Деревянные наличники продолжает мастерить, но в меньшем объеме. Есть образцы табуреток и стульев, а также саней. В этой же деревне плотник – М.М. Габдрахманов (1962 г.р.), занимается производством деревянных лавок, табуреток, этажерок, журнальных столиков и в большом количестве изготавливает разнообразные скворечники. Как и предыдущий мастер, заинтересовался резьбой в юности, обучался ремеслу самостоятельно.

В селе Пшенгер было взято интервью у плотника Х.З. Зайнуллина (1948 г.р.). Мастерству резьбы тоже обучался сам. В последние пять лет заказы получает от жителей района на изготовление наличников и узоров из металла, поэтому сейчас работает только с этим материалом. Также мастерит и украшает цветочным орнаментом железные почтовые ящики.

Самый молодой мастер Н.Ф. Гимадетдинов (1982 г.р.) обнаружен в деревне Мамся. Уроженец этой местности, закончил

педагогическое училище в Арске, несколько лет работал учителем труда в Новом Кинере, где обучал мальчиков основе резьбы по дереву. В самой деревне есть дома украшенные его работами. Следует упомянуть еще об одном мастере-самоучке из Сердебаша И.И. Самигуллине (1972 г.р.). Хоть и не занимается серийным производством деревянных изделий, он всю жизнь мастерит, самостоятельно украсил свой дом резьбой. В 2011 году заинтересовался весьма необычным занятием на сегодняшний день – изготовлением гуслей. Изучив и освоив довольно успешно этот промысел, стал известен среди местных жителей, которые, пусть и в небольших количествах, но заказывают ему этот музыкальный инструмент.

Давняя традиция украшать дома шамаилями сейчас возвращается, но это в основном покупные магазинные изделия. В советское время таким ремеслом занимались кустари-самоучки. В деревнях Шека и Мамся были обнаружены шамаили, примерная датировка которых относится к 1960-ым годам. Выполнены масляными красками по стеклу. В первом шамаиле на черном фоне присутствует текстовое содержание, арабской вязью в правой части. В левой, расположено изображение мечети, обрамленное рамкой из цветов. В прорезях между букв и минаретами мечети проложена цветная фольга. Во втором шамаиле большое изображение минарета помещено посередине, в него вписан текст, по бокам расположены две башни, по форме и цвету, напоминающие башню Сююмбике. Фоном служит голубой цвет, также вверху помещено изображение цветов и полумесяцев, лепестки украшены фольгой.

Вышивка – один из древнейших и интереснейших видов декоративно-прикладного искусства, весьма был развит в Арском районе. Много образцов вышивки и ткачества сохранилось в семьях и в местных школьных музеях. Не секрет, что раньше девушки начинали готовить себе приданое, будучи совсем еще юными. Сейчас уже эта традиция ушла. Многие респонденты ссылались также на отсутствие времени, которое необходимо затратить на изготовление такого произведения искусства. Поэтому древним ремеслом в основном занимается больше старшее

поколение. Материал для вышивки используется разнообразный: хлопок, лен, фабричные ткани, сукно, в старых изделиях встречается домотканое полотно. Нитки для вышивки выбирают также разного вида: хлопковые, шелковые, шерстяные, в настоящее время используют много синтетических материалов. Техника вышивания тоже применяется различная: гладь, вышивка крестом и традиционный тамбурный шов. Золотошвейное шитье применяется в основном в декоре тюбетеек.

Цветовое решение в татарской народной вышивке, как и в деревянных украшениях домов, полихромное. В подборе цветов нет строгого правила, здесь мастерицы вольны проявлять свою фантазию и вкус. Если говорить об основных орнаментах, то Ф.Ф. Гулова вслед за Ф.Х. Валеевым выделяет 3 группы: цветочные, геометрические и зооморфные мотивы. «Образы садовых цветов (георгины, пионы, астры, хризантемы) более характерны для вышивок горожанок, тогда как крестьянскому быту были близки образы лесов, полей, лугов. Геометрическому орнаменту в вышивке в большинстве случаев отводится вспомогательная роль. Так, мотивы меандр спирали, жгута, веревочки и др. используются в композициях каём… Зооморфные мотивы в татарской вышивке встречаются очень редко»[1].

В деревне Кзыл Яр у Х. Галиевой сохранилась старинная вышивка, сделанная её мамой, примерная датировка изделий 1928 год. Это бранное полотенце с геометрическими узорами по краям. Особо надо отметить цветную корама – ярко связанную дорожку на скамейку. Изделие состоит из цветных квадратов, каждый такой кусочек выполнен мастерицей в своем сочетании тонов, который не повторяется ни в одном из сегментов. В деревне Новая Ора удалось встретиться с мастерицей А.М. Хакимовой (1952 г.р.). Обучалась вышивке еще в школьные годы, училась вместе с девушками из многодетных семей. Занимается вышивкой салфеток, наволочек, скатертей. Техника, в которой работает мастерица – гладь (тутырып чигү) и тамбур. В основном мотивы

---

[1] *Гулова Ф.Ф.* Татарская народная вышивка. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. С. 22–24.

вышивки – это разнообразные цветочные орнаменты. В этом же населенном пункте сохранился старинный намазлык у М.Х. Мехаметжановой, выполненный ее мамой в 1909 году. Тамбурная разноцветная вышивка обрамляет периметр намазлыка, но одна часть остается без орнамента, что придает П-образную форму. Мотив узора: разнообразные цветы, листья, которые складываются во всевозможные букеты. С внутренней стороны все это великолепие обрамляют волна змеевидных завитков. Синяя лента по краям намазлыка завершает общую композицию. Другой намазлык расшит на хлопчатобумажной ткани, также выложены цветочные орнаменты. Контур цветка выполнен тамбурным швом, внутренняя часть – гладью. Обрамляет намазлык – красный кант.

В деревне Байкал изготовлением вязаных изделий занимается местная мастерица М.В. Гиннатуллина (1940 г.р.). Всю жизнь проработала учителем начальных классов, вязанию обучалась сама. Она изготавливает различные половики, накидки на стулья, в ее же коллекции имеется старинный намазлык. Здесь нет того привычного многообразия цветов, а скорее симметричное расположение узоров: 3 по бокам и 3 сверху. Присутствует один орнамент, который повторяется по периметру: ваза с цветами. Каждый цветок имеет свой окрас и форму.

Сердабаш – населенный пункт, где проживают казанские татары и кряшены. Мастерица из этой деревни Э.К. Архипова расшивает полотенца, наволочки, подзор на кровать в ее коллекции есть набожник – шторка над иконой, вся вышивка выполнена в технике – гладь, узор у них единый – садовые цветы.

Потомственная мастерица живет в селе Пшенгер – М.К. Шарифуллина (1940 г.р.), вышиванию и вязанию с ранних лет учила ее мама. В Пшенгерском многофункциональном центре, во время нашей экспедиции, как раз проходила ее выставка. Выставлялись следующие работы: наволочки, расшитые простыни, полотенца, платки, орнаментированы цветочными узорами. Шерстяную нить М.К. Шарифуллина прядет сама, с помощью старой прялки, которую в свое время изготовил ее отец. Из этих нитей потом и вяжет различные вещи: носки, шали, узорные украшения на стулья.

В деревне Мамся учитель истории собрал коллекцию старинных предметов декоративно-прикладного искусства, которая находится в музее местной школы. Вещи датируются 1920-ми годами. Расшитые «аяк чолгавы» – наголенники, украшены с двух сторон цветочным орнаментом. Контур цветов обрамляет тамбурный шов, внутри расшиты шерстяными нитями. По краям наголенник обрамлен кружевной тесьмой. Другие «аяк чолгавы» вышиты крестиком, лоза из красно-синих цветов декорирует два края полотна и также завершает отделку кружевные канты. В доме у Р.И. Насыбуллиной в коллекции находятся два намазлыка. Оба датируются 1860 годом. Один намазлык вышит в технике низкий тамбур на белом полотне, богато украшен цветочным узором, который обрамляет его по периметру. При вышивке использовались как шерстяные нити, так и шелковые. Второй намазлык сделан из темного сукна. Рисунок состоит из отдельных симметричных букетов – 4 по бокам и один вверху.

Богато украшаются вышивкой и головные уборы – тюбетейки. Мастеров, которые занимаются до сих пор этим ремеслом осталось немного. В районах такие умельцы не были обнаружены, но в самом Арске мастера нашлись: Н.И. Шакирова (1950 г.р.) и З.Ф. Тимергалиев (1974 г.р.). Как рассказала в интервью Нурания Исламовна, она 30 лет проработала на Арской фабрике, когда производство закрылось, продолжила заниматься творчеством и самостоятельно создавать головные уборы, учеников у нее нет, поэтому мастерство передавать некому. Техника производства следующая: сначала на пяльцах вышивается верхняя часть тюбетейки, потом отдельно боковые, окружная часть. Для изготовления использует бархат (зеленого или черного цвета), вышивает она только бисером. На вышитые части будущей тюбетейки пришивается изнаночная хлопчатобумажная ткань. Бархатная основа простегивается, что придает рельеф головному убору. Между строчками вставляют шпагат, чтобы держать форму. Украшается изделие цветочным орнаментом, узор располагается по три цветка сверху, три по окружности. Затем две части сшивают и сажают на специальную форму, предварительно смочив ткань, где она высушивается. З.Ф. Тимергалиев

занялся производством тюбетеек 8 лет назад вместе со своей женой Л.И. Тимергалиевой. Процесс производства примерно такой же. Только расшивает мастер изделие канителью. Орнаментальный узор обвивает всю поверхность тюбетейки, это изображение цветов и трилистников, которые также обрамляют и боковые части изделия. Цвет бархата выбирает зеленый и белый.

Изготовлением тканых изделий сейчас не занимаются. Но образцы браного и закладного ткачества в больших количествах остались во многих домах респондентов и в музеях района, примерная датировка этих изделий 1920–1930-е годы. Браное ткачество одна из древнейших техник орнаментации тканей, декоративного оформления бытовых и обрядовых изделий. Браными узорами часто украшали полотенца, скатерти, детали женской одежды. Наиболее распространенный орнамент, который встречался в таких изделиях в исследуемых населенных пунктах – это ромбовидный орнамент. Ромбовидные узоры, заполоняют, как сплошь вышитую полосу, так и симметрично располагаться в зоне рисунка, либо в шахматном порядке. Как правило, орнамент ткался красными нитями, материалом служила либо хлопчатобумажная, либо льняная ткань. Кроме сложного браного ткачества применялось и закладное. Этим способом можно выполнить и большую одноцветную плоскость, и рисунчатую многоцветную. Орнамент в этих изделиях тоже геометрический: ромбы, зигзаги. В деревне Сердабаш в доме Э.К. Архиповой была обнаружена старинная домотканая ткань, выполненная технике пестрядь. Пестрядь представляет собой хлопчатобумажную ткань, с расположенными на ней разноцветными квадратами, в данном случае чередование красных и черных сегментов. Другая скатерть в этой же технике с линейным узором, сочетание красных и синих полос. В доме номер 3 по ул. 65 лет Победы сохранились тканые дорожки, выполненные мастерицей А.А. Андреевой.

Татарские костюмы в Арском районе сохранились в достаточном количестве в крупных музеях данного региона. Самая большая коллекция представлена в Арском историко-этнографическом музее. Здесь собрана обширная коллекция

декоративно-прикладного искусства татар, образцы одежды, утвари и резьбы и др. В населенных пунктах, которые были обследованы, в частных коллекциях народного костюма практически не осталось, лишь небольшая часть представлена в местных ДК, школьных музеях и клубах. Среди вещей, которые удалось собрать по крупицам: кукрекче – нагрудник, жилетки, калфаки, фартуки, ичиги.

Ичижное производство, которое было некогда развито в регионе, сейчас практически забыто. В населенных пунктах мастеров – сапожников не осталось. Отдельные экземпляры сапог встречаются в музеях и сельских клубах, в основном эти изделия, остатки от массового производства, которые выпускались на Арской фабрике. Но есть умельцы, продолжающие работать на дому. С одной из таких мастериц произошла встреча в Арске. Ф.Г. Каримуллина (1958 г.р.) с 1975 года начала осваивать это непростое ремесло. Много лет проработала на фабрике по пошиву национальной обуви. После ухода, продолжила заниматься любимым делом. Процесс производства ичигов составляет несколько ступеней. Фарида Габдулхаковна – первое звено в этой цепочке, она занимается исключительно вышивкой. Заготовленные узоры из кусочков разноцветной кожи сшиваются вручную на специальном станке с помощью шила, нитки мастерица использует шелковые тоже многоцветные. Сшивается узор с изнаночной стороны, лицевую часть в процессе работы умелица не видит. Цвет каждого кусочка в кожаной мозаике подбирает сама, предварительно нарисовав на бумаге, где подробно подписывает, какого окраса будет каждый фрагмент. Орнаментальные мотивы традиционные: тюльпаны, трилистники, змеевидные завитки.

В Арском районе представлены практически все виды народных промыслов казанских татар. Это край с богатым наследием и прославленными мастерами. Как писал Н.И. Воробьев, «главным центром распространения почти всех промыслов является Арский кантон»[1]. Все исследователи отмечали, что Арские

[1] *Воробьев Н.И.* Материальная культура казанских татар. Казань: Изд-во Дома Татарской культуры и Академического центра, 1930. С. 86.

умельцы – идеал, к которому необходимо стремиться. Образцы декоративно-прикладного искусства еще остаются в домах респондентов, переходят по наследству следующему поколению. Отдельные энтузиасты собирают предметы народного искусства, которые являются основанием коллекций школьных музеев, ДК, сельских клубов и т.д. Но наблюдается постепенная утрата тех отраслей, которые некогда были хорошо развиты. Мастеров-резчиков по дереву осталось совсем немного, как правило, у них нет учеников; поколение мастериц-вышивальщиц, постепенно уходит, а ичижный промысел, после закрытия Арской фабрики, сохраняется только благодаря профессионалам, которые продолжают заниматься этим в частном порядке. Деревянная резьба заменяется на изделия, сделанные из метала, в отдельных случаях от нее стараются избавиться совсем. Стремление сделать дом «по последней моде», приводит к утрате народного зодчества. Убранство внутри домов тоже подгоняется под общие веяния моды, уже не принято декорировать интерьер вышивкой, внутри отделывается современными материалами. Немало важно, что происходит утрата старинных предметов декоративно-прикладного искусства и среди наследников: вышитые полотенца, намазлыки, одежда, шамаили. Видимо, не понимается особая ценность этих вещей, как реликвий, в которых зафиксирована память народа. Поэтому сегодня существует особая потребность в поддержке и сохранении народных традиций.

# ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә төрле елларда фәнни экспедицияләр вакытында тупланган күп кенә фольклор әсәрләре саклана. Бирердә, шул экспедицияләрдә катнашкан Мөхәммәт Мәһдиев (1961), Эдуард Касыймов (1951), Наил Гыйззәтуллин (1951), Мәрвә Богданова (1951), Арча педагогия көллияте укучылары тарафыннан язып алынган материаллар тәкъдим ителә.

### Шәкерт җырлары

*(Казим мәдрәсәсендә)*

«Мулла Җәлал»нең Сахибе «Мөхаккикер дәвани»
Гыйшкым төшкән син җаныйга табиб тапмый дәваны.

Укый торган китабымның исеме «Сөлләмел голум»,
Бәнем җанкәмне күрсәгез, кәл камҗе бәйнән хөҗүм.

Каләшшәйых диш шифа дип укыганың мантыйкмы
Ма рә әйтә ма вәшәттә син җанидин артыкны.

Исагушның дәресе кәлияты хәместин,
Син җаный белән утырсам, бәнем күңелем ләместин.

Бәнем бик сөйгән китабым «Мәсаилел һидая»,
Нурлы йөзеңне күрсәм дә шул буладыр кифая.

Тәмәке тартсам оят, аракы эчсәм кыйбат,
Икесенә дә кыймасаң, пич башына мен дә ят.

Һавада йолдыз ни кадәр, суда балык шул кадәр;
Синең калбең нәмиданым бәнем гыйшкым шул кадәр.

Бу дөньяның фәүкында балкый шәмес нурлары,
Гайнең әсвәт (*күзең кара*) вәшһең абьяз (*йөзең ак*),
мисалең җәннәт хурлары.

Биек тауларның башында сандугачлар агач башында,
Зөләйханың васфы бардыр синең дәкыйкъ кашында.

Фиракыңның уты җаный һәм хәсрәттин әгъладыр,
Әгәр мәхрүм висалеңдән бәнем үлмәгем әүладыр.

Тәрәзәңнең төпләрендә нинди гөлләр үсәдер,
Кил, җанкәем, бер кавышыйк, гыйшкың үзәгемне өзәдер.

Сәхрәләргә чыккаймын төрле якка йөргәнмен,
Гүзәлемнең йөзләрен нихәл итеп күргәнмен.

«Шәрхемулла» дәресендә шәкерт карый «Мөхәррәм»
Син, җанкәем, ятка китсәң, инни әхваттә хәрәм.

«Каләл козыя» дип алдык без бу көнге дәресне,
Син җаныемны күргәчтен башым тулы ләместин.

«Исагучи» тәмам булгач укый шәкерт «Шәмсия»,
Фил җәннәти хурыл гайнем кара чәчең шәл сиңа.

«Гакайыд»ның дәресендә сөеп карыйм Хашия
Фил хакыйкать әнә гашыйк, җаныем, кара кашыңа.

Мохгасарның дәресендә караганым «Җамигый»,
Сәнең белән мөгамәләм булса иде даими.

Мохаккыйкет дәвани тәшвиз кыйла Мөхалли,
Күрмәгәнгә күрсәтмәсен Кадыйр Мәүлә бу хәлне.

Укый торган китабымның исеме «Хикмәтелгаен»,
Син җаныем күк булса булыр җәннәттә Хурәлгаен.

Әл хикмәрел балига, мин тәэлидил Мәрҗани,
Фил Мәгърибе вә диил мәшрикый ла назирәкә җаный.

*Габделхак Мәһдиев дәфтәреннән.*
*Арча районы Сикертән авылы.*
*Күчереп алды: М. Мәһдиев. 1961 ел.*
*(кол. 72, папка 1, сак. бер. 1)*

**Баламишкин бәете**

Баламишкин агып киткән Кара идел буенча,
Я саларымны, балаларымны күрми калдым туйганча.

Миннән калган сәгатемне балаларыма бирегез,
Газиз анам, газиз балам, миннән бәхил булыгыз.

Бу эшләрне язмак булдым, һич тә бу эшкә чара юк,
Миңа язылмыш эшләрдер, бу тәкъдиргә һич тә газа юк.

Мишкин алма алма алдырган кунакларның ашына,
Кемләр сәбәб булган бу бичара башына.

Баламишкин атылганда ливарвирын төзәтеп,
Хатынлары, балалары елап калган озатып.

Галиевнең корпусында Баламишкин сәүдәсе,
Су өстендә череп беткән бала Мишкин гәүдәсе.

Баламишкин нәрсәләре үзе үлгәч сатылган,
Почтадан түбәнрәк Баламишкин атылган.

Баламишкин ташлап киткән, ике туган ишләре
Үзен-үзе ташлап киткән, Баламишкин эзләре.

Кибеттән чыгу сәбәб булган Баламишкин башына,
Бөтен шәһәр хәйран булган балам эшенә.

Баламишкин табылды, дип, телефоннан хәбәр иттеләр,
Баламишкинны карарга балалары киттеләр.

Баламишкин башы йөрде һәрбер эшнең көендә,
Баламишкин вәйран булды Кара идел төбендә.

Баламишкин яр буена төшеп киткән аткачтын,
Киемләре череп беткән суда озак яткачтын.

Баламишкин булмагачтын азайгандыр сәүдәсе,
Баламишкин сигез көн югалып торды су эчендә гәүдәсе.

Усиядән хәбәр килгәч карый киткән әнкәсе,
Су эчендә озак ятып, тарала башлаган гәүдәсе.

Ак куянның балалары йөгерә олы юл белән,
Микъдарын язылганны бозып булмый кул белән.

Финисадан ясыйлар алтын йөзек кашлары,
Агым суда вәйран булган Баламишкин башлары.

Зекер тәсбих әйтә алмадым Идел бозы акканда,
Үземне үзем тыя алмадым башыма мылтык атканда.

Газиз әнкәм, газиз балам көткәннәрдер кайта дип,
Алмачылар килеп җиткән Мишкин суда ята дип.

Буел еллар җылы килгән җылы буран бураган,
Баламишкинның гәүдәсе параходка чорналган.

Мишкин чыгып киткән чакта өстәл тулы аш калды,
Анасының, баласының күзе тулы яшь калды.

Охотник мылтык атадыр, төгене җиргә ятадыр,
Баламишкинның гәүдәсе ком өстендә ятадыр.

Баламишкин иртә торгач Сачын майлап тараган,
Баламишкинның гәүдәсен доктор ярып караган.

Иртә торгач чыгып киттем, башыма бүрек алмаган,
Җан биргәндә юк әнкәем агазыма су салмаган.

Биек-биек каралты, аның эче караңгы,
Үземне үзем аткан чакта ике күзем кан алды.

Иртә торып тышка чыккач, ике күзем төште үләнгә,
Мылтык белән мин атылгач, фаш булгандыр галәмгә.

Өемнән чыгып киттем туганнарым белгән дип,
Бөтен галәмнәр сөйләгән мишкин суда үлгән дип.

Өстемдәге күлмәгемне газиз анам теккәндер,
Балаларым, туганнарым мин кайта дип көткәндер.

Баламишкинны мактыйлар, яхшы диеп сәүдәсе,
Баламишкинны таптылар усиядә гәүдәсе.

Пылау илә пилмән Баламишкин ашлары,
Су астында вәйран булды Баламишкин башлары.

Җигә торган тугры атымны, күзем туеп күрмәдем,
Балаларым, бәгырьләрем, күзем туеп күрмәдем.

*Сөнгать Бәдретдинов дәфтәреннән.*
*Арча районы Сикертән авылы.*
*Күчереп алды: М. Мәһдиев. 1961 ел.*
*(кол. 72, папка 1, сак. бер. 1–5)*

**Бәрәзә бәете**

Моны укып белгән кеше бөтен илне тутырыр,
Укый белмәгән кеше авызын ачып утырыр.

Бисмилла дип башладым, тауга таяк ташладым,
Гаеп итмә тыңлаганнар, бәетегезне башладым.

Бәрәзәнең кызлары, чыпта суга үзләре,
Көне-төне чыпта сугып, пешегеп беткән күзләре.

Чыптачының бишмәте, озын гына тишкәндер,
Чыпталарын каты сугып, агызлары пешкәндер.

Бәрәзәнең ындырында ике куян бер төлке,
Бәрәзәнең кызлары Россиягә бер көлке.

Әүәйгә чыксаң, шулар була Эшкәтә елгасында
Бичаралар бер туктыйлар җыенның җомгасында.

Бәрәзәнең атлары улак төбен кимерә,
Бәрәзәнең кызлары чыпта белән тилмерә.

Бәрәзәләр чыпта сугып, ак мончалар салдырган
Чыпталарын начар сугып, бик күп табыш калдырган.

Чыптачылар тышка чыга, иңенә бишмәт салып,
Чыптачылар табыш итә, юкәсен алып калып.

Бәрәзәнең кызлары су китерә менеп,
Атна кичләр җитә диеп, алар йөри сөенеп.

Бәрәзәнең кызлары чыпта сугып киенә,
Башка авылдан яучы килсә, котылам дип сөенә.

Бәрәзәнең кызлары кара бүрек кияләр
..................................................................

Бу көн иртә тордым диеп, бер-ике чыпта арттыра.

Бәрәзәнең кызлары уникедән торалар,
Йокылары килгәчтен инә-җепкә уралыр.

Бәрәзәнең кызлары чыпта суга сызланып,
Аналары уятырга үкереп җылый кызганып.

Бәрәзәләр чыпта суга, бәһаләре ун тиен,
Көне-төне суга-суга, тутыруы бик кыен.

Бәрәзәнең атлары тау менгәндә тартмый ич,
Инә биргән малайларга бер тиен дә артмый ич.

Бәрәзәнең кызлары сатин яулык алалар,
Атна кичтә юкә ярып ял итмичә калалар.

Бәрәзәләр иртә тора, чыпта суга башлыйлар,
Кич җиткәчтен ял итәргә калакларын ташлыйлар.

Чыпта байның атлары таудан тауга ашыга,
Чыпта бае юкә алып кайтса, чыптачылар чабыша.

Бәрәзәнең басуында аппак куян ятадыр,
Сукмас идек бу чыптаны, акча кирәк этигә.

Бәрәзәнең кызлары ак чабата кияләр,
Чыпта сугып акча тапкач, аталары сөяләр.

Бәрәзәнең сыгырлары көне-төне үкерә,
Бер көн чыпта сукмый калса, аталары үкенә.

Чыптачының өйләре багана белән бүлмәле,
Чыпта суккан яшь кызларның каешлана күлмәге.

Бәрәзәнең атларында алты колачлы аркан,
Бу чыптадан котылыр идем, инде кияүгә барсам.

Бәрәзәнең кызлары су китерә мончага,
Өйләренә барып керсәң, чорналадыр мончала.

Чыптачының өйләрендә юкә була тастымал,
Буйлырак юкә килеп чыкса, сөлге урынына астылар.

Бәрәзәләр чыпта суга, чиратлашып йоклыйлар,
Атна кичләр җитмичә, урамга да чыкмыйлар.

Кылны тарткан чагында чыгырлары шалтырый,
Тәрәзәдән егетләр күргәч, кызлар күзе ялтырый.

Чыптачының сукмагы кара була күмердән,
Өсләрендәге күлмәге кара белән күмелгән.

Сөләйманнар капкасында халык тора җыелып,
Чыптаң начар булган дигәч, шулар китә боегып.

Бай катына барганда кеше саен бер чыпта,
Май базары җиткәчтен бармый калмый бер йорт та.

Бу чыптаны кем суктыра, Бәрәзәдә Сөләйман,
Чыпта суккан яшь кызларның ике күзе челәйгән.

Бәрәзәләр чыпта сугып, урыс капка эшләтә,
Җәйгә чыкса, шулар кия башларына эшләпә.

Җомга көнне иртә белән картлар бара мәҗлескә,
Бу чыптадан котылсак иде дип, нәзер әйтәләр шәкерткә.

Аппак каен сазлар саен, яфрак яра ел саен,
Бәрәзәдәге кызлар чыпта суга көн саен.

Бәрәзә урамы дугай, дугай-дугай бер тургай,
Кайсы урамнар дугайсыз, чыпта сугу уңайсыз.

Бәрәзәгә кыз бирмәгез чыпта суга белмәсә,
Шул чыптадан котыла алмас, әҗәл җитеп үлмәсә.

*Сөнгать Бәдретдинов дәфтәреннән.*
*Арча районы Сикертән авылы.*
*Күчереп алды: М. Мәһдиев. 1961 ел.*
*(кол. 72, папка 1, сак.бер. 4)*

## Акыллы җавап

Бер кеше үзенең туганын кунакка чакырган. Кунакның, ашагач, су эчәсе килгән. Ләкин кисмәкнең кайда икәнен белмәгән. Шунда хуҗадан су сораган.

Хуҗа:

– Йөрәгең янып бетә күрмәсен, – дигән.

Кунак:

– Үзем дә шуннан куркып сорадым шул, – дигән.

## Табышмаклар

Үзе атланган, аягын арт якка салган (*күзлек*).

* * *

Утта туам, утта үләм (*күмер*).

* * *

Кыш көне күп ашый, җәй көне күп йоклый (*мич*).

* * *

Агач, агач өстендә табак, табак өстендә кибет, кибет эчендә ике мең егет (*көнбагыш*).

* * *

Бер анасы, бер атасы, ничә йөз мең баласы (*ай, кояш, йолдызлар*).

* * *

Бер бүректә кырык ямау (*мунча ташы*).

* * *

Иһитә-миһитә, бер кешене ике итә (*көзге*).

* * *

Арткылы да, торткылы
Безнең бабай ындыры (*тәрәзә*).

* * *

Ай бирде, кояш алды (*чык*).

* * *

Кабара-кабара, кабара күк, кабарым пешкән коймак күк,
Ясана-ясана, ясана күп, ясанып килгән кияү күк (*күркә*).

* * *

360 сыерчык, 52 тәкерлек, 12 аккош, 1 торна,
Аны белмичә күп торма (*360 көн, 52 атна, 12 ай, 1 ел*).

* * *

4 терәвеч, бер болгавыч, 2 йолдыз, пар кубыз (*сыер*).

* * *

Йомры башлы, мең күзле (*уймак*).

* * *

Эче куыш, тышы таш, әллә нинди орчык баш (*чәйнек*).

* * *

Озын урыс сузылып ята, балалары тезелеп ята (*матча, түшәм такталары*).

* * *

Кече киленнең башмагы олы киленгә ярамый, олы киленнең башмагы кече киленгә ярамый (*юшкәләр*).

* * *

Биби, биби, би балык,
Биби ашый чи балык,
Бу балыклар булмаса
Нишләр иде бу халык (*икмәк*).

* * *

Киндер келәт, мунчала йозак (*капчык*).

* * *

Өрми дә, җибәрми дә (*тигәнәк*).

* * *

Дүрт колаклы, ике корсаклы (*мендәр*).

* * *

30 кеше ашлык суга,
Дмитрий агай әйләндерә (*тешләр, тел*).

* * *

Ишек катында яшел каз,
Яшел казның башы таз (*себерке*).

* * *

Мич астында кортлы киез (*тел*).

* * *

Мич башында карт урыс,
Сакалыннан тартыгыз (*песи*).

* * *

Ике койрыклы күсе (*чабата*).

* * *

Өй әйләнәсендә кыл дилбегә (*мүк*).

* * *

Йөзлек астында йөз инә (*керфек*).

* * *

Тышы сары шалкан кебек,
Утырадыр мулла кебек,
Сызгырадыр шайтан кебек (*самовар*).

* * *

Ак келәтнең алдында ике көчек бәйләүле (*алкалар*).

* * *

Ике читеннән тоттым, уртасына тыктым (*оек*).

* * *

Ерак килгән кунак булса да
Тәрәзә астында тора (*җил*).

* * *

Ябалактан курка, чикләвекне вата,
Сызгырсаң, урманны ярата (*тиен*).

* * *

Өй эчендә үгез күзе (*ботак*).

* * *

Сакаллы сабый, бармак яный (*билчән башы*).

* * *

Дүрт киленгә бер шәл (*өстәл*).

* * *

Чалт аязда болыт юк (*көзге*).

* * *

Башы бар, мие юк,
Сырты бар, эче юк (*чабата*).

* * *

Бер тычканга ике койрык (*инә, җеп*).

*Туплады: М. Мәһдиев, 1958 ел.*
*(кол. 72, папка 1 сак. бер. 12)*

**Такмаза**

Төштем инеш буена
Ике ана каз утыра.
Килдем дустым катына
Дустым ялгыз утыра.
Дустым дуслар эчендә
Мин дустымны танырмын,
Йөз алпавыт эченнән.

* * *

Тыпыр-тыпыр биергә
Имән сайгаклар кирәк;
Имән сайгаклар өстенә
Таллы өстәлләр кирәк.
Таллы өстәлләр өстенә
Ак кәгазьләр бик кирәк,
Ак кәгазьләргә язарга
Кара каләмнәр кирәк,
Кара каләмне тотарга
Гыйльми шәкертләр кирәк,
Гыйльми шәкертләр каршына
Кара кашлы кыз кирәк.
Кара кашлы кыз битенә
Кершән, иннек бик кирәк,
Иннек, кершән ягынырга
Бүләк көзгеләр кирәк,
Бүләк көзгеләр пыяла
Җиргә төшсә уала.

*Арча районы, Субаш Аты авылында*
*72 яшьлек Шиһап Бикбаутовтан*
*Э. Касыймов белән Н. Гыйззәтуллин*
*язып алды. 1951 ел.*
*(кол. 42, папка 1, сак.бер. 34)*

**Сугыш бәете**

1904 нче дә сугышырга башладык,
Сугышка дип хәбәр алгач,
Вольный киемне ташладык.

Бу бәетне язамын,
Искә алсын туганнар,
Хәзер монда безләрне,
Сугышырга куалар.

Уйлый-уйлый язамын
Ниләр булды башымда,
Әти-әни истән чыкмый
Гел торалар каршымда.

Бу бәетне яздык без
Ничә солдат җыелып,
Көне төне җылаганга,
Бетте яшьләр коелып.

Укучыдан үтенәмен,
Гаеп кылма карарга,
Чибәрен дә язар идем,
Табып булмый язарга.

Ничә төрле булды инде
Түбәндәге сүзләрем,
Кулым бер дә дөрес язмый
Кан алганга күзләрем.

Яшь-кан алмасын күзебез,
Утка кердек үзебез,
Әткәй-әнкәй, кайгырмагыз,
Бер вакытка түзегез.

Әвәл хезмәт итүләр
Бер нәрсә дә булмаган.
Шуның өчен булган
Сугышларга куылмаган.

Бу китүем авыр булды,
Өмет өздем кайтудан.
Без чыгачак кичләрдә,
Бигрәк яңа ай туган.

Көне-төне Ходайга
Зарый кылып сыгылам.
Казак килеп хәбәр биргәч,
Һушсыз булып егылам.

Ике балам ике яшьтә,
Мине кочып яталар.
Чыгасы көн уенга,
Мичкә иртә якканнар.

Әти әйтә: хәзерлән, дип
Атны хәзер җигәбез,
Может быть, Ходай бирсә
Японнарны җиңәрбез.

Төнлә сугу сукканда,
Кигән идем тула ыштан,
Угылым килеп хәбәр бирде,
Казак килгән волыстан.

Чыккан вакыт сугышка,
Без мәчеткә җыелдык,
Мулла вәгазь кылгачтын,
Күп эшләрдән тыелдык.

Җылый-җылый йөгреп кайттым,
Чыкты бәтекәйләр каршы.
Ашарга да салучы юк,
Кычкырыша бәтиләр.

Безнең авыл мулласы
Вәгазь кылды безләргә,
Староста чыгып киткән
Кайсыбызны эзләргә.

Алтмыш ике солдат булдык
Без авылдан чыкканда,
Пышык-пошык халкым җылый,
Нәрсәләрен такканда.

Сугышка дип куганда,
Җыелдык без урамга,
Күз яшьләрем ....
Агы суык буранга.

Балаларым үкереп җылый,
Без мескеннең алдында,
Әткәй-әнкәй әйтә миңа:
– Безне утка салдың ла.

Әни карчык, әти карт,
Бөкерәеп калдылар,
Япон дигән йөзе кара,
Безне утка салды ла.

Без авылдан чыкканда,
Тәкбир әйтеп калдылар,
Хәер-дога кылыгыз,
Безне инде алдылар.

Туганнарым, дусларым,
Ничек ташлыйм сезләрне,
Бу эшләрне күрергә
Ходай кушты безләрне.

Көне-төне бәгърем корый
Исемем солдат булганга,
Мин җылый дип җыламагыз,
Җылыйм күңелем тулганга.

И, дусларым-ишләрем,
Аерылгач нишләрем,
Кая китте бу фәкыйрьнең
Тыныч яткан кичләре.

Озатырга килгәчтен
Печән салдым айгырыма,
Ходай бирсә кайтырбыз,
Әти-әни, кайгырма.

Кардәшләрем килделәр
Озатырга калага,
Тәккатем юк, бәгърем корый
Ятим калган балага.

Ике кызым, бер улым
Озатырга килделәр,
Бик җылагач балаларга
Кәнфит алып бирделәр.

– Әти бәгърем, китмә, – дип
Асылалар муйныма,
Күңлем тулып җылыйбыз
Җаулык куеп күземә.

Их, балалар, балалар!
Бик җылашып калалар,
Ничек итим, җаннарым,
Атагызны алалар.

Балаларым «әтием» диеп
Асылалар муйныма,
Әти-әни «бәпкәм» диеп
Акча тыга куйныма.

Машинага утырганда
Уфарунга тезделәр,
– Кая безнең әткәй? диеп,
Балаларым эзлиләр.

Әти-әни, туганнарым
Озатырга килделәр,
Агай-эне кызганышып,
Акча җыеп бирделәр.

Көне буран, җилләп тора,
Өскә карлар сылаша,
Машиналарга утыргач
Туганнарым җылаша.

Утыз өчкә җиткәндә
Китеп бардым уенга,
Бик җылаган җәмәгатем,
Ачулана кайнага.

Без утырып киткәндә
Жиртуннаны җыйдылар,
Мең ярымлап солдат булды,
Бер поездга сыйдылар.

Караңгы төн, ачы буран
Ачып булмый күзләрне,
Колагымыз ишетми
– Сау бул! – дигән сүзләрне.

Кайсы ябышкан вагонга
Кайсы егылып калган,
Япон дигән йөзе кара
Диңгезгә миңа салган.

Хатыным тол каладыр,
Балам ятим каладыр,
Уйлап карагыз, кардәшләр,
Бу безгә зур бәладыр.

Ташлап чыгу җиңел түгел,
Йорт тулы балаларны,
Ник бармаска сугышка
Алганнар калаларны.

Безләр барып җитәргә
Бик зур куәт таптык без,
Барыбызда гайрәт икән
Японнарга аттык без.

Пуже сара уйнаганда
Күңелем тулып җыладым,
Аерылып киткәндә
Бик моңаеп җыладым.

Йөкле булып хатыным
Авырып калды балага,
Безне алып киттеләр
Дальний дигән калага.

Җаум-җаңгыр көннәре
Чыгып киттек каладан,
Стансадан хәбәр алдым:
Хатыным үлгән баладан.

Февральнең дүртендә
Машинага утырдык,
Безнең урыс гаскәре
Гурияне тутырдык.

Гуриягә барып кергәч
Кытайларга ....,
Японнар каршы килгәч,
Көне-төне атыштык.

Җаныпп яткан вакытта
Китеп бардым солдатка,
Барып кергәч сугышка,
Пуля тиде бармакка.

Кая барсаң, шунда тулы
Безнең урыс гаскәре.
Пуля каты очып килә
Өстемезгә нык кәре.

Кара флаг күтәрелгәч,
Булды безгә барабан,
Японнарның туплары
Узып китә арадан.

Барып кердек төнлә икән
Сеул дигән калага,
Шәһәр эченә сыймагач
Гаскәр чыкты далага.

Утыз алты көн булганда
Порт-Артурга җиттек без,
Ашамыйча, эчмичә,
Сугышырга киттек без.

Порт-Артурдан чыгып киттек
Апрельнең өчесендә,
Биш йөз чакрым бардык без
Тугыз көннең эчендә.

Ялу суы буенда
Унсигез көн яттык без.

Йөзе кара японнарга
Мылтыкларны кордык без,
Гуриядә йөрдек без,
Ачлыкларны күрдек без.

Ялу бозы өстендә
Түшләр илән шудык без,
Ялу суын чыгып киткәч,
Японнарны кырдык без.

– Молодец! – дип кычкыра
Безнең урыс башлыгы,
Яргалады аягымны
Маньчжурия ташлыгы.

Маньчжурия җирендә
Аршин ярым кар булды,
Без атарга керешкәч,
Японнарга тар булды.

Кара төтен арасында
Яудырадыр өсләргә,
Бу эшләрне күрәсем
Кергән иде төшләргә.

Ялу суын чыкканда
Суык алды тезләрне,
Япон дигән йөзең кара
Хәрап итте безләрне.

Мылтык төзәп торганда,
Килеп төште туп өскә.

Японнар туп атадыр
Безнең гаскәр күп төшкә.

Өстебездән туп узганда,
Әҗәл көтеп торабыз,
Сигнал булса безгә таба,
Мылтыкларны корабыз.

Көне-төне колагымда
Туп тавышы шартылдый,
Бу ниндәен сугыш булды
Бигрәк озак тартылды.

Күзләремне ачып булмый
Бигрәк ачы буранга,
Аптырагач, утырып җылыйм
Күңелләрем тулганга.

Караңгы таң, ачы буран
Ачып булмый күзләрне,
Әфисәрләр килеп суга
– Смирно! – дип үземне.

Ливан дигән шәһәрдә
Безнең гаскәр ятадыр,
Ялу суы буеннан
Японнар туп атадыр.

Кырык биш мең гаскәр булды
Мукдин дигән шәһәрдә,
Алты сәгать тоташ аттык
Япон дигән каһәргә.

Дүрт-биш сәгать эчендә
Йөз чакырым киттек без,
Сигнал булгач безгә табан,
Артка табан чиктек без.

Яргалады аягымны
Гуриядә ташлыклар.

– Ребята, молодец! – дип
Куандыра башлыклар.

Биек-биек тауларга
Газап чигеп мендек без,
Лауян дигән сугышка
Ничә кәррә кердек без.

Гөр-гөр итеп туп тавышы
Гел торадыр колакта,
Командирлар кычкыргач
Карыйбыз без флагка.

Камышлыкта йөргәндә
Аяк асты баткалак
Йөзең кара японнар,
Калды безгә аткалап.

Күлмәк-ыштан калмады
Гаурәтемне ябарлык,
Монда йөргән әдәмгә
Бирсен Ходай сабырлык.

Башымдагы картусым
Иләк кебек тишелде,
Безнең туплар атканда
Биек таулар ишелде.

Бигрәк яман сугыш булды
Лауяның буенда,
Көне-төне атышканда
Пуля тия куенга.

Камышлыктан барганда
Атлар сазга батадыр,
Биек тауның арасында
Японнар туп атадыр.

Телеграм алдык без,
Сахалинга бардык без,

Янә кайттык Порт-Артурга
Эчке якта калдык без.

Безнең казак командасы
Порт-Артурга килгәннәр,
Ауышырга японнар
Безгә вәгъдә биргәннәр.

Безнең урыс гаскәре
Биек тауга менгәннәр;
Йөзе кара японнар
Флагларын элгәннәр.

Восток дигән каладан
Озын морҗа күренә,
Безнең гаскәр менеп яткан
Биек тауның үренә.

Су эчәсем килгәчтен,
Ятып эчтем улактан,
Очып-очып пуля китә
Выж-выж итеп колактан.

Чирек сәгать эчендә
Камышлыкны ут алды,
Искәрмәдән туп атылгач,
Безнең гаскәр буталды.

Өч ай ярым артыграк
Су өстендә йөздек без,
Йөзе кара японнарны
Лауяннан сөрдек без.

Сары диңгез өстендә
Дулкын булды давылга,
Җайсыз булгач туктатырга
Барып төштек авылга.

Су буенда йөргәндә
Былчыранды аяклар,

Караңгылык җайсыз булды
Күренгәндер маяклар.

Искәрмәдән туп атылды
Карауылда торганда,
Янымызда мина калды
Крейсырны борганда.

Японнарның минасы
Безнең артта калганнар,
Яклы-якка карасак,
Миналарны салганнар.

Ачы буран суыкта
Итекләрем шакылдый,
Көне-төне колагымда
Туп тавышы шартылдый.

Маньчжурия җирендә
Аршин ярым кар булды,
Без атырга керешкәч,
Японнарга тар булды.

Караңгы төн, ачы буран
Ачып булмый күзләрне,
Колагыбыз ишетми
– Бегом! – дигән сүзләрне.

Бик уңайсыз вакытлар
Булды безгә язырак,
Хәерле булсын, туганнар,
Авыр килде азырак.

Авырлыкка булды сәбәп
Япон дигән каһәрләр,
Урышырга японнардан
Булды безгә хәбәрләр.

Маньчжурия буенда
Чокыр казып яттык без,

Японислар күрмәгәч,
Көне-төне аттык без.

Кара төтен арасында
Ничә көннәр урыштык,
Японнарның меңләренә
Йөзләребез очраштык.

Тун арбама җиккән атым
Парлап кара алаша,
Бу бичара хайваннар
Туп киткәндә караша.

Мөлдер-мөлдер яшьләр килә
Бу атларның күзеннән,
Боларны бик кызганамын
Артыгырак үземнән.

Өсләреннән туп узганда
Бер-берсенә кешнәшә,
Өлгермәсәм җигәргә
Офицерлар эшләшә.

Ак кәгазьләргә яздым
Баштан үткән эшләрне,
Җылый-җылый уйлап яздым
Сугышмаган кичләрне.

Төрле кеше уйлаганга
Төрле эшләр куелды,
Бу эшләрне күрүе
Безгә авыр тоелды.

Һәр кайсымыз яздык без
Башка килгән эшләрне,
Сүзләремезне тикшермәгез
Пуля алды тешләрне.

Һәр кайсыбыз яздык без
Башка килгән эшләре,

Туп тавышы яман икән,
Шакырдатты тешләрне.

Бәетнең ахырында шундый язу бар:

«Ошбу бәетне язучы Гәпделҗәмил Хәбибрахман улы Садыйков. Орнашбаш авылының ... Гәптелҗәмил дип беләсез, укып дога кылыгыз. 1906 елда гыйнварның 2 дә яздым, дүшәмбе көн». Бәет гарәп телендә язылган иде. Аны безгә Вәлиева Хаерниса укып торды, без яздык.

Садыйков Гәпделҗәмилне авылда белүчеләр бар, ләкин ул хәзер бу авылда тормый икән, адресын таба алмадык».

*Арча районы Орнашбаш авылында*
*Э. Касыймов, Н. Гыйззәтуллин*
*һәм М. Богданова язып алды. 1951 ел.*
*(кол. 42, папка 2, сак. бер. 46, 59)*

## Кибәче остабикәсенә

(1885 ел)

Бу бакчаны ясадылар май числосы башында,
Бу бакчаны ясаганда мин карадым каерылып,
Бакча эше беткәнче китәм инде аерылып.

Бу бакчаның эчләрендә сез утырырсыз серләшеп,
Мин ятырмын ялгыз гүрдә хаста булып яңгырашып.

Бу бакчаның ишеге бер ачылса, ябылмас,
Миннән калган балаларның хәтерләре табылмас.

И Ходаем, сөекле муллам, васиятем шул минем сиңа:
Балаларны кагар булсаң, бәхиллегем юк сиңа.

*М. Вәлиева.*
*Арча педкөллияте укучысы дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак. бер. 1)*

## Суга төшеп үлгән Савруш кызының бәете

Савруш суы борма-борма
Бер бормасы дирексез,

Ике рус куа килгәч,
Суга төштем ирексез.

«Чәршәнбе көн кер юма», дип
Әйтте миңа әнкәем,
Әҗәл җитте – тәкъдир тартты
Мин ашыктым, әнкәем.

Боз өстенә төшеп калган
Зөһрәнең тәнкәсе,
Озак торгач эзләп чыкты
Карый булган әнкәсе.

*М. Вәлиева.*
*Арча педкөллияте укучысы дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 2)*

**Бәет**

Без әйтәбез, сез тыңлагыз Нигъмәтулла бәетен
Бисмиллаһи дип башладым бу бәетнең башларын.
Күчсә урман эчләрендә вәйран булды башларым.

Минем калган киемемне кем кисә дә килешер,
Коръән укып багышлагыз рухыма ирешер.

Биек тауны менгән чакта, карадым бер каерылып,
Туганнарым дус-ишләрем, калдыгыз бит аерылып.

Ишекләрдән чыккан чакта «сау булыгыз» димәдем,
Бу илләргә кайтарым дип төшләремдә күрмәдем.

Нигъмәтулла агач кисә, балта тоткан кулына;
Әткәсе белән әнкәсе бәхил булсын улына.

Агач төшә дигәченнән йөгереп китте уң якка
Нигъмәтулланы шул чакта агач басты уң якта.

Күчсә урман эчләрендә агач кисә эшчеләр,
Нигъмәтулланы агач баскач, җыелдылар кешеләр.

Нигъмәтулла ничә яшендә, кара бүрке башында;
Нигъмәтулла вафат булды 22 яшендә.

Биш ел йөрдем чит илләрдә, кайттым туган илләргә.
Туган илгә кайткачыннан рәхәтләнеп йөрмәдем.

Биек тауларның башында ашлык суга машина
Баш миләре тугыланган нарат төшкәч башына.

Минем калган киемнәрем эленеп торсын чөйләрдә,
Үз гомеремдә тора алмадым рәхәтләнеп өйләрдә.

Әнкәй, син мине тапканчы бер кыз бала тапсаңчы,
Я булмаса, яшь чагында су төбенә атсаңчы.

Рожмара тегермәненең бураларын сүттеләр,
Нигъмәтулла үлгәченнән күз яшьләре түктеләр.

Нигъмәтулланың киемен кия микән энесе,
Нигъмәтулла үлгәченнән күз яшь түкте күп кеше.

Рожмараның су буенча су коена балалар
Әткәй-әнкәй, туганнарым аерылып калалар.

Аның калган киемнәрен элеп куегыз чөйләргә,
Үкенечле булмас иде үлгән булса өйләрдә.

Җем-җем кара чәчләремне керләнгәч тарап алдым.
Нигъмәтулланы кызганып бу бәетне мин яздым.

*Арча педкөллияте укучысы К. Сәлахов дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 3)*

## Мансур Мостафин бәете

Әткәй, мине сагынсагыз, тәрәзәләрдән карагыз,
Зияратларда ялгыз ята сезнең газиз балагыз.

Әнкәй, ашың пешкән булса, ватмасана бүкәнне;
Син тапмасаң, мин булмасам, күрмәс идек бу хәлне.

Баскычлары биек икән, эчләре бик тар икән,
Җан алучы газыраил силос базында икән.

Әнкәй, ашың пешкән булса, бушатып куй чарага;
Миңа дигән өлешеңне бир нарасый балага.

Әнкәй, ашың пешкән булса, балаларың җыелыр,
Алар булып, мин булмагач, күзеңнән яшь коелыр.

Әйдә, силоска төшик, дип иптәшләрем әйткәндер,
Төшмәс өчен ният иттем, тәкъдир шулай иткәндер.

Инде мин басылып үлдем, каберемне карагыз,
Баш очына акташ куеп, исемнәрем языгыз.

Тальянский гармоннарны, әнкәй, син уйныйсыңмы?
Балам яшьләй үлде, диеп, әткәй, син уйлыйсыңмы?

Йөгереп кердем өйләргә, бүрек элдем чөйләргә,
Әткәй булмады янымда хәлләремне сөйләргә.

Әбиләргә барган чакта борыла идем чатларны,
Бөтен авыл зар елады мине алган чакларны.

Мине казып алдылар, өйгә кертеп салдылар,
Әткәй-әнкәй, туганнарым мине күрми калдылар.

Әбиләргә барам, диеп өйдән чыгып киттем мин,
Тәүлегем тулган чагында гүр иясе булдым мин.

Үзебездән әбиләргә үтәсе күп араны,
Силостан казып алдылар мин бәхетсез баланы.

Әткәй чәчен алдырган, артын тигез калдырган,
Мансур мескен газиз җанын силосларда калдырган.

1934 елның 10 февралендә яки шимбә көн сәгать унбердә Мансур Мостафин силос базында басылып вафат булды. Бу бәет аңа багышлана.

*Арча педкөллияте укучысы П. Иванов дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 4)*

**Анасы суйган кыз бәете**

Җәй башыннан ук моңланып йөрдем,
Әнкәй суясын төшемдә күрдем.
Кура җиләге нигәдер пешми,
Быел күңелем нигәдер үсми.

Ялгызым кичтән ятып йокладым,
Бераз ял иткәч туңып уяндым.
Ябык җир йөзен һичбер ачмадым,
Җирнең иңәсен белеп бармадым.

Тышлардан кереп сузылып яттым,
Шул яткан килеш тора алмадым.
Хәлем авырайгач, докторлар килде,
Труба аша тыңлап «терелерсең» диде.

Алмалар тоттым, уйларга баттым,
«Терелерсең» дигәч, сөенеп яттым.
Әнкәй чәчемне майлап тарады
Кара коелып йөземә карады.

Тау буйларында йөргән юлларым,
Дүшәнбе көн иртә белән чыкты җаннарым.
Әнкәй чәчемне майлап тараган,
Мине суярга пычак кайраган,

Ниләр буласын күңелем сизде,
Минут эчендә җанымны алды.
Әнкәем, алма, зинһар җанымны,
Үтенеп әйтәм, түкмә канымны!

Әнкәй, шәфкатьсез зәлим икәнсең,
Балаңны үтереп рәхәт күрмәссең.
Әнкәй мине карамады, үлеп җаным чыкканчы,
Һич тә рәхәт күрә алмадым
Үсеп буйга җиткәнче.

Сабый чакта яраттым мин
Әнкәемнең кочагын.
Җанымны алган чакларында
Ала алмадым пычагын.

*Арча педкөллияте укучысы З. Мусина дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 5)*

## Комга басылып үлгән Галимә бәете

Бисмиллаһи вә биллаһи, җитте корбан гаете,
Без әйтәбез сез тыңлагыз бу Галимә бәетен.

Иртә белән киткән чакта карадым мин аерылып,
Әткәм, әнкәм, туганнарым, калдыгыз бит аерылып.

Кызарып пешә җиләкләр безнең каршы тауларда;
Әткәй, әнкәй чыдый алмас, мондый авыр хәлләргә.

Әткәм белән әнкәемнең олы баласы идем,
Әҗәлем шунда икән, ком асларында үлдем.

Бибигалимә кер юа, ике җиңен сызганып,
Өсләремә зур ком төшкәч, бик күп яттым тилмереп.

Аксыл-сары чын гәрәбә Галимәнең муенында,
Комга барып үлә рмен дип, булмагандыр уемда.

Кулымдагы йөзегемнең исемнәре Гөлйөзем,
Сез сагынсагыз да бергә, мин кабердә берүзем.

Алмагачларның алмасын парлап саный алмадым,
Үкенечтә шунысы калды, бәхилләшә алмадым.

Зәңгәр сатин күлмәгемне элеп куйдым җилләргә,
Үкенечле булмас иде вафат булсам илләрдә.

Зәңгәр сатин күлмәгемне киштәләргә элмәдем,
Өйдән чыгып киткән чакта «сау булыгыз» димәдем.

Иртә торып тышка чыксам, гөрләп килә машина,
Бу ел бик моңайган идем, булган икән башыма.

Төшләремдә менгән идем Агыйделнең ярыннан,
Туган илдән аерылып үлүләрем күренгән.

Мин эшләргә чыгып киттем, көрәк-кәйлә күтәреп,
Шушы комнан котылырга һичбер хәйлә тапмадым.

Безнең бакча башларында, кемнәр чәчә борчакны,
Әткәй, әнкәй, кавыша алмабыз кыямәт көненә чаклы.

Йөгереп чыктым урамга, күңелләрем тулганга,
Әйтер сүземне әйтә алмадым гомерем тәмам булганга.

Комнан казып алдылар, чәлкән каз кебек салдылар,
Бөтен халык җыелып, хәйран булып калдылар.

Әнекәем, ашың пешкәч, балаларың җыелыр,
Алар булыр, мин булмамын күз яшьләрең коелыр.

Итәгемне комнар басты, йөгереп чыга алмадым,
Өйгә кайтып, бер сөйләшеп, бәхилләшә алмадым.

Җәйгә чыккач яшь балалар җыелыр,
Әткәй, әнкәй, уйласагыз, йөрәгегез бозылыр.

Кара булды кашларым, моңлы булды башларым,
Шушы ком чокырларында вафат булды башларым.

Исәпләсәм исем китә бу моңаюларыма,
Бөтен халык хайран булды болай булуларыма.

Кулымдагы балдагымны нихәл итеп киярсең,
Тере китеп, үле кайтып, әнкәй, нихәл түзәрсең.

Безнең турыда салкын чишмә, кемнәр төшеп су алды,
Әткәй, әнкәй йөрәгенә ком казулар ут салды.

Миннән калган гәрәбәне өзәрсең дә тезәрсең,
Кошлар килеп, сайраганда, әнкәй нихәл түзәрсең.

Уңга кисәм, сулга әйләнә кулымдагы балдагым;
Үкенечтә шунысы калды, гомеремне әйтә алмадым.

Зияратта күке кычкыра, чатта минем каршыда;
Әнкәй, мине беләсезме, мин хәзер җир астында.

Быел җәйли бик күп йөрдем, басу кырыйларында,
Яшь башларым вафат булды шушы ком чокырларында.

Безнең урам туры урам, алма бакчасы
Төрле хәлләр булгандыр, бәхил булсын барчасы.

Зәңгәр сатин күлмәгемнең, биле үземә таман,
Таман күлмәкләрне салып, кәфен киюләре яман.

*Арча педкөллияте укучысы Ф. Галимов дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 6)*

**Буранда адашып үлгән Мотыйга бәете**

Бисмиллаһи вә биллаһи җитте Корбан гаете,
Без әйтәбез, сез тыңлагыз Мотыйганың бәетен.

Туганнарым, дус ишләрем, хәзергә сау булыгыз.
Миңа җылау файда түгел, утырып дога кыйлагыз.

Капкалардан чыккан чакта өч карадым каерылып,
Күз алмам күк газиз балам калды миннән аерылып.

Өйдә чакта өсләремә кат-кат киендем,
Тегермәннән кайта алмыйча, бураннарда тилмердем.

Ашлыгымны киптереп, тегермәннәргә киттем,
Күргән төшләремне уйлап көн саен әҗәл көттем.

Ал тәлинкәләремдә тәмле иде ашларым,
Кар астында вайран булып ята минем башларым.

Газиз балам, туганнарым, җылап бетмәгез инде,
Минем гәүдәмнең кайтасын язсыз көтмәгез инде.

Мин ятам кар астында, кайчан табарсыз инде,
Мине табып алып кайткач, балам, нишләрсең инде.

Миннән калган киемнәрем, минем сиңа ярамас,
Миннән калгачтан торырсың, ләкин бәхетең булмас.

Тегермәннән чыктык без,
Түбән Нижат ярларыннан чыга алмый интектек без.

Ике туган икебез дә сөйләшеп кайта идек,
Бураннарда үләрбез дип һич уйламаган идек.

Ярманы күтәреп чыгып тәмам куллар арыды,
Кайтырга юллар эзләдем, минем килгән юлларыма буран чыкты.

Минем васиятләремне сез тыңлагыз, туганнар!
Һич белеп булмый икән быел булган бураннар.

Безнең чишмә буйларында казлар йөри коенып,
Туганнарым, газиз балам калды миннән аерылып.

Өстемдәге күлмәгемне манарсыңмы яшелгә;
Инде, балам, мин булмамын «әнкәй» дип эндәшергә.

Бураннар бик каты сибә биткә,
Килгән юл дип киткәнбез читкә.
Зәңгәрле бүрек минем башымда,
Зифа буйларым кар асларында.

Зифа буйларым, кара кашларым
Кар асларында газиз башларым.
Ачып карарга күзем таладыр,
Барча туганнар миннән каладыр.

Зифа буйларымны үлчәп алырлар,
Ак кисиядән кәфен сарырлар.
«Уф алла» дип бик күп кычкырдым,
Туганкаемны җанга чакырдым.

Төн караңгылык алдады безне
Юлны табарга ача алмыйм күзне.
Юллар эзләдек бик тар җирләрдән,
Кала алмадык шунда үлемнән.

Хәлләрем бетте юллар эзләргә,
Туганкаем да күренми күзгә.
Бу ел кыш буе эчләрем пошты
Вайран булып җаннарым чыкты.

Мин үлгәч, балам, укырсың микән,
Минем башларым бәхетсез икән.
Юллар эзләргә аягым тала,
Мотыйга дигән исемем кала.

Түбән Ниҗат ярларында күп утырдым хәл җыеп,
Шул кадәр хәлләрем бетте әйтә алмыйм «уф» диеп.

Яз чыгуга яшәрерләр бакчадагы суганнар,
Минем күргән нужаларны сез күрмәгән, туганнар.

Юллар эзләп тиргә баттым мин,
Юллар таба алмый бик тилмереп яттым мин.

Кадерсез булды башларым тегермәннән кайтам дип,
Газиз башым вәйран булды өйләремә кайтам дип.

Каты карның асларыннан мине эзләп алыгыз,
Бураннарда юлга чыкмагыз, миннән гыйбрәт алыгыз.

*Арча педкөллияте укучысы Ф. Галимов дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 7)*

**Фәйрүзә бәете**

Рбәгый язам сак-сок көенә,
Минем хәлемә дошман сөенә.

Җәйдем түшәгем, яттым урныма,
Нарасый балам алдым кулыма,
Имчәк имезәм сабый балама,
Ниләр киләсен белми анага.
Күңелем сизә, борчыла җаным,
Ашкынып йөрде чыгасы каным.

Җан бирүләре бигрәк сусата
Сулар бирергә юк ана-ата,
Ләхет ал, эткәй, киң гүрләремә,
Бик авыр хәл бит туганнарыма.

Аккан каныма күземне салам,
Күз нуры кебек калды өч балам.
Каршы урманда тургай сайрады,
Мине чабарга балта кайрады.

Хәдичә кызым кысты муенымнан,
Газиз энкәем, калам дип синнән.
Балта белән чапкач кан булды бар җирем,
Сөймәде мине көндәшем ирем.

Бардым басуга чүпләр утарга.
Керде ишектән каты дошманым,
Күрәмен инде Ходай кушканын.
Ишектән керде басты каршыма,
«Дөньядан үт» дип чапты башыма.

Ерак җирләрдән туганнар килгән,
Бәхил булыгыз, каласыз миннән
Ләхет ал, әткәй, минем гүремнән,
Бәхетсез булдым яшьлек көнемнән.

Исмем языгыз каберем ташына,
Көндәшем житте минем башыма.
Минем гомерем булды бик азга,
Ахыры мин төштем ләхетле базга.

Васият сүзләрем әйтә алмадым,
Җир асларыннан кайта алмамын.
Җеназам күтәр, газиз әткәем,
Газиз баламны күрми китәрмен.

Башым авырый, каты юмагыз,
Дөньяны күрим ашыктырмагыз.
Җеназам өстенә куелган кабык
Мәхшәр көне күк җыелган халык.

Бик күп хатын-кыз, бик күп агайлар,
Таяклар тотып чыккан бабайлар.
Бу авыр хәлгә дошманым сөенә
Дусларым жәлли, «уф алла» дия.

Әткәем белде «уф алла» дигәч,
Ишекне ачып «ни эшлисең» диде.
Җеназам барсын урам буенча,
Күрим дөньяны күзем туйганча.

*Арча педкөллияте укучысы Р. Төхфәтуллина дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 7)*

## Авыр көннәрдә
(бәет)

Бик күптән түгел, берничә елдан
Яздык тигез тормышлардан,
Дөнья каһәре сөйгән анамны
Алып китте безнең арадан.

Ул гына җитми әткәй кыз тапкан.
«Мәрьям җаным, бәгырькәем», – ди.
Өйгә алып кайткач кочаклап сөя.
«Менә сезгә яшь ана» дия.

Шулай торганда әнкәй әткәйгә:
«Җаным, сезгә сүзем бар», – дия. –
Үзеңне сөям тормышта яхшы,
Тик шул кызың тия тәңкәмә.

Бүгенге көннән улыңны приютка,
Кызыңны бир, яисә үтер, – ди. –
Аларны тотсаң, мине тотмассың,
Төкерәм дә чыгып китәм, – ди.

Әткәй кайгыга батып утыргач,
Сикереп торды өстәл башына:
– Кызым Һәмдия, килегез яныма,
Сезгә әйтәсе сүзем бар, – дия.

Сеңлем Һәмдия сиреннән кебек
Шул көнне чәчәк җыйган күп итеп.
Үлгәч каберемә шуны кадарсыз,
«Мин бүген үләм» дигән кебек.

Сеңлем Һәмдия бара янына,
Акбур төсле аның йөзләре,
Миңа әйләнеп яшен тамызды,
Җем-җем итә аның күзләре.

Сул кулы белән кочаклап кысты
Аны үзенең күкрәгенә,
Уң кулы белән үткен пычакны
Кадады аның яшь йөрәгенә:

– Кызым Һәмдия, бар анаң янына
Анаң белән рәхәт яшәрсең,
Якты дөньяда Мәрьям белән миңа
Рәхәт күрсәтми башларсың.

Кеше сүзе белән ничек кул барып
Үз баласын үзе үтергән.
Мәрьямне ташлап, Һәмдия өчен
Үзе 10 ел төрмәгә кергән.

Дөнья таралды, мин ятим калдым,
Авыр булды тормыш итәргә.
Бер шәфкатьле бәндә туры килде
Мине приютка алып китәргә.

*Арча педпедкөллияте укучысы*
*З. Хәйбуллина дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 9)*

**Бәхетсез кыз**

Иптәшләр җырлыйм мин сезгә
Туры килер чөнки шул көннәр,
Ничек зиарат минем юлдашым
Җиргә түгелә күз яшем.

Әткәй-әнкәй тора иде яхшы
Кайгы төште бу матур кызга.
Әнкәсе үлде, кыз калды ятим
Мәңге саргаерга гомергә.

Үзе әткәем кабергә күмгәч
Сөйми башлады, ташлады мине
Яшь хатынга әткәй өйләнгәч.

Яшь әнкәйне әткәй бигрәк яратты,
Һичбер вакыт бер сүз әйтмәде.
Ул үги әни кара йөрәкле
Усал эшкә әтине өйрәтте.

Диде ул: «Ирем, яратам сине,
Ул кызыңа тормыш калмады,
Я суга сал, я утка ташла,
Я булмаса югалт син аны».

Көннәрдә бер көнне әтием әйтәдер:
«Зәйнәп кызкаем, әйдә йөрергә
Кара урманга зияратка,
Әнкәеңнең каберен күрергә.

Бармыйм әткәй, барасым килми
Анда әллә күрергә,
Барасым килми анда йөрергә
Барам әнкәемнең каберен күрергә».

«Зәйнәп кызкаем, әйдә бараек,
Әнкәеңнең каберен караек,
Озак та тормыйча кайтып килербез
Һәм әнкәеңгә “сәлам” диярбез».

Шул сүзне әйткәч, килдем киенергә
Дидем: «Әткәй, әйдә барабыз.
Сөенеп анамның изге каберен
Чәчәкләр белән бизәп кайтабыз».

Зиярат өстеннән чәчәкләр җыйдам
Әнием каберенә куярга.
Мин бардым ахыры зиярәткә
Газиз башымны җуярга.

Чәчәкләр җыйгач, әтием әйтәдер:
«Зәйнәп, кызкаем, килче каршыма,
Кызганмый сине үги әниең
Әҗәл җыя синең башыңа.

Кызганмый сине үги әнкәең
Ахыры рәнҗерсең син миңа,
Мин сине суям, булма дөньяда,
Әниең белән яшә кабердә».

Әткәй кулында ялтырый пычак,
Минем җыйган чәчкәләрем бер кочак,
«Әткәй, суйсаң мин сиңа риза,
Ятим калдым бәхетем булмагач».

Үз әткәем муенымнан суйгач
Тиз дә чыкмый минем җаннарым,
Әти суйганны әни белмәде,
Кабергә ага минем каннарым.

«Суйдым баламны, сөйгән кызымны
Дөньясында тормыш калмагач,
Кафердән усал булдым балама
Яшь хатынның сүзен тыңлагач».

* * *

Иптәшләр җырлыйм мин сезгә, тыңламыйча һичкем калмасын
Үлсә хатыныгыз, яшь балалар булу өстенә икенчеләй
хатын алмагыз.

*Арча педкөллияте укучысы*
*М. Фазылҗанова дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 11)*

**Шахта бәете**
(Кәче авылының Хафиз Кәрим бәете)

Бисмилләһи дип башладым бу бәетнең башларын,
Кәрим иптәшнең бәетен хәзер әйтә башладым.

Авызымнан җаным чыкканда селкенде сөякләрем,
Чит илләрдә калырга дип яралган сөякләрем.

Шахталарга барган чакта 3–4 мендем Арчага,
Гаҗиз җаным өемә кайтыр сөякләрем калса да.

Машинадан карап калдым авылның күмелгәнен,
Бу ел шахтага барырга тартмады күңелләрем.

Саҗидә апа чәчен үрә, матур үрүләрем дип,
Вокзалларга озата барды актык күрүләрем дип.

Кеше баргач мин дә бардым, иптәшләрем бара дип,
Кеше кайткач әнкәм елар балам шунда кала дип.

Рамазан айларында бар кешедә ит булыр,
Төнге сәхәр ашаганда Кәрим улың юк булыр.

Шахталардан үлеп чыккач, бар да тора карашып,
Чит илләрдә ялгыз калды сөякләрем адашып.

Кәрим үлгән дип ишеткәч, бар туганнар елашыр,
Иптәшләрем кайткан чакта әнкәй барып сорашыр.

Әнкәй, үзең таза түгел, бик елама бетәрсең.
Машиналар узган чакта, мин кайтыр дип көтәрсең.

Бу ел урак урган идем Кәче басуларында,
Кәрим фасуннары бар ич Минҗан фасуннарында.

Минҗан энем тәгәрәп җылый «абый җаным, беттең» дип,
«Безгә кайгы калдырып, тар-ләхеткә киттең», дип.

Кулымдагы көмеш йөзек көнгә каршы ялтырый.
Фазыл кереп алган чакта барча тәнем калтырый.

Сеңлем сиңа васиятем шул, польтәмне син киярсең,
Ураза көн кичләрендә хәер-дога диярсең.

Авыллардан чыккан чакта мин карадым каерылып,
Чит илләрдә тар ләхеттә ялгыз калдым аерылып.

Бар егетләр дә булдылар җыен-санбан туенда.
Нәсимә сеңлем, син җыларсың Миләш күле буенда.

Минем калган бишмәтемне, әнкәем, ябынырсың.
Җәен сабан туйларында мин булмам, сагынырсың.

Үләсе көн төштә күрдем, балык тоттым елгадан.
Яшьләй үлем миңа читен, сез яшисез дөньяда.

Үләсе көн төштә күрдем, ятам бүрәнә астында.
Башларымны яшьләй җуйдым дөнья малы астында.

*Арча педкөллияте укучысы*
*С. Шаһлисламова дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 13)*

**Миңнуллин бәете**

Үз буема бик килешә
Минем зәңгәр чалбарым;
Рушка урамы башларында,
Чыкты минем җаннарым.

И, Ходаем, ник яраттың
Минем кара кашымны;
Рушка урамы башларында
Ашадылар башымны.

Күн сумкалар, дөбәлбирлар
Талдыра беләгемне.
Эткә өчләтеп таптырдылар
Канлы күлмәкләремне.

Җәйгә чыксам, юлда йөрсәм,
Кер куна кашларыма.
Шахта фонарьлары белән
Суктылар башларыма.

Бу ел теккән костюмым
Бик килешә гәүдәмә,
Зиан китереп йөрмәдем
Авылдагы бәндәгә.

Октябрьнең 11 ендә
Җыелыш ясадылар,
Җыелыштан кайткан чакта
Башымны ашадылар.

Арчаларда хезмәт иттем
ГРУ кул астында,
28 яшемдә
Ятам балчык астында.

Армиядан алып кайткан
Риминнәрем билемдә,
Ике кич тә куна алмадым
Туган-үскән илемдә.

Бераз вакыт йөреп кайтыйм,
Чыкмагыз мине эзләргә,
Каты, авыр хәлләр булды,
Туганнарым сезләргә.

Кечкенәдән бик күп йөрдем,
Казан калаларында,
Бер дә жәлләмиләр икән
Адәм балаларын да.

Минем кара каннарымны
Агыздылар җирләргә.
Бу бәетне югалтмагыз
Таралсын чит җирләргә.

Ал сатинга эшләтелгән,
Күлмәгемне кидем мин;
Атна кич сәгать уннарда
Тыкрыкта үлдем мин.

Аклы ситса күлмәгемне
Туйганча кия алмадым,
Туган-үскән илләремне
Туйганчы күрә алмадым.

Иртә торып сулар сибәм
Бакчадагы суганга.
Бу хәлләрне күрсәтмәсен
Миннән соң туганнарга.

Туганнарым, сезгә әйтәм:
Якты булсын юлыгыз,
Кайтмас җирләргә китәм мин
Хуш, исән-сау булыгыз.

Аклы ситса күлмәк кисәм,
Билләремне бәйлимен,
Җан бирү кайчан да бер
Яшь гомерне жәллимен.

Башымдагы бүрегемне
Алып куйдым җирләргә,
Минем авылда йөргәнем
Калды сагынып сөйләргә.

*Арча педкөллияте укучысы*
*М. Вәлиева дәфтәреннән. 1958 ел.*
*(кол. 61, папка 1, сак. бер. 14)*

**Бәет**

(Бу бәетнең язылган елы билгеле түгел. Бу бәеттә бер егетнең кыланышлары турында бирелә. Ул үзенең ата-аналарын һәм сеңлесен үтерә. Аны атарга хөкем итәләр. Ләкин ул шушы бәетне язу белән 12 елга төрмәгә озаталар).

Сигез яшемдә кердем мәктәпкә,
Унсигез яшемдә төштем хәсрәткә,
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Мәктәптән чыктым мин имтихан биреп,
Кешелектән чыктым мин эчеп-исереп,
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Өйгә кайттым мин эчеп-исереп,
Әнкәйгә кычкырдым аягым тибеп,
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Әткәйне суйдым мин, әнкәйне чалдым,
Кечкенә сеңлемне суларга салдым.
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Әткәй идәндә, әнкәй кароватта
Кечкенә сеңлем суның төбендә.
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Минем бу эшемне сизде милиционер,
Чакырдылар мине судья каршына.
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Беренчесе судит итә мине атарга,
Икенчесе судит итә мине асарга.
Эх, югалдым мин егет, калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Безнең ындыр уртабызда бар бер зур тирән елга
Судит итеп җибәрделәр нәкъ 12 елга.
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Идел өстендә ап-ак пароход
Мине озаттылар – Владивосток.
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

Минем башымда аклы фуражка
Моңланып карыйм мин нурлы кояшка.
Эх, югалдым мин егет,
Калтырый куллар,
Үтәдер айлар, үтә күп еллар.

*Арча педкөллияте укучысы*
*Ш. Шәрипов дәфтәреннән. 1958 ел.*
*(кол. 61, папка 1, сак.бер. 15)*

**Бүре бәете**

Күк ширмәнең илендә
Бар да болан шүресе,
Кыерларда берәү, икәү
Ташлыкларның бүресе.

Олы юлның маягы
Бары да каен таягы.
Ахыры, абый, бу эттер
Кыска моның аягы.

Олы юлдан бүре төшкән,
Кычкырыгыз Әмингә,
Эт икәнен шуннан белдем
Барып керде Хәлилгә.

Ташлыкларның бүресе
Төшеп килә яклардан;
Гимадетдин атлары
Сикерә алмый ярлардан.

Гимадетдин атлары
Икесе дә кан җирән.
Кычык мескен чыгар иде
Бу ел яуган кар тирән.

Ике-өч көннән җим сорый
Ана казның бәпкәсе,
Ат атланып килеп чыкты
Хәйбулла агай кеткә.

Таш елганың күбеген
Гыймадетдин сабын ит;
Фәхри солдат килеп җитсен,
Чәпчемичә сабыр ит.

Вәлиулла тегермәне
Талканлыкны тартадыр,
Вәлиулла эт үтергән,
Бәйләп чорнап кайтадыр.

Тукта, балдыз, туры утыр,
Менә тунап бетерермен,
Бүре тиресе кыйбат китсә,
Сиңа иннек китерермен.

Казаныгызда ашыгыз
Кайнамыйча пешмәсен,
Этегезне үтерерләр
Түбән очка төшмәсен.

***Нәтиҗәсе*: **Көлке итеп чыгарылган бәетләр төренә бер мисал. Бу бәет Мамадыш тирәсендә Ташлык авылының эте Кыерлы кешеләре тарафыннан бүре дип йөртелгәне, шул Кыерлыдан көлеп чыгарылган.

*Арча педкөллияте укучысы*
*З. Сабирова дәфтәреннән. 1959 ел.*
*(кол. 61, папка 1, сак.бер. 16)*

**Мәдрәсә бәете**
(япон көенә)

Бездә гыйлем нәрсә бар,
Барын сөйлим тыңлап кал!
Ничек итеп кабарга
Ашар булсаң әгәр бал.

Мыек ничек печергә,
Кием ничек кисергә,
Һәм дә кымыз эчкәндә
Ничек кирәк эчәргә.

Истинҗаны кылганда,
Таш белән ышкыганда,
Нинди зекер әйтергә
Кикереп пошкырганда.

Өскә чапан кигәндә,
Күркә тавык егәндә,
Нинди дога укырга
Яткан вакыт идәндә.

Читек кәвеш салганда,
Кавын төшен ярганда,
Нинди таяк тотарга
Мәчетләргә барганда.

Сул аяк белән керсә,
Уң ягына төкерсә,
Дүрт мәртәбә төкерсә,
Ничек булыр ул нәрсә?

Гыйш-гашрәткә батканда,
Кароватта ятканда,
Кафер буламы егет
Тәмәкене тартканда?

Исле майлар сөртkәндә,
Кызларга күз йөрткәндә,
Хәлфә сизсә, нәрсә эшлик
Авызга вак төрткәндә.

Берәү ашаса суган,
Үзе балмаса юан,
Миңа берәү сөйләде:
«Кафер була, – ди – туган!»

Шундый сүзләрне сорап,
Кылны кырыкка турап,
Гомерләр үткән җилге,
Дөресе булдык харап.

*Арча педкөллияте укучысы*
*М. Гаязов дәфтәреннән. 1959 ел.*
*(кол. 61, папка 1, сак.бер. 17)*

**Асрау кыз бәете**

Әнкәем дөнья куйды, башыма хәсрәт кунды,
Әткәем фәкыйрьлектән, ачлыктан гаҗиз булды.

Әткәем миңа әйтә, монда кил, бәпкәм-кызым,
Тыңласаң сөйләр идем, бар сиңа берәр сүзем.

Әткәем, ни әйтәсең, тыңлыймын сүзләреңне
Алай да тилмертмә син, күрергә йөзләреңне.

Балакаем, сүзем шулдыр, калага барыйм алып,
Асраулыкка бирәм сине, гомер ит шунда калып.

Яхшырак җиргә бирсәм, төзелер өстең – башың,
Фәкыйрьлек тә онытылыр, күзеңнән түккән яшең.

Әткәйнең бу сүзләре, тоелды яхшы булып,
Барам, дидем, әткәем, йөргәнче рисвай булып.

Сабак та укытырлар, мәгърифәт тә алырсың,
Яхшылык өйрәнерсең, динеңне һәм танырсың.

Тагы да ике үксез, бармакчы булды бергә;
Һәркайсы өмит итеп, мәгърифәт өйрәнергә.

Бер көнне тәвәккәллеп, җияүләп чыктык юлга
«Барабыз калага» дип, каранып уңга-сулга.

Бер-ике көннәр барып, юллардан йөреп арып,
Күп михнәт чигә-чигә, калага җиттек барып.

Баргачтан күп йөредек, аптырап урамдарда,
Керергә фатир тапмый суыкта, бураннарда.

Алай да, йөри торгач, бер йортка барып кердек,
Ул йортта бик юан гына, бер симез хатын күрдек.

Бу хатын безгә әйтә, «килдегез вакытсыз», ди,
Сөйлибез өчәү кызлар, ник болай бәхетсез без.

Алай да карый безне, сорыйдыр яшебезне,
Исәбе бар шикелле, сатарга башыбызны.

Әткәем шунда килеп, ишетте хатын сүзен,
«Кит моннан, бәдбәхет!» дип, җибәрде куып үзен.

Ул китте, берәү килде, асраугa сорый безне,
«Булырбыз риза» дидек, алсагыз өчебезне.

Бераздан килде бу ир, өч кызга урын бар, ди,
Әйдәгез бергә-бергә, байлар да карарлар, ди.

Карады абыстайлар, ашатты тагын байлар,
Өчебез өч урынга, урнаштык без гидайлар.

Әткәем китеп барды, башкынам ялгыз калды,
Ашап, эчерткәннән соң, абыстай чакырып алды.

Әйтә: «Юк минем балам, син инде миңа бала,
Акыллы, тәүфиклы бул, бар малым сиңа кала».

Өстемә күлмәк бирде, башыма япты яулык,
Күңелем күтәрелеп, телимен хактин саулык.

Абыстай куандырды, күңелемне юандырды,
Җиңнәрне сызгандырып, битемне юындырды.

Һәр көнне яхшылыкка һәм паклыкка күндерде,
Өйдәге хезмәтләрнең һәрберсен белдерде.

Ул вакыт яшем тугыз, тәнем сау, таза, тигез.
Кызарды ябык битем, тәнем дә булды симез.

Бераздан әткәй килде, хәлемне карап белде,
Әткәйгә маталанып, бай абый бүләк бирде.

Абыйстай тагын мактый, кызың бик уңган, диде,
Сабак та яхшы укый, акыллы, булган, диде.

Тәрбия тагын яхшы, көннән-көн тәнем тула,
Асрауның исәнлеге, байга да шатлык була.

Әткәем китеп барды, куанып йөрешемә,
Абыйстай тагын шулай, шатлана һәр эшемә.

Унбишкә яшем җиткәч, көн итү булды читен,
Бер сүз бар: «утны күргәч, мамыктан чыга төтен».

Бай абый миңа карап, әллә ни уйлый башлый,
Абыйстай күрмәгәндә, аулакта уйный башлый.

Ачмасын серне диеп, бүләкләр биреп көйли,
Бик иркен вакытларда, гыйшык сүзләрен сөйли.

Киемнәр ясыйм диеп, ант итеп ышандыра,
Алырмын үземә дип, күңелне бушандыра.

Шул кадәр карганадыр, алырмын бик хак диеп,
Алмасам, булсын миннән, хатыным талак, диеп.

Абыйстай хәлне белә, дөньяга фетнә туа,
Күземә күренмә, дип, һәр көнне мине куа.

Алдымда йөрмә, дия, залга да кермә, дия,
Бай абыйга бигрәк яман, эт кебек өрмә, дия.

Абыйстай карый ямьсез, телләре ачы, тәмьсез,
Хезмәтне куша авыр, сөйли бигрәк яман сүз.

Абыстайдан куркып качтым, бай абый үзе дә алмый,
Алам дип алдады да, соңыннан күз дә салмый.

Мин кабул итмәгәнне, абыйстай бер дә белми,
Никадәр каргансам да, сүземне алга алмый.

Ахырда туры килде, китәргә туган илгә,
Бөтенләй вайран булып, эләгеп тешкә, телгә.

Илемә кайтып китеп, бер фәкыйрь картка бардым,
Азгын бай җафасыннан, гомерлек теш-тел алдым.

*Арча педкөллияте укучысы*
*Г. Хөсәенев дәфтәреннән. 1958 ел.*
*(кол. 61, папка 1, сак.бер. 18)*

**Сугыш бәете**

Волкан тавын мендек без,
Болгарларны күрдек без.
Болгарларны күргәчтән,
Мылтыкларны кордык без.

Волкан тавы биек икән,
Ат менә алмый башына,
Болгар дигән йөзе кара
Җителә адәм башына.

Биек тауга мендем исә,
Күренә болгар казагы;

Безнең хәлләрне сорагыз,
Мисле кабер газабы.

Бүген төштә суга кердем,
Тезгә тиде салкыны.
Бу дөньяны ут чолгаган
Безгә тиде ялкыны.

Болгарлар туп аталар
Биек тауны ваталар.

*Арча педкөллияте укучысы.*
*Ф. Рәхимова дәфтәреннән. 1958 ел.*
*(кол. 61, папка 1, сак.бер. 19)*

**Ачлык елларда**

Кайдадыр шунда авыл читендә
Ишле семьяда мин тудым,
Абыйлар белән, апалар белән
Тугыз яшьтән эшкә тотындым.

Бик рәхәт иде апалар белән
Бергәләшеп тормыш итүе.
Җәйге көннәрдә таң нуры белән
Төялешеп эшкә китүе.

Әмма бу рәхәт күпкә бармады,
Тиздән канлы сугыш башланды.
Кырык яшендә безнең атабыз
Илтеп ут эченә ташланды.

Таң чулпаннарын чыгып санадым,
Көтеп сугышларның бетүен,
Һич уйламадым әткәй мәрхүмнең
Гомерлеккә бездән китүен.

Гомер күрмәдем тимер арбалар
Урманнардан узып киттеләр.
Туры атыбызны ишек алдыннан
Җигеп алып чыгып киттеләр.

Дәү абый китте кызыллар белән
Дошманнардан илне сакларга,
Бәләкәй абый кылычын тагып,
Китте үз иркеннән акларга.

Көннәрдән бер көн кара урманнарда,
Ишеттем мин мылтык тавышын,
Дәү абый белән бәләкәй абый
Атышалар кара каршы.

Атма, туганкай, куй мылтыгыңны
Туганкаең булам мин синең.
Юк инде, туган, хәзерге көндә
Туганкаең түгел мин синең.

Шушы сүзләрне бәләкәй абый
Җылый-җылый кайтып сөйләде.
Озак та үтмәде, чыгып та китте,
Шул китүдән кайтып кермәде.

Ал, кызыл гөлләр бөгелеп төшәдер
Көннең кызуында болында,
Каргалар белән козгыннар гына
Калды абыемның янында.

Абыйлар белән, апалар белән
Киттек алабута урырга,
Көн дә җил-давыл, тузаннар туза,
Ничек авылларда торырга.

Йорт җирләребезне байларга сатып,
Чыгып киттек Себер иленә.
Себер илендә ямь таба алмагач,
Туры килдек үлем чигенә.

*Арча педкөллияте укучысы*
*Р. Әминова, С. Галиева дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак.бер. 20)*

### Агуланган Мәрьям

Агуланган Мәрьямне больницага салалар,
Аталары, аналары аны озатып калалар.

Беренче көн килә аның хәл белергә анасы
Докторлар җавап бирәләр: «Авыр хәлдә ята», – дип.

Икенче көн килә аның хәл белергә атасы
Докторлар җавап бирәләр: «Авыр хәлдә ята», – дип.

Өченче көн килә аның хәл белергә дуслары,
Докторлар җавап бирәләр: «Бүген телдән калды», – дип.

Дүртенче көн килә аның хәл белергә сөйгәне,
Докторлар җавап бирәләр: «Җир астында ята», – дип.

Бардым кердем, җир астына анда күрдем Мәрьямне
Ач, бәгърем Мәрьям, күзеңне,
Ачмасаң, Мәрьям, күзеңне харап итәм үземне.

*Арча педкөллияте укучылары*
*Р. Әминова, С. Галиева дәфтәреннән.*
*1958 ел. (кол. 61, папка 1, сак. бер. 21)*

### Яшүсмерләр бәете

Мин кечкенә вакытта
Әтием киткән фронтка,
Германия фашистларын
Тотарга диеп утка.

Барып җиткәч, әтиемнең
Бер генә хаты килгән:
Безгә каршы дошманнарны
Тар-мар итәбез, дигән.

Шуннан соң минем әтием
Сугыш кырында үлгән,
Кадерле илебез өчен
Актык җанын да биргән.

Менә хәзер без үсәбез,
Һаман алга барырбыз,
Әтиебезне үтергән
Дошманнан үч алдык без.

Безнең Кызыл Армиябез
Тырышты, алга барды,
Әтиебезне үтергән
Дошманнан үчне алды.

Без дә үсеп белем алсак
Якларбыз Совет илен,
Корбан булсак та риза
Бирмәс өчен Совет җирен.

**Германия сугышы бәете**

Германия безгә сугыш ачты көтмәгәндә
... договор тулып бетмәгәндә.

22 июньдә хәбәр килде,
Һәркем хәзер ... булып торылсын диелде.

Фронтларга чыгып китте ишләребез,
Озата бардык яшькә тулы күзләребез.

Аерылышып, саубуллашып, бәхилләшеп,
Исән булсаң хатлар яз, дип вәгъдәләшеп.

Алар киткәч, кайгы булды үзебезне
Тормыш авыр һәм яшь каплый күзебезне.

Без китәбез аларга ярдәмгә эшкә,
Йөрәккә файда аларны күрсәк төштә.

Күпләребез киттеләр бер хәбәрсез,
Уза безнең яшь гомеребез аларсыз.

Бер хәбәрсез әллә исән, әллә үлгәннәр?..
Бик күп кешеләр ләхетсез күмелгәннәр.

Исән булсалар дошманнарга аталардыр
Ачу, нәфрәт белән уч алып яталардыр.

Сугыш туктап, кеше кайтса гел көтәрсең,
Үлгәннәрең һич белмәсен өмет итәрсең.

Балалар да беләә башлар, әти, дияр,
Алар әйткәч, минем йөрәкләрем көяр.

Балаларым ул нәфрәтне белеп үсәр,
Үскән саен аталары искә төшәр.

Моны яздым күз нурлары яшькә тулып,
Бу кайгылар урнашты миндә кайгы булып.

Ул балалар укырлар да зур булырлар,
Туган илне сагыну өчен
Һәрвакыт хәзер торырлар.

Үлсә дә ул дошманнарны җиңеп үлгән,
Балаларым Совет улы булган, дигән.

*Арча районының Урта-Ашы авылында*
*Кәримова Мөнәвәрәдән (1915 елгы)*
*1951 елда язып алынды.*
*(кол. 42, папка 3, сак.бер. 59)*

**Җырлар**

Өй түренә гөлләр чәчтем,
Чәчәге кирәк булыр,
Аерылдык, дип йөрмә елап,
Күзләрең кирәк булыр.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Гөлсемем,
Җиде ятның кулларына
Тагын калдың, мескенем.

* * *

Бөек тауның башларында
Җигүле трантаслар,
Икебез бер сердә булсак
Арага кералмаслар.

* * *

Җиде итәкле күлмәгемне
Кия алмадым уракка,
Я башларымны җуярмын,
Я китәрмен еракка.

* * *

Ерактан яхшы күренә
Кара урманның бөеге,
Сөеп-сөеп кавыша алмасак,
Гомергә җан көеге.

* * *

Ак чиләкләрнең булгачтын,
Ник бармыйсың коега?
Көн аралаш күрмәгәчтен
Күңелләрем боега.

* * *

Эре була, сары була
Сибран тамырлары,
Бит югач, суыма чыга
Йөземнең сарылары.

* * *

Сандугач баласы сары
Күгәрчен баласы күк;
Җыламаган көннәремнән
Җылаган көннәрем күп.

* * *

Сезнең тәрәз төбендә дә
Зәйтүн дигән гөлләр бар;
Дөньяларда синнән матур,
Синнән гүзәл кемнәр бар.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Фәрзәнә,
Гөлләр булып үсәр идек
Икебез бер нәрсәдән.

* * *

Кулымдагы зәңгәр чәчәк
Күңелсез чәчәк түгел,
Синең белән минем дуслык
Мәңге сүнәчәк түгел.

* * *

Бер мәктәпләрдә укыйбыз
Бергә белем алабыз,
Аерылгачтын, сагынсагыз,
Шул дәфтәргә карагыз.

* * *

Минем сөйгән чәчәкләрем
Ак белән кызыл, зәңгәр,
Күкрәгемә кадар идем
Чәчәкләр булсаң әгәр.

* * *

Өстәл өсләрендә
Нинди хат шигырьләре,
Синең кебек булса булыр
Алмагач чәчәкләре.

* * *

Суга барам, сулар алам
Тулмаса кире салам,
Сезнең якка оча торсын
Кошларга карап калам.

* * *

Кара бөдрә чәчләремне
Дүртләп үрәсем килә,
Суга сусаган кош кебек
Сине күрәсем килә.

* * *

Төшләремдә кара елан
Уралды беләгемә,
Һәрвакытта ирeш, дустым,
Теләгән теләгеңә.

* * *

Дустым, сиңа бүләк итәм
Бу серле чәчәгемне,
Киләчәктә теләп калам
Чәчәк кебек яшәвеңне.

* * *

Елгалар булып ага да
Җыела күлләр булып,
Күз алларымнан китмисең
Чәчәкле гөлләр булып.

*Арча районының Наласа авылында*
*1951 елда язып алынды.*
*(кол. 42, папка 3, сак.бер. 59)*

* * *

Зәңгәр буяуларга буя
Тәрәзә рамнарын,
Ничек итеп оештырыйк
Кавышу планнарын.

* * *

Ник әйтмәдең баштарак син
Ярларыңның барлыгын,
Яшь йөрәгең уртасында
Миңа урын тарлыгын.

* * *

Агыйделнең сулары
Боз булып ага мени,
Ятны теләп, ятка калдың
Ятлар да кага мени?!.

* * *

Әйтегез шул дускаема,
Кара күлмәген кисен.
Аның миңа буласы юк,
Теләсә кемне сөйсен.

* * *

Өй түрендә күлебез
Сай гына, тирән түгел;
Теләп сөям, бәгыркәем,
Җиде ят кирәк түгел.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Әневәр,
Яшь йөрәгем уртасында
Әрнүләр кайчан сүнәр.

* * *

Айкый-чайкый керләр юдым
Елганың уртасында,
Яфрак ярдың, чәчәк аттың
Йөрәгем уртасында.

* * *

Җиде ятны сөймә, дустым,
Миннән сиңа үтенеч,
Сачкага, сачкә тавына
Ләкин була үтенеч.

* * *

Көтәргә дип вәгъдә бирдем,
Көтәрмен бәгъремне,
Ул кайтканчы яшел үлән
Басмаса каберемне.

* * *

Озын булса, кисеп ташла
Фуфайка җиңнәреңне,
Сагынмасаң ташла, иркәм,
Эзлә үз тиңнәреңне.

* * *

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр ал алма;
Абын, сөртен, торып йөгер,
Только янымнан калма.

* * *

Сөюләрең хәйлә булса,
Әйт, бәгърем, дөресен,
Синең өчен яшь йөрәгем
Саргаймасын, сүрелсен.

* * *

Әнә килә автомобиль
Төягәннәр бөрлегән,
Йөрмә, дустым, ике белән
Бәхетең булсын бер белән.

* * *

Кулларыма чәчәк җыям
Чәчәкләрнең тулганын,
Төшләремә кермәсме дип,
Көтәм кичләр булганын.

* * *

Аклы ситса күлмәгемне
Киям әле тузса да,
Тагын бераз көтәм әле
Гомерем әрәм узса да.

* * *

Кулымдагы кульяулыгым
Аэроплан бизәкле,
Синнән башка беркемнәр дә
Өзми минем үзәкне.

* * *

Сандугачым, нигә болай
Өзелеп-өзелеп сайрыйсың,
Әллә сизеп сайрыйсыңмы
Башларымның кайгысын?

* * *

Агыйделне тирән диләр,
Тирән җире муеннан,
Кабер газаплары артык
Теләмәгән куеннан.

* * *

Мәхәббәт ул шундый нәрсә
Башларны әйләндерә,
Алмадай алсу йөзләрне
Лимонга әйләндерә.

* * *

Су буенда алсу чәчәк
Уралган каеннарга,
Мин дә шулай алсу идем
Уралдым кайгыларга.

* * *

Эчем пошса, карап торам
Һавадагы болытка,
Ут эчендә янып калган
Син дустымны онытмам.

* * *

Аклы яулык бәйләр идем
Уртасы айлыларын,
Агым суда юар идем
Башымның кайгыларын.

* * *

Ишек алдым яшел чирәм
Шунда кошлар ашатам,
Арасында бар матуры
Шунсын сиңа ошатам.

* * *

Иртә торып тышка чыксам
Карыймын ягыгызга,
Карасам да ягыгызга
Баралмыйм ягыгызга.

* * *

Суга барып өзеп алдым
Кәнәфер чәчәкләрен,
Моңарчы бергә яшәдек
Белмим киләчәкләрен.

* * *

Аклы-гөлле чәчәк белән
Бизәр идем атымны,
Яманлы сәламнар белән
Тәмам итәм хатымны.

* * *

Биек тауның башларында
Кып-кызыл чия икән,
Барып бергә вакытларда
Туйганчы сөйсәм икән.

* * *

Мәк чәчәкләре коела
Былбыл килеп кагынгач,
Мин дә шул чәчәккә карыйм
Сине өзлеп сагынгач.

* * *

Иртән торып тышка чыксам
Сездән көтәмен хәбәр,
Сезнең өчен минем эчем
Ник өзелә бу кадәр.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлфира,
Уф, йөрәгем парә-парә
Ни булыр тора-бара.

* * *

Су сикерә, диңгез шаулый
Алсу тауның кичендә,
Яшә, дустым, тормыш гөлем,
Ал чәчәкләр эчендә.

* * *

Бакчаларга кергәнем юк
Үсә микән гөлләрем?
Үлсәм дә сезне эзләрмен
Тар булмаса гүрләрем.

* * *

Аклы ситса күлмәгемне
Киртәләрдән җил алды,
Бергә булган вакытларны
Сагынып сөйләргә калды.

* * *

Һаваларда мамык оча
Күгәрчен кагынганда,
Берәр генә җыру язам
Укырсыз сагынганда.

* * *

Син дустыма хатлар язам
Уң беләгем талганчы,
Йокыларым кермәс инде
Сездән хатлар алганчы.

* * *

Яз көннәре бигрәк ямьле
Сахрада сайрый кошлар,
Бетте сугыш, алдык сулыш
Иркенләп яшик, дуслар!

* * *

Җәйгә чыксам сандугачлар
Болыннарда чәчәктә,
Гөл генә булсын, дускаем,
Тормышың киләчәктә.

*Арча районының Субаш Аты авылында*
*1951 елда язып алынды.*
*(кол. 42, папка 3, сак.бер. 59)*

**Хәниф егет бәете**

Бер истәлек язып әле,
Ачуланмый укырсыз.
Бер истәлек язмасак,
Бигрәк тиз онтырсыз.

Бик күп кенә уйлыйсы бар,
Чыгарасы бәеткә.
Уйламый да булмый инде
Үкенечле мәеткә.

«Мин илләрдән чыгып киттем,
Бик күп тауларны үттем.
Сау булыгыз биек таулар,
Мин сезгә басмам бүтән.

Минем дусларым шау-гөр килә
Туган илгә кайтканда,
Мин дә кайткан булыр идем
Туфрагым читкә тартканда.

Илләремә кайтмаганга,
Әнкәем каргагандыр
Каргышлары килеп җитеп
Башыма кадалгандыр.

Әнкәем, ялгыз калып
Үзәгемне өздең син.
Телеграмны алгач,
Ничек итеп түздең син.

Туганнарым, мин үлгәчтен
Бик елаша күрмәгез.
Минем кебек вакыт җитми
Җир астына кермәгез.

Күбәләк күк минем җаным
Кайтыр тәрәзәгезгә,
Күбәләгем кайткан чакта
Сәлам әйтермен сезгә.

Минем калган гармонымны
Кемнәр уйнатыр икән,
Әнкәем, син елаганда
Кемнәр юатыр икән.

Әнкәй, сине алдырам дип,
Уйлап кына йөрдем мин.
Болай булып үләсемне,
Төшләремдә күрдем мин.

Таһир абый, син килмәсәң,
Мин дә килмәс идем бит.
Ростов дигән зур шәһәрнең
Исемен дә белмәс идем бит.

Таһир абый, ачуланма,
Уйнап әйтәм мин аны.
Ходаем миңа тугач та,
Язып куйган инде аны.

Таһир абый, каберемә
Гөлләр дә утыртырсың.
Гөлләр чәчәк атканда
Килеп әлпи укырсың.

Чардуганнар корырсыз,
Ал буяуга буярсыз.
Бер генә елга булса да
Онытмыйча уйларсыз.

Чәчәк кебек вакытымда
Тар гүрләргә кердем мин.
Туганнарым, онытмагыз,
Мәңгегә шиңмәмен мин.

Врачлар килеп ярырлар,
Тар гробка салырлар.
Туганнарым, әнкәем
Ничек түзеп торырлар.

Каберләрем югалмасын,
Таш куегыз билгегә.
Озын гомер, ак бәхетләр
Телим сезгә мәңгегә.

Рәхмәт, Фатыйх абый,
Актык туема килеп җиттегез.
Дусларым арасында
Бик күңелле иттегез.
Инде исән-сау туган илгә
Кайтып җитегез.

Әнкәем кайткан чакта
Акылыннан шашкандыр.
Күзеннән аккан яшьләре,
Күлләргә тоташкандыр».

Агыйделләргә баткан ич
Минем ак үрдәккәем.
Ак үрдәккәем батмаган,
Беткән ич бәгырькәем.

Кайгысыз булган гомерләр
Үтми, сизелми икән.
Башларыңда кайгы булгач,
Көннәр дә үтми икән.

Шулай итеп гомерләрем
Үтәр инде рәхәтсез,
Бу хәсрәтләремне күргәнче
Кемгә тудым бәхетсез.

Башларымда уй югында
Нигә уйландым икән,
Уйсыз башка уйлар уйлап
Теләп алганмын икән.

Су сипсәм дә чәчәк атмый
Банкадагы гөлләрем,
Балам, синең хәсрәтеңнән
Озакламый үләрмен.

Зиратларны әйләнсәм дә
Җиләк өзеп капмадым.
Күзләрем йомып эзләдем,
Күз алдымда тапмадым.

Җиләкләрен ашасам да,
Җиләгендә тәм булмас.
Инде миңа яшәсәм дә,
Дөньяларда ямь булмас.

Алма бирәм алганга,
Ал яулыкка салганда.
Бу бәетне чыгардым мин
Йөрәккәем янганга.

*Бәетне аның авторы Әхмәдуллина Сабирадан*
*Арча районы Ташкичү авылында*
*Р. Һадиева 1958 елда язып алган*
*(кол. 72, папка 1, сак.бер. 12)*

Бисмиллаһи, вә биллаһи
Җитте корбан гаете
Без язабыз, сез укырсыз
**Әюп абый бәете**

Әти белән булган чакта
Белмәдем ич үләсен.
Алдагы көннең язмышын
Белеп булмый күрәсең.

Минем әти эшли иде
Ындыр башлыгы булып,
Әткәемнең гәүдәләрен
Хәйранга калдып күреп.

Әткәемнең гәүдәләрен,
Әвеннән алып мендек.
Әткәем, сине үлгән дигәч,
Урын өстенә мендек.

Әткәем үлгән чагында
Мин булдым ич янында,
Яшьләй гүрләргә керүе,
Әткәем, сиңа авырмы?

«Авыр диеп белми идем
Әле үлем хәлләрен,
Бигрәк авыр була икән
Мондый үлем хәлләре.

Фаһирә, сиңа бер теләгем:
Үлгәч мине онытма,
Минем турыда сүз әйтеп
Балаларны куркытма.

Бәгыркәем, мин үлгәндә
Уф! та дия алмадым,
Фаһирә җаным, мин үлгәндә
Сине күрә алмадым.

Әби җаным, сиңа әйтәм,
Мин үлде дип елама.
Киттем ерак сәфәргә мин,
Кайтыр диеп уйлама.

Күрер идем Тәкыяне
Бик сагындым мин аны,
Кече яшьтән күрә инде
Бу дөньяда нужнаны.

Актык чәйләремне эчтем
Синең белән бергәләп,
Машинаның бауларын
Йөри идем элгәләп.

Тегермәндә эшләгәндә
Башларыма җиттем мин,
Балаларымны калдырып
Яшьли гүргә киттем мин.

Тегермәнгә төшкән чакта
Аякларым тартмады.
Төшкәч озак та үтмәде
Машиналар таптады.

Актык чәйне эчкән чакта
Рафаэль белән уйнадым.
Шулай булса да, туганнар,
Сезне күреп туймадым.

Яздан чәчкән сабаннарны
Өлгермичә урмагыз,
Һәр эшегез үткер булсын
Минем кебек булмагыз.

Су буйларыннан төштем мин,
Матур су буйларында.
Беркемнәр дә күрмәгәндер
Актык сынуларымда.

26 кабат әйләнгәч
Мине баудан алдылар,
Өйдәге туганнарым
Күрмичә дә калдылар.

Мине баудан алгачтын
Арбаларга салдылар,
Ерактагы туганнарым
Күрә алмый калдылар.

Кенәрләргә барган чакта
Авырта ич тәннәрем,
Мин үләрмен дә китәрмен
Кала ич туганнарым».

**Әхмәтова Флёра бәете**

Казаннардан кайтканда
Аякларым тартмады,
Өйгә кайтып җитә алмадым
Машиналар таптады.

Кырлай тавын төшкән чакта
Машина китте чын ходка,
Мин сикереп төшәм дигәч,
Әти әйтте: «Курыкма».

Без тауларны төшкән чакта,
Машина чыкты юллардан.
Сикереп төшәргә уйладым
Әти тотты куллардан.

Машина чабып күп бормады
Китте тауның астына,
Әти белән кереп калдык,
Машинаның астына.

Шул егылудан без тормадык
Чыкты безнең җаныбыз,
Яшел үләнне кызартып
Аккан безнең каныбыз.

Әнине һәм туганнарны
Кайтып күрә алмадым,
Җан биргән чакларыбызда
– Сау бул! – дия алмадым.

Тамак кибеп мин уяндым
Сорап мин сулар эчтем,
Кабат минем күз йомылды
Мәңгелек йокыга киттем.

Без куанып кайткан идек,
Кайтабыз дип өйләргә,

Әҗәл безнең юлны кисте
Исән кайтмадык өйләргә.

Столовайга кергән идек,
Калды безнең ашыбыз,
Казан белән ике арада
Бетте газиз башыбыз.

Әнием җаным, без булмагач,
Юрган тегәрсезме икән?
Безнең үлгәнне ишеткәч
Ничек түзәрсең икән.

Авыр булыр, әни, сиңа
Безнең үлгәнне ишетү,
Җан бирергә булган икән
Безнең ашкынып китү.

Әни, безнең янга килгәч
Безне күреп еларсың.
Безнең ничек үлгәннәрне
Иптәшләрдән сорарсың.

Алар сиңа, әни, сөйләр
Безнең ничек үлгәнне.
Машина астында калып
Ничек җаннар биргәнне.

Әти белән без икебез
Вафат булдык бер җирдә,
Безне җәлләгән шикелле
Иркәләп исте җилләр.

Әтине күрдем, үлеп ята,
Су сорап яткан чагымда.
Безнең тормыш җимерелде,
Гөрләп үскән чагында.

Әни җаным, бездән теләк,
Үлгәч безне онытма.
Безнең үлгәннәрне әйтеп,
Балаларны куркытма.

Минем салган киемнәрне
Әни, үзең киярсең,
Калган ике туганымны,
Безне искә алып сөярсең.

Кала минем туганнарым,
Радик белән Фирая.
Без үлде дип, кыйнама аларны
Әни, син яхшы кара.

Әни, безнең карточканы
Ертма да, югалтма да.
Калган ике туганымны
Кагып син елатма да.

Дөньялардан без югалдык,
Әни, күлмәк текмә дә.
Киттек мәңгелек йокыга,
Без кайтыр дип көтмә дә.

Безне әни алып кайткач,
Күп кешеләр карарлар.
Кайберәүләр куанырлар,
Кайберәүләр җыларлар.

Кенәрләргә алып барып,
Безне шунда күмәрсез.
Әтидән мине аермагыз,
Икебезне бергә куярсыз.

Безне больницага керткәч,
Анда ярып карарлар,
Керерләр якын кешеләр,
Безне кызганып карарлар.

Безне ярып карагач,
Бергә кабер казырлар.
Әти белән икебезне
Салкын гүргә салырлар.

Салкын гүргә без барганда,
Күп кеше карап калыр,
Туганнарым һәм дусларым
Безне озата барыр.

Безне озата барганда,
Күзге җилләр исәрләр.
Салкын гүргә безне салып,
Өскә балчык ишәрләр.

Безнең үле гәүдәләр
Гүр төбендә ятырлар.
Баш өстенә таш утыртып
Исемнәрне язырлар.

Әни, безне озаткач
Кайтырсың син өйләргә;
Әти белән мин булмагач,
Сәер булыр өйләр дә.

Әни, балалар безне сагынырлар,
Алар безне сорарлар.
Безнең үлгәнне кисәк әйтмә,
Алар куркып еларлар.

Бездән калган ике баланы,
Әни, иркәләп карарсың.
Әни, больше без кайтмабыз,
Безне искә алып багарсың.

Безнең калды карточкалар,
Югалтмыйча аны сакларсың.
Алар булыр безнең истәлекләр,
Ертып ташлап утка якмассың.

Кенәрләргә, әни, килгән чакта,
Зират яннарыннан үтәрсең,
Кереп карап безнең каберләргә
Сәлам биреп, әни, китәрсең.

Искә алырсың шул чак, әни, безне
Ничек безнең вафат булганны,
Казаннардан өйгә кайткан чакта
Машинага тапталып үлгәнне.

Күрә алмассың, әни, хәзер безне
Үле гәүдәләр кире кайтмаслар,
Сүнде инде безнең тормыш гөле,
Алар яшәреп чәчәк атмаслар.

Безнең кабер ташларына басып,
Сандугачлар сайрап үтәрләр.
Кабер ташын алар укып карап,
Яшьләй үлгән икән диярләр.

Әни, безгә күлмәк текмә инде,
Кәфен киелгән безнең өсләргә.
Хәзер безне күрә алмассын син,
Балчык өелгән безнең өсләргә.

Безне, әни, искә алырсыз
Карточкаларга карап.
Балаңны үлде диеп,
Үткән көннәрне санап.

Без юк диеп, әни, син елама,
Күзләреңне елап бетермә,
Калган, әни, миннәр туганымны
Бәхетсез дип качып үстермә.

Авыр булыр, әни, без булмагач,
Каты каяу булыр башыңда.
Сагынып кайткан идем, әникәем,
Утыра алмадым синең каршыңда.

Яздан чәчкән сабаннарны
Вакыт җитми ура күрмәгез.
Казаннарга барып кайткан чакта
Безнең кебек була күрмәгез...

*Бәетнең авторы – Әхмәтова Флёраның абыйсы*
*Әхмәтов Нурый. Арча педкөллияте укучысы*
*Р. Һадиева тарафыннан Арча районы*
*Ташкичү авылында 1956 елда язып алынган.*
*(кол. 72, папка 1, сак.бер. 12)*

**Мулла бәете**

Яшел чапаннан, тубал чалмадан,
Калмыйм ашлардан, булсам да надан.
Фикерем яхшы, килмиләр каршы,
Һәр җомгам саен ясыйлар ашны.

Сөйләшә мужик каршыма килгән,
Хәзрәт, тизрәк бар, бәлеш изелгән.
Халык җыелган, нигъмәт куелган
Урының буш тора, токмач куерган.

Ашыгып барам, хәтерен саклап,
Ашап кайтамын ашларын мактап.
Бөтиләр язам, бәһа бик арзан,
Зәгъфран белән тәлинкә язам.

Авырулар карыйм, өшкерәм, өрәм.
Дәрәҗәм белән яхшы көн күрәм.
Гыйлемем бик яхшы, мичуар сатам,
Иҗек чәйнәтәм, баш миләр ватам.

Карыйм авырулар, ясыйм дарулар
Мәхәлләм бик зур, кайный сарулар.
Мин үзем табип: сикерәм, өрәм,
Дәрәҗәм белән яшим, көн күрәм.

*Р. Һадиева дәфтәреннән.*
*(кол. 72, папка 1, сак.бер. 12)*

## Шәфыйкъ бәете

Шәфыйкъ менә югары очка,
Дөньяларны күрәм, дип.
Әнкәсенә әйтеп чыккан:
«Әнкәй, бүген үләм», дип.

Шәфыйкъ ничә яшендә
Ал түбәтәй башында.
Мулла суккан, Шәфыйкъ үлгән
Шаһидулла каршында.

Йосып мулланың мәчете
Кояш чыккач яктыра.
Шәфыйкъ мескеннең йөзләре
Мәхшәр көнендә ак була.

Әнкәй, аклы күлмәгемне
Сабын тиереп юсана.
Әнкәй, мин дә синең балаң
Хәер-дога кылсана.

## Солдат бәете

Ике көннең берсендә,
Обед була безләргә.
Безнең монда нишләп йөргән
Мәгълүм түгел сезләргә.

Иртә торып, баш күтәрсәк,
Чуен юлдан барабыз.
Туганнарым, кавышыр идек,
Ерак безнең арабыз.

Тар юлларны без киңәйтеп,
Карлар ярып барабыз.
Бик сагынган чакларда,
Бер җырлашып алабыз.

Солдатларга аш бирәләр
Тимер табаклар белән.
«Смирно!» – дип кычкыралар,
Ачы тамаклар белән.

Солдатларның ашлары
Кич яткачтын кикертә.
Ике потлы мылтык биреп,
Үрле-кырлы сикертә.

Германия чебененең
Канатлары талчыкмый.
Никадәрле суырсак та,
Сохаридан бал чыймый.

Иң кечкенә туганымның
Исемнәре Әминә.
Каникуллар җиткәч кенә
Кайта алмадым илемә.

*Авторы Вафина Факия.*
*Р. Һадиева тарафыннан Арча районы*
*Кысна авылында язып алынган*
*(кол. 72, папка 1, сак.бер. 12)*

**Чыптачылар бәете**

Чыптачының өйләре
Багана белән бүлмәле;
Чыпта суккан кызларның
Каешлана күлмәге.

Сөләйманның капкасында
Кызлар тора җыелып,
– Чыпта начар булган, – дигәч
Алар китә боегып.

Бәрәзәнең кызлары
Су китерә мунчага,
Өйләренә керер хәл юк
Чорналадыр мунчала.

**Маһинур бәете**

Маһинур карак урлаган
Сабыйра ана маен да
Ни хурлыкларга төшмәде
Рамазан аенда.

Бәдәрнең күлмәген киеп,
Маһинур йөри киерелеп.
Анасы риза иткән
Ул кадак ярма биреп.

Кызылга буялган диләр
Мәкәрҗәдә дугалар.
Маһинур урлаган күлмәктән
Чүпрәк палас сугалар.

**Хатын белән бала бәете**

Бисмиллаһи вә биллаһи
Җитте Корбан гаете
Мин укырмын, сез тыңлагыз
Явыз хатын бәете.

Бисмиллаһи дип башлыймын
Бәетемнең башларын
Явыз хатын ашады бит
Яшь баланың башларын.

«Председатель алам дигәч,
Әни шуңа ышанган:
Шуның өчен үз әнкәем
Башларымны ашаган.

Мине мичтә яндырырга
Ник уйладың, әнкәем,
Ник азрак җәлләмәдең
Үзең тапкан бәбкәең.

Күлмәкләрем бар иде бит
Өсләремә кияргә.
Үтермәсәң, китәр идем
Дөньяларны гизәргә.

Белгән булсам, уйлар идем
Йөгереп тышка чыгарга.
Ничек кулың барды, әнкәй,
Янган утка тыгарга.

Әни, мичкә тыгар өчен
Одеалларга урадың.
Әни, барыбыр үзең дә бит
Кайгыларга уралдың.

Мин үлгәч күрәсең инде
Дөньяларның җәфасын;
Барыбер, әнкәй, үзең дә бит
Төрмәләрдә янасың.

Әни, ниләр булды икән
Синең башкайларыңа?
Сигез яшьтән җиттең, әнкәй
Газиз башкайларыма.

Яңа киелми калды инде
Зәңгәрле күлмәкләрем.
Өзелер әле минем өчен
Синең дә үзәкләрең.

Күрәсене күрмичә
Кереп булмый гүрләргә;
Аякларым янып бетми
Әби килеп кергәндә.

Минем әби кергән икән
Май исләре чыкканга,
Бигрәк авыр булды инде
Кызып янган чакларда.

Инде хәзер чәчләремне
Лента белән үрмәссең;
Мине утта яндырсаң да
Барыбыр рәхәт күрмәссең.

Больницаның тәрәзәсе
Җиде-сигез бүлмәле;
Минем утта яначакны
Бер кеше дә белмәде.

Ак тәннәрем авыртканга
Больницага салдыгыз,
Мин мичләрдә дөрләп яндым,
Туганнарым, калдыгыз.

Аклы ситса күлмәгемне
Өсләремә кимәдем;
Одеалларга төргән чакта
Ни дияргә белмәдем.

Председатель алам, дигәч
Ник, әнкәем, бармадың;
Янган утларга салганчы,
Ник суларга салмадың?

Явыз хатын белән ирне
Шунда кулга алдылар.
Авыл халкы артларыннан
Ләгънәт укып калдылар.

Казанга күргәзмә судка
Бар халык җыелып китте.
Суд аларны мәңгелеккә
Дөньядан мәхрүм итте.

**Марсель бәете**

Әнкәй куркып торыр диеп,
Чыгып киттем карышып
Ни газаплар чигеп йөрдем
Кашупкага ябышып.

Марсель, Марсель, дип кычкырып,
Бер тавыш та бирмәде;
Минем җан биргәннәремне
Кич бирәү дә белмәде.

Аякларым бик туңгач
Әремнәр салып кидем.
Җан биргән чакларымда
Ай, әнкәй, үләм, дидем.

Яшьләр чыгып китте мени
Чаңгы белән эзләргә;
Үле гәүдәләрем күргәч,
Белми әнкәй нишләргә.

Марсель белән чыгып киттем
Кашупкага ябышып,
Мәет булып кайтып кердем
Чаналарны тутырып.

Илгизәргә бара диеп,
Чыкты минем даннарым
Лесополос яннарында
Чыкты минем җаннарым.

Бер алыгыз, бер салыгыз
Казанканың басмасын;
Әнкәемне юатыгыз,
Мине уйлап шашмасын.

Каракуль пальтоларымны
Бер салдым да, бер кидем.
Җаным чыккан чакларда да,
Әнкәем, үләм, дидем.

Ашытбаштан төшә диеп
Көтеп торган әнкәем,
Мәет булып кайтып керде
Көтеп алган бәбкәең.

Ай, дусларым, читен икән
Адашып үлүләре,
Бигрәк читен була икән
Гүрләргә керүләре.

Мине гүрләргә илтергә
Туганнар ашыкмагыз.
Васыятем шул сезгә дуслар
Буранда юлга чыкмагыз.

Җем-җем кара чәчләремне
Бер тарадым, бер үрдем,
Басуларда юллар эзләп
Мин ни газаплар күрдем.

Мәктәпләргә менгән чакта
Уйлар төште башыма
Мәет булып кайтып кергәч,
Дуслар керде каршыма.

Марсель атка китереп суга
Станциягә барам дип,
Газраиль көтеп торган
Җанымны алам дип.

Минем гәүдәләрем кайткач
Нихәл итеп карарлар
Минем зифа буйларымны
Ничек гүргә куярлар.

Мине үлгәч урадылар
Кәфен дигән бүз белән
Дусларым искә алыгыз
Монда язган сүз белән.

Кычкырган тавыш булса,
Кызганыгыз барыгыз!
Мине гүрләргә илткәндә,
Дуслар, карап калыгыз.

**Моң-зар җырлары**

Кыйгак-кыйгак каз кычкыра
Бер бәбкәсе юк өчен,
Ятлар безне бик кагалар
Үз әнкәбез юк өчен.

* * *

Киң бакчада чәчәк ата,
Яран дигән гөлебез.
Ачлыктан җәфа чигәргә
Кала инде көчебез.

* * *

Алма бакчасына кереп,
Чәчәк өздем бер гөлдән.
Чәчәк өзгән гөлләр кебек
Аерылам туган илдән.

* * *

Су буена төшсәм, күзем алмыйм
Суга карап торган мин булдым.
Җыен туганнарым арасында
Иң бәхетсез бала мин булдым.

* * *

Безнең урам аркылы,
Ага суның салкыны.
Акмый ла суның салкыны,
Яна йөрәк ялкыны.

* * *

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлгенә;
Кадерле минутлар килә
Әллә нигә бер генә.

* * *

Өстәлләргә салып кисәм
Аклы күлмәкләремне.
Бергә вакыт искә төшеп
Өзә үзәкләремне.

* * *

Ак алъяпкыч кесәсендә
Алсу алма сулана.
Яннарыңа кош җибәрәм
Моңлы сайрар, елама.

* * *

Исле гөлләр булмаса да,
Бар бит башка гөлләрем.
Сез дуслардан аерылсам да,
Аерылмый күңелләрем.

* * *

Карама дуга, җиз алка
Безнең атларда гына;
Татлы йокы йокладык без
Сабый чакларда гына.

* * *

Биек тауның башларында
Арысланга оя юк.
Кая барсак та бер кояш,
Безгә рәхәт дөнья юк.

* * *

Машинаның тәгәрмәче
Үзе әйләнә микәнни,
Бу дөньяның михнәте
Безгә генә микәнни.

* * *

Тамчыларга чиләк куйдым,
Тула торгандыр инде.
Һәр кешедә бер хәсрәт
Була торгандыр инде.

* * *

Алмаш-тилмәш һаман тарта
Минем ике кашкынам,
Әлләниләр күрәчәкмен
Нигә генә ашкынам.

* * *

Бик ерактан ук күренә
Тауда ярның ак ташы,
Кая бармый, ниләр күрми
Адәм белән ат башы.

* * *

Тар сукмактан атлап килә
Озын буйлы тегүче,
Бу авылда мин генә инде
Иске бишмәт киюче.

* * *

Язгы кар сулары агып киткәч,
Алар тагы кире акмаслар,
Үтте, дуслар, бергә булган чаклар
Алар мәңге кире кайтмаслар.

*Н. Нәкыйпова дәфтәреннән.*
*Арча районы Югары Сәрдә авылы.*
*1969 ел. (кол. 72, папка 1 сак.бер. 18)*

*Текстларны басмага халык авыз иҗаты бүлегенең фәнни хезмәткәре Г.Р. Яхшисарова әзерләде.*

**Авторлар турында кыскача белешмә**

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Нуриев Илшат Габделфәрт улы* – Арча муниципаль районы башлыгы, икътисад фәннәре кандидаты.

*Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Гайнетдинов Айдар Марсель улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының ТР халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Газизова Марина Ринат кызы* – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге фәнни хезмәткәре.

*Гобәйдуллин Ленар* – «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары.

*Ямалтдинов Ильмир Илдар улы* – филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире.

*Яхин Фәрит Зәкиҗан улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире.

*Яхшисарова Гөлнара Рәшит кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре.

**ЭЧТӘЛЕК**

СҮЗ БАШЫ
*Ким Миңнуллин*
5

РУХИ МИРАСЫБЫЗ ХӘЗИНӘСЕ
*Илшат Нуриев*
11

ДҮРТ ЯГЫМ КЫЙБЛА:
Арчаның тарихи халкына бер сәяхәт
*Фәрит Яхин*
13

КУЛЪЯЗМАЛАР ҖЫЮ ТАРИХЫННАН
*Марсель Әхмәтҗанов*
59

«КАЗАН АРТЫ» ТАРИХ-ЭТНОГРАФИЯ МУЗЕЕНДА
ГАРӘБИ ЯЗУЛЫ ТАТАР ЧЫГАНАКЛАРЫ
*Ленар Гобәйдуллин*
65

ӨЙРӘНЕЛГӘН ТАШ ШОМАРА,
ЯТКАН ТАШ МҮКЛӘНӘ
*Айдар Гайнетдинов*
71

ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ ТУГАН ТЕЛ
*Флера Баязитова*
89

БАБАЛАР СҮЗЕ – АКЫЛНЫҢ ҮЗЕ
*Ильмир Ямалтдинов*
113

ШҮРӘЛЕ ТУГАН ҖИРДӘ
*Гөлнара Яхшисарова*
187

ЖИВОЙ РОДНИК ТАЛАНТОВ
*Марина Газизова*
228

ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
273

Авторлар турында кыскача белешмә
357

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*
Пятнадцатая книга

**Национально-культурное наследие**
**АРСК**

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*
Унбишенче китап

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**АРЧА**

Редакторлар: *Я.М. Абдулкадыйрова, Л.Ш. Дәүләтшина*
Компьютерда биткә салучы *Н.Т. Абдуллина*
Китапта *М.Р. Газизова, Р.Г. Галиуллин*
фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 12.11.2016
Форматы 60×84 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 12,5. Шартлы басма табагы 20,9
Тиражы 300 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

ООО «ТКС Контакт»
420021, Казань, ул. Г. Тукая, 91